View metadata, citation and similar papers at core.ac.uk
brought to you by CORE
provided by Kazan Federal University Digital Repository

**КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ**

**ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ**

***Кафедра татарской литературы и методики преподавания***

**Нурфия Марсовна Юсупова,**
**Гульфия Расилевна Гайнуллина**

# История татарской литературы (1940-2000) (7 семестр)

## Конспект лекций

**Казань – 2014**

**Направление подготовки:032700 «Филология» (**профиль подготовки 032700.62 «Прикладная филология (татарский язык и литература, английский язык): бакалавр»**)**

**Учебный план:**032700.62 «Прикладная филология (татарский язык и литература, английский язык): бакалавр»(очное, 2011), «Отечественная филология (татарский язык и литература): бакалавр» (очное, 2011)

**Дисциплина:** «**История татарской литературы 1940-2000-х гг. (7 семестр)**» **(бакалавр, 4 курс, очное обучение)**

Количество часов: **54** (в том числе: лекции – **28,** практические занятия -– **14**, самостоятельная работа -- **12**), форма контроля: **экзамен**.

**Аннотация:** главной целью курса является ознакомление литературным процессом последней четверти XX векав его взаимосвязи с развитием культуры, спецификой интерпретации литературного текста. Наибольшее внимание уделяется выделению художественного значения литературного произведения, определению художественного своеобразие произведений и творчества писателей 1980-2000-х гг. в целом. Данный электронно-образовательный курс является продолжением электронно-образовательных курсов «История татарской литературы (1940-2000) (5 семестр)» и «История татарской литературы (1940-2000) (6 семестр)».

**Темы:** 20.Татарская проза 1985-2000-х гг.; 21. Неомифологизм в татарской прозе 1985-2000-х гг.; 22. Психологический реализм в татарской прозе 1990-х гг.; 23. Романтизм в татарской прозе 1985-2000-х гг.; 24. Критический пласт в татарской прозе 1985-2000-х гг.; 25. Жанр рассказа в татарской прозе 1985-2000-х гг. 26.Татарская поэзия 1980-2000-х гг.; 27. Творчество Р.Хариса (1941); 28. Татарская драматургия 1985-2000-х гг..

Ключевые слова: **татарская литература, литературный процесс, стилевые тенденции, литературные направления и течения, творчество.**

**Дата начала использования:** 1 сентября 2014 г.

**Авторы:Юсупова Нурфия Марсовна**, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, email: Faikovich@mail.ru, Nurfija.Jusupova@ kpfu.ru; **Гайнуллина Гульфия Расилевна**, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, email: gulfiarasilevna@mail.ru, GGaynyllina@ kpfu.ru

**URL электронного курса в MOODLE**: http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=2223

**Доступность:** записанные на курс пользователи

**Язык интерфейса:** татарский

## Эчтәлек

Тема 20. 1985-2000 еллар татар прозасы ....................................................4

Тема 21. 1985-2000 еллар татар прозасында неомифологизм юнәлеше.........................................................................................................9

Тема 22. 1990 еллар татар прозасында психологик реализм күренеше, интелектуаль тенденция.........................................................................19

Тема 23. 1985-2000 еллар татар прозасында романтизм...........................................................................................33

Тема 24. 1985-2000 еллар татар прозасында тәнкыйди катлам...............................................................................................39

Тема 25. 1985-2000 еллар татар прозасында хикәя жанры...............................................................................................45

Тема 26. 1985-2000 еллар татар поэзиясе..................................................47

Тема 27. Р.Харис иҗаты (1941)...........................................................72

Тема 28. 1985-2000 нче елларда татар драматургиясе ..........................79

Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар........................................................................94

Терминологик сүзлекчә.........................................................................98

Имтихан сораулары..............................................................................100

# Тема 20. 1985-2000 еллар татар прозасы

**Лекция**

**Аннотация.** Лекциядә соңгы еллар татар прозасы юнәлешләр-агымнар ягыннан бәяләнә, «яңартылган реализм», романтизм, экзистенциализм, неомифологизм, постмодернистик алымнар, хәзерге прозада романтизм, символик сурәтлелеккә корылган хикәяләр өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** «яңартылган реализм», романтизм, экзистенциализм, неомифологизм, постмодернистик алымнар

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д. Яңа дулкында / Д.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.5-23.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. - 544 б.

4. Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – 455 б.

**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы.**

1. Соңгы еллар татар прозасында неореализм «яңартылган реализм».
2. Традицион реалистик юнәлешнең яңа агымнар, стиль элементлары белән баюы.
3. Тәнкыйди башлангычны да, романтик башлангычны кушарга мөмкинлек биргән магик реализм агымы, неомифологизм юнәлеше.
4. Прозада интеллектуаль тенденция. Интеллектуаль башлангычның гротеск формасына, сатирик пафоска мөрәҗәгать итүе. Постмодернистик текст.
5. Хәзерге прозада кеше фаҗигасен сентименталь төгәллектә сурәтләргә омтылучы, тормышны хисләр тарихы итеп күрсәткән әсәрләр.
6. Романтизмның яңадан мәйданга чыгуы.
7. Символик сурәтлелеккә корылган хикәяләр.
8. Прозада аллегорик, күпләп куллану.

XX гасыр ахыры прозасы – татар прозасы үсешендә яңа дәвер. Бу чор, бер яктан, XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булып, фәлсәфилек, һәм гареп, һәм шәрык мәдәнияте булдырган алымнарны бик теләп милли җирлеккә күчерү ягыннан алтын чор традицияләрен үстерүчегә әверелде. Икенче яктан, милли чынбарлыкка, үткәнгә һәм бүгенгегә игътибар арту күзәтелә, һәм ул әдәбияттагы тема-проблематикага тәэсир ясый.

Гасыр ахырында «социалистик» кысаларыннан арынган реализм кеше характерын аның субъектив казанышы итеп аңлату белән эш-гамәлләрне тарихи-иҗтимагый мотивацияләү (детерминизм) арасында алтын урталыкны тапты, типиклаштыруны иҗтимагый-сыйнфый баскычтан гомум-кешелек югарылыгына күтәрде (Ф. Сафин, Ф. Садриев, К. Кәримов)

Соңгы еллар татар прозасында **неореализм** (яки соцреализмнан соң булганга «яңартылган реализм») шәхеснең кыйммәтен ассызыклаган хәлдә, традицияләргә тугры калып, иҗтимагый тормышка аерым игътибар бирә. Әсәрләрдә чор картинасын тудыру, заман, хакимият, системаның бөтенлекле образын укучы күз алдына бастыру максаты әйдәп бара. Реалистик әсәрләр ярдәмендә татар язучылары татар халкы үткәненең аерым бер дәверләре сурәтен яңадан тергезергә (1920—1930 еллар фаҗигасе – Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» романында, 1980—1990 еллардагы ялганга корылган хакимият системасы – Ф. Садриевның «Таң җиле» һәм «Бәхетсезләр бәхете» романнарында, үзгәртеп кору дәвере Ф. Сафинның «Биек тауның башларында» әсәрендә һ. б. үзәктә тора). Авторлар үзләре дә җәмгыятьнең яки җәмгыяви бөтенлекнең вәкиле булып аңлашылалар, шул бөтенлектәге әхлакый кануннарны алга куеп, үткәннәргә бәя бирәләр.

**Реалистик проза** кешене һәм әсәрдә тудырылган тормыш моделен бәяләүдә әхлаклылык һәм әхлаксызлык, хакыйкать һәм ялган, намус һәм намуссызлык, шәхси мәнфәгатьләр һәм гомум мәнфәгате, матурлык һәм ямьсезлек дигән антиномик принциплар куллануны дәвам итә. Автор позициясе әйдәп бара һәм әсәр уйланмасы шуңа тәңгәл килә. Автор һәм хикәяләүче якынлыгы саклана, бәлки шуңа да татар прозасының публицистик характердагы өстәмәләрдән азат түгел.

Бер үк вакытта әдәбилекне арттыра торган алымнар күбәя бара. Реальлек һәм ирреальлекнең бөтенлеген тудыру омтылышы ясала: бу тормыш һәм теге дөнья, яшәү һәм үлем, кешенең дингә мөнәсәбәте, тормыш мәгънәсен экзистенциаль яссылыкта, чиктәш халәттә эзләү үтеп керә. Заманның иҗтимагый проблемаларын гомумкешелек мәсьәләләре белән тәңгәлләштерү теләге үзен нык сиздерә. Иң әһәмиятлесе: традицион реалистик юнәлеш яңа агымнар, стиль элементлары белән байый.

Аерым әсәрләрдә эш-гамәлләр геройларның хис-кичерешләре белән мотивацияләнә, танып-аңлап бетерү мөмкин булмаган ирреальлек: сихер, ырым дөньясы чынбарлык кебек тәкъдим ителә (Н. Гыйматдинова «Ак торна

каргышы», «Пәри утарында», «Китәм, димә», «Болан» һ. б.). Магик реализм агымы **(неомифологизм юнәлеше)** тәнкыйди башлангычны да, романтик башлангычны да кушарга мөмкинлек бирә, үткән – бүгенге – киләчәк чылбырының ике төрле үсеш вариантын күз алдына бастыра.

Психологик башлангычның алга чыгуы шәхес тормышының, аның эчке дөньясының тарихи-иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслый. (Ф. Бәйрәмованың «Болын», «Битлек») кебек повестьлары психологик реализм агымындагы беренче әсәрләрдән.

1990 еллар ахырына реалистик прозада **интеллектуаль тенденция** көчле билгеләнә башлады. Интеллектуаль әдәбият, фәлсәфи-психологик (Ф. Бәйрәмова), иҗтимагый (Р. Сибат, М. Кәбиров), әхлакый (Г. Гыйльманов) төсмерләр белән баетылып, мәйданга чыкты. Яшәеш, тормыш, кешегә караган универсаль кануннарны эзләп, шуларны барлап һәм укучыга тәкъдим итеп язылган әсәрләрдә автор-хикәяләүче образы беренче планга куелды. Г. Гыйльмановның «Албастылар» әсәрендә – әхлакый кануннар, Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар»ында – галәм, тормыш фәлсәфәсе, «Алыплар илендә»сендә – дини тәгълимат, Р. Сибатның «Ялгызак» романында «татар кешесе өчен» мәҗбүри кагыйдәләр үзәккә куела. Еш кына мифка мөрәҗәгать итү табигатьтәге һәм кешедәге үзгәрмәс кыйммәтләрне аерып чыгару юлына әйләнә.

Интеллектуаль башлангычның гротеск формасына, сатирик пафоска мөрәҗәгать итүе совет җәмгыятенә көчле тәнкыйть белән караган, антиутопик дөнья тудырган әсәрләр китереп чыгарды (Зөлфәт Хәким прозасы, Ф. Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга!», В. Имамовның «Могикан» повестьларында, Т. Галиуллинның «Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар» трилогиясе). Интеллектуаль башлангыч һәм шартлы-метафорик формалар белән кызыксыну артты (М. Кәбировның «Сары йортлар сере»).

XX гасыр ахырында **романтизм** яңадан мәйданга чыкты. Бер яктан, фәлсәфи фикер-карашлар белән баетылган саф романтик әсәрләр язылса (Ф. Садриев «Кыргый алма ачысы», М. Вәлиев «Качу», М. Галиев «Алтын тотка», «Ак абагалар»), икенче яктан, иҗтимагый катлам әһәмиятле роль уйный

торган, ситуацияләр иҗтимагый-тарихи да, психологик та мотивацияләнүче, романтик реализм төшенчәсенә туры килерлек әсәрләр иҗат ителә (Ә. Салахов «Соңгы вальс», М. Кәбиров «Мәхәббәттән җырлар кала»).

**Сентименталь башлангыч** калку билгеләнә торган, кеше фаҗигасен сентименталь тәгәллектә сурәтләргә омтылучы, тормышны хисләр тарихы итеп күрсәткән әсәрләр яңадан мәйданга чыкты (Ф. Садриевның «Рәхмәт, әтием» повесте, Ф. Яруллинның «Яралы язмышлар» романы, «Суга сөйләнгән серләр», «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», М. Галиевнең «Ерак урман авазы», Ф. Бәйрәмованың «Кем?» повестьлары).

Гасыр ахырында **символизм**ны кабат тергезгән, ягъни тулысы белән символик сурәтлелеккә корылган, символик катлам вакыйгалар катламыннан әһәмиятлерәк булып, аны күләгәдә калдырган әсәрләр күбәя. Хәзергә символизм – нигездә хикәя жанрының табышы. Яшь прозаиклардан Р. Зәйдулла («Дару» һ. б.), Ф. Җамалетдинова («Алма») һ. б. иҗатында символизм (яки икенче тапкыр күтәрелгәнгә, постсимволизм дип атау да бар) калку билгеләнә.

Шартлы-метафорик әсәрләр реализмнан гына түгел, романтизмнан да юл ала. Хикәя жанрында, кешенең бөеклегенә дан җырлап, кеше хисенең сафлыгы һәм тирәнлеге югары күтәреп язылган әсәрләр (И. Иксанова «Телефон», М. Кәбиров «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше» һ. б.).

Татар әдәбиятында хикәя үзгәрешләргә иң сизгер жанр булып кала. Инде 1960-1980 елларда хикәя тукымасында күзәтелгән үзгәрешләр гасыр чигендә повесть жанрына күчте һәм әдәбиятта яңа дулкын күтәрелү хакында аваз салды.

Прозада шигъриләшә барган эпик тел милли, шәркый мәдәният традициясен дәвам итә кебек тәэсир калдыра. Аллегорик, шартлы-ассоциатив, метафорик сурәтләрне күпләп куллану текстларны катлауландыра, укучының акыл эшчәнлеген активлаштыра. Кыйсса, эссе жанрларының үсүе исә аларга хас сыйфатларны башка жанрдагы әсәрләргә дә алып керә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр:**

1. Хәзерге татар прозасында тәнкыйди дискурс, аның креатив компетенциясе, референт компетенциягә юл алган татар прозасы.

2. Неореализм («яңартылган реализм») дигән төшенчәгә бәяләмә бирергә.

3. Традицион реалистик юнәлешнең нинди яңа агымнар, стиль элементлары белән байый?

4. Неомифологизм юнәлешенә караган әдәби текстларны атагыз.

5. Прозада интеллектуаль тенденция. Интеллектуаль башлангычның нинди формаларга, пафоска мөрәҗәгать итә? З.Хәким прозасы нигезендә расларга?

6. Хәзерге прозада кеше фаҗигасен сентименталь төгәллектә сурәтләргә омтылучы, тормышны хисләр тарихы итеп күрсәткән әсәрләргә кайсы әсәрләрне кертеп каый алабыз?

7. Романтизмның яңадан мәйданга чыгуы. М.Кәбиров, Ф.Садриев, М.Вәлиев һ.б. романтик прозасы.

8. Символик сурәтлелеккә корылган хикәяләр (Р.Зәйдулла прозасы).

9. Постмодернистик текст (З.Хәким, Т.Миңнуллин, Г.Гыйльманов).

## Тема 21. 1985-2000 еллар татар прозасында неомифологизм юнәлеше

**Лекция**

**Аннотация.** Лекциядә 1980-2000 еллар татар прозасында неомифологизм юнәлеше, Н.Гыйматдинованың “Ак торна каргышы”, “Болан”, “Пәри утарында” һ.б. повестьларында төрле катламнарның синтезы аша үткәрелгән фәлсәфә өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** неомифологизм, магик реализм.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың

үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.159-160.

2. Заһидуллина Д. Сихри дөнья чакыра // Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.107-123.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. ХХгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: ХХ йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы.**

1. 1980-2000 еллар татар прозасында неомифологизм юнәлеше: нәзари нигезләре.

2. Н.Гыйматдинованың “Ак торна каргышы”, “Болан”, “Пәри утарында” һ.б. повестьларында төрле катламнарның синтезы аша үткәрелгән фәлсәфә.

Дөнья әдәбиятында ХХ гасыр урталарында реализмның үзгә агымы – **магик реализм** формалаша. Төшенчә Германиядә 1923 елдан сәнгать белгече Франц Роо мәкалә һәм китапларында телгә алына башлый. Италиядә 1927–1928 елларда

«Новен-чето» журналында Роо фикерләрен М. Бонтемпелли теоретик яктан нигезли, үстерә. *Магик* гыйбарәсе чынбарлык белән янәшә серле, танып белү мөмкин булмаган катламны сурәтләүгә барып тоташа. 1927 елны Рооның «Постэкспрессионизм. Магик реализм» исемле китабын испан философы һәм сәнгать белгече Х. Ортега-и-Гассет испанчага тәрҗемә итә, исемнең беренче өлешен төшереп калдыра.

Магик реализм әдәбиятта озын юл үтә. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң немец язучылары Әрнет Кройдерның «Чарлактагы җәмгыять» (1946), Элизабет Лан-гессерның «Җуелмас билге» (1946), Герман Казакның «Елга артындагы шәһәр» (1947) кебек романнары дөнья күрә. Немец М. р.ы тамырлары белән романтизм һәм экспрессионизмга барып тоташа. «Колонна» (1929—1932) журналы битләрендә Магик реализм фәлсәфәсе һәм поэтикасы эшләнә. 1940—1950 елларда Магик реализмның Бельгия варианты дөньяга чыга. Моңа мисал итеп, Й. Ден, Х. Лампо иҗатларын китерергә мөмкин. Шул ук 1950 еллардан магик реализм Латин Америкасы илләрендә гаҗәеп көчле күтәрелеш кичерә. Х.Л.Борхес, М.А.Астуриас («Ураган», 1950; «Маис кешеләр», 1949), А. Карпентьер («Җир асты патшалыгы», 1949), Г. Г. Маркес («100 ел ялгызлык», 1967; «Полковникка беркем язмый»; «Патриарх көзе») әсәрләре дан казана. Рус әдәбиятындагы А. П. Платоновның «Чевенгур» (1929), «Котлован» (1930), Л.Леоновның «Пирамида» кебек әсәрләрен шушы агымга кертәләр. Бу агымга караган әсәрләрдә чынбарлык һәм аңлату мөмкин булмаган хәлләр тоташа, реалистик һәм мифологик, фантастик катламнар янәшә сурәтләнә. Язучы бүгенге белән үткәнне янәшә куя һәм, уйлап табылган, ирреаль хәлләр белән чагыштырып, тормышка, җәмгыятькә бәя бирә. Ирреальлек үзе гадәти, көндәлек тормышта даими күзәтелә торган детальләрдән «ясала», реаль законнарга буйсына һәм сәбәп-нәтиҗә аңлатылышы таба, шуңа күрә ышандыра да. Андый әсәрләрдә «мифологик детерминизм» – хәл-вакыйгаларны язмыш, табигый башлангычлар, борынгыдан килгән ышанулар белән бәйләп аңлату көчле. Бер үк вакытта аларда җәмгыятькә тискәре бәя бирелә, еш кына тормыш фаҗига, юкка чыгу белән тәгәлләнә. Магик реализмга түбәндәге сыйфатларның берлеге күзәтелү шарт:

– реаль һәм мифологик, фантастик катламнарның тоташып китүе;

– вакыт категориясен субъектив һәм шартлы файдалану;

– кешене мифик аң яссылыгында сурәтләргә омтылу;

– чынбарлыкны, ике катламга бүлеп, түбән һәм

– югары дәрәҗәләргә кую, түбән тормышның алдавыч булуын, югары дәрәҗәдә мондагы законнарның кирәк түгеллеген раслау;

– магик кануннар буенча яшәүче урынны тергезү;

– тормыш чынбарлыгына охшату, тарихи детальләргә мөрәҗәгать итү;

– төп геройларның аң-фикерләү үзенчәлекләрен рациональ-прагматик аңга капма-каршы кую;

– антиутопия, антипрагматизм, антиидеологизм,антидогматизм;

– кеше аңының тарихи төрләре – синкретик (фольклор, миф), рациональ, иррациональ, дини, атеистик, мистик кисешү һ. б.

Магик реализмның татар әдәбиятында агым булып формалашып җиткәне юк, ләкин әдәби күренеш төсендә 1990 еллардан Н. Гыйматдинова иҗатында күзәтелә. Аның «Ак торна каргышы», «Пәри утарында», «Сихерче», «Болан», «Каракош» повестьларында магик реализм сыйфатлары калку билгеләнә.

Н. Гыйматдинова әсәрләрендә кеше ике яссылыкта: реаль-гадәти тормышта да, серле-сихерле һәм аңлап-танып бетереп булмый торган дөньяда да яши.

«Ак торна каргышы» повестенда төп реалистик сюжет сызыгы Арслан, Сара һәм авыл кешеләре мөнәсәбәтләре кебек үсә.

Реалистик сюжет сызыгы күп каршылыклар ярдәмендә 1980-1990 еллар авылындагы проблемаларны ача: битарафлык (Сара-авылдашлары), эчкечелек, комсызлык (Сара-Сәрия), азгынлык (Сара-Фәрдәнә, Сәрия-Фәрдәнә), эчкечелек (Арслан-Шаһиәхмәт малае, Арслан-Шаһиәхмәт), әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе-алышынуы (Арслан-әнисе), җәмгыятьтәге бозыклык (мулла-авылдашлары, Арслан-авылдашлары), башкаларга иярү (Сара-мәктәп коллективы).

Беренчесе белән янәшә башланган, аннан соңрак тәмамланучы икенче, мифологик сюжет сызыгы – кешеләр һәм торналар арасындагы мөнәсәбәтләр

үсү тарихы. Гүзәллек һәм сафлык символы булган пар торналар, тәрәзәдән күренүгә үк, Сара күңелен җилкендерә, соңрак аны яшәүгә кайтара, аякка бастыра. Ләкин авыл кешеләре, азгынлык мәгънәсе салып, аларның берсен кыйнап үтерә. Бу фаҗигагә табигать көчле давыл белән җавап бирә: гөнаһ кылган авыл җәза ала. Әлеге мотив татар мифологиясендә бар: пар торнаның берсен үтерсәң, исән калганы каргый, бәхетсезлек китерә, дигән ышану яши.

Икенче сюжет сызыгы беренчесен көчәйтеп, үстереп килә. Шуның ярдәмендә автор үз фикерен әйтә: битарафлык, явызлык-кансызлык җәзасыз калмый, үлем һәм фаҗигаләргә китерә, мәрхәмәтле булырга кирәк, ди. Һәм давыл авылны – Нәбирә Гыйматдинова уйлап тапкан һәм тергезгән яшәү моделен җимереп кенә китми, ул мондый көнитешнең, усаллык, эчкечелек, битарафлык, кансызлык белән тулы тормышның яшәештә булырга тиешме-түгелме икәнлеген хәл итә, апокалипсиска әверелә.

Синтезга омтылу сюжет сызыкларында тәгәлләнми. Автор реалистик сюжетта романтик геройлар – Сара белән Арсланны үзәккә куя.

Әлеге геройларны укучыга «тәкъдим итү» вакытында символ кулланыла: канат. Беренче мәртәбә бу сүз Сара тарафыннан телгә алына. Язучы тарафыннан Сараның авылда тереклек итүе «сынган канатлар» дип бәяләнә. Шул рәвешле, пар канатлар – бәхет, мәхәббәт, өмет символы. Сараның сыңар канаты – ире Шамил каерылгач, яшәүгә аны Арслан кайтара. Канатларның табигать гүзәллеге фонында сурәтләнүе, Сараның гел очарга, югарыга омтылуы символның тагын бер мәгънәсен — кеше күңеле, рухи дөньясы кебек аңлануны тәэмин итә. Шушы мәгънәне көчәйтеп, язучы сүзне Шаһиәхмәткә бәйле файдалана. Символ ярдәмендә кеше күңеле- җәмгыять каршылыгы тудырыла. Торналарның игътибар үзәгенә куелуы, авылны чолгап алган табигатьнең җете буяулар белән күрсәтелүе язучының бөтен иҗаты буйлап үтә торган фикерен – табигать белән кешенең берлеген, кешенең җәмгыять законнарына буйсынып түгел, табигый кануннарны саклап яшәргә тиешлеге хакындагы субъектив идеясен калку итә.

«Пәри утарында» повестенең герое Рөстәм – реалист герой. Рөстәмгә хезмәттәшләр-әшнәләр мөнәсәбәтне яңадан бер кат карыйсы, дуслык- хыянәт яссылыгында уйланасы бар. Моның белән янәшә куйганда, Арсланга иҗтимагый вазифа йөкләтелә: ул – җәмгыятьтәге бозылган-үзгәргән кануннарны кире кайтарырга тиешле шәхес.

«Пәри утарында» повестендагы реалистик һәм романтик сюжет сызыклары бер ноктада төенләнә. Рөстәм-Хаят каршылыгы, романтик мөнәсәбәтләр мәхәббәткә кадәр үсә һәм югалту белән төгәлләнә. Рөстәм - хезмәттәшләре каршылыгы хыянәт, шулай ук дуслыкны югалту белән бетә. Сорыкай һәм ак бүре мифологик сызыгы да шушы ук схеманы кабатлый. Өч очракта да янәшәдәгеләр, якыннар хыянәте ялгызлыкка, бәхетсезлеккә китерә. Повесть проблемалар ягыннан да беренчесенә охшаш. Тигезсез мәхәббәт (Рөстәм-Хаят), җавапсызлык (Искәндәр -Хаят), азгынлык (Рөстәм-Җемҗемия), куркаклык (Рөстәм-Искәндәр), көнчелек, усаллык (Хаят-Искәндәрнең туганнары), комсызлык, җавапсызлык, битарафлык (Рөстәм - Фәрит Садриевич, Рөстәм-Хөсни, Рөстәм-Хасибулла), табигатькә сак караш (Рөстәм-бүреләр) мәсьәләләре кеше белән кеше, кеше белән табигать, кеше белән җәмгыять арасындагы конфликтларда ачыла, шулай ук заман кешеләренә һәм җәмгыятькә бәя бирүгә хезмәт итә. Мәхәббәткә, дуслыкка җавапсыз карау, әхлакый кыйммәтләрнең җуелуы югалтуларга, фаҗигагә китерә дигән автор фикере-идеясе өч төрле сюжет сызыгында кабатланып, көчәйтеп куела.

Романтик геройлар, бер яктан, язучыга магик реализмдагыча, ике төрле тормыш моделе төзергә мөмкинлек бирә. Иҗтимагый кануннар буенча яшәүче, комсызлык, эчкечелек, азгынлык, вәхшилек хөкем сөргән авыл тормышына – табигый, кешелеклелек кануннары белән яшәүче пәри утары – саф мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, изгелекне саклаган дөнья каршы куела («Пәри утары»), яки бу капма-каршылык авыл һәм Каф тавы арты кебек төгәлләшә («Ак торна каргышы»), авыл һәм тоба буларак аерыла («Икебезгә дә авыр»). Кайбер әсәр-ләрдә мондый ук конкретлык юк: табигать һәм сихер дөньясын җәмгыятькә

альтернатива төсендә сурәтләү белән чикләнелә («Сихерче», «Болан»). Икенче яктан, романтик геройлар, һичшиксез, автор мөнәсәбәтен күрсәтү, җиткерү өчен кирәк. Язучы аларны «чистарта», рухи дөнья кайгысы белән генә яшәүче, материаль ваклыклардан өстен, саф һәм изге җаннар дәрәҗәсенә күтәрә.

«Болан» повестенда Н. Гыйматдинова мифологик сюжетның үзен башка төрле эчтәлек белән катлауландыра. Акчәч һәм Рыскол мөнәсәбәтләре тарихы ярыммифологик, ярымромантик кушылма тәшкил итә. Акчәчнең үз эчендәге: җан һәм тән яки Акчәч һәм болан каршылыгы барлыкка китергән ярдәмче сюжет сызыгы исә тулысы белән мифологик характерда. Шулай ук синтезга нигезләнгән булса да, бу әсәр бөтенләй бүтәнчә кабул ителә. Төп сюжет сызыгында каршылыклар (Сузгын — авыл кешеләре, Сузгын — Мәүли, Акчәч — Рыскол, Сузгын — Рыскол, Сузгын — Акчәч, Рыскол — әнисе, Гатаулла — Рыскол) бер проблеманы — табигатькә, кешегә, үзоңо охшамаганнарга мәрхәмәт күрсәтү мәсьәләсен төрле яклап ача. Аяклары яраланган Акчәч һәм Рысколның тау буенда очрашу вакытында төенләнгән сюжет сызыгы алар арасында мәхәббәт кабынуга кадәр үсә һәм Акчәчнең, Рыскол гомерен саклап калу өчен боланга әверелеп, үзен корбан итүе белән чишелә. Башка җәнлек-җанвар аучыны каргап үләчәген белгән кыз яраткан кешесен коткарап кала. Ләкин Рыскол язмышы да матур булыр төсле тоелмый: антын бозган ир йә акылдан шашар, йә, чынлап та, тере мәеткә әверелер! Бу сюжет сызыгындагы табигатькә каршы бармаска чакыру идеясе ярдәмче сызыкта да кабатлана. Боланга сокланып, канун бозган өчен җәза алып, үзе дә ике тормыш белән яшәгән Акчәч, Рысколны коткарырга омтылып, табигатькә каршы чыга. Әлеге адым кыз гомере өзелү белән төгәлләнә. Рыскол язмышында канун бозу явызлык, тереклеккә зыян салу булып аңлашылса, Акчәчнең мәхәббәтен яклап канун бозуы соклангыч һәм бөек сурәтләнә, саф хисләргә мәдхия булып тоела.

Әсәрләрдә геройлар символлар һәм мифологик катламнар янәшәсендә тасвирлана. Хаят образына бәйләп, өч символик образ тудырыла: пәри утары,

лампа уты һәм шәл. Пәри утары – Хаяткә күчмәләрдән нәзер булып калган, ачкычын тапшырганчы вакытлыча тору урыны гына түгел. Ул – табигатьтән аерылып, үзе язган кануннар белән яшәүче, авылдагыга охшамаган, үзгә дөнья. Бу көнитештә һәр тереклек иясе – кешегә ярдәмче һәм дус. Бу дөньяда кеше –табигатьнең, тирәлекнең бер кисәге, чылбырдагы буын. Димәк, пәри утары – яшәү моделе, кешенең табигать белән кушылып көн итә алу үрнәге дә булып чыга. Ә ут символы, һәркөн Хаят тәрәзә төбенә яндырып куя торган лампа яктысы – Искәндәрне көтү газабы да. Ләкин аның чын мәгънәсе тирәндә: бу ут адашкан һәр кешегә юл күрсәтүче, маяк ролен үти. Шул ут кемнәрнедер үлемнән йолып кала. Ул – кеше күңелендәге изгелек, башкалардан әҗерен көтмичә эшләнә торган мәрхәмәт. Өченчесе — шәл образы. Гаять чибәр Хаят йөзен шәл белән томалап йөри, шуңа күрә кешеләр аны ямьсез, чәчсез, пәри төсле дип уйлыйлар. Ләкин шәл – матурлыкны яшерү чарасы. Ул – шулай ук яман күздән, явыз эшләрдән саклаучы да. Рөстәм дусларына күрсәткән мәлдә шәлен югалткан Хаят шундый саксызлык кыла. Образның өченче мәгънәсе дә бар. Хаятне шәлен югалтырга, матурлыгын күрсәтергә мәҗбүр итүче, фаҗигагә китерүче – мәхәббәт. Шәл мәхәббәтне күңелгә үткәрмәү, үзеңне сөюдән мәхрүм итеп яшәү, аскетлык билгесе кебек тә тасвирлана.

Үзәк геройлар мифологик катламнар янәшәсендә сурәтләнә. Рөстәм һәм Хаят язмышы ак бүре һәм сорыкай мәхәббәте тарихына тәңгәл. Урмандагы соры бүреләр ыруыннан берсе Хаят туып үскән яклардан ак бүре алып кайта. Ләкин соры бүреләр аны кабул итми: өзгәлән ташлый. Соры бүре ялгыз кала. Хаят тә үз тирәсендә, җәмгыятьтә ак бүре булып яши. Бу янәшәлек үз җиренә Хаятне алып кайтып, ташлап киткән Искәндәрне гаепләргә, Хаяткә соры бүре булып ташланган башкаларны: Рөстәмнең әшнәләрен, Искәндәрнең туганнарын, авыл кешеләрен, шулар аша тулаем җәмгыятьне тәнкыйтьләргә ярдәм итә.

Повестьларда төп героиня белән каршылыкка керүче өлкән хатын-кызлар (Сузгын, Убыр һ. б.) дөньяны – тәмуг, кешене аждаһа дип саныйлар. Ләкин шушы карашка үзәк герой фикере каршы куела, аның кешене һәм дөньяны

матур, саф итеп күрүе, үзгәртә, камилләштерә алырлык көчле итеп сурәтләнеше автор фәлсәфәсенең нининдилеген ассызыклый. Тискәре хәлләрнең, күренешләрнең, сыйфатларның вакытлы, узгынчы булуына ышаныч һәрвакыт үзен сиздерә. Дөрес, кара һәм караңгы яклар әсәрләрдә җете буяулар белән сурәтләнә, тирән фаҗигаләргә китерә. Шул фаҗигаләрдә кешеләрне гаепләгән, «Әй кешеләр! Әй кансызлар! Әй-й-й!» дигән Сәрия артыннан автор-хикәяләүченең дә «Әй-й-й...» дип уфтануы («Ак торна каргышы») аның чарасызлык чигенә җитүе хакында сөйли. Ләкин давылдан соң авылның да, кешеләрнең дә үзгәрәчәге ачык күренгән кебек (Сәрия дә үзгәрде бит), башка әсәрләрдә дә тормышның дөрес эзгә борылачагына өмет тоемлана.

Вакыйгалар эчендә дөньяны икегә: чынбарлык һәм хыял катламнарына аерганнан, чынбарлыкка караган күренешләрне материализм ноктасыннан аңлатып булмый торган эпизодлар-детальләр белән баетканнан соң (Хаятнең бүреләр белән дуслашуы, Акчәчнең боланга әверелеп яшәве, Хаятнең үлгән Рөстәмне терелтүе, Сараның аякка басуы шундыйлардан), фәлсәфи яктан да ике чик билгеләнә. Автор яшәешне капма-каршы көчләр бүленеше итеп күзаллый. Матурлык һәм Яхшылык – табигатьтә, кеше күңелендә, җанында; бар явызлыкка җәза бирерлек көч тә, ямьсезлек һәм усаллык та табигатьтә һәм Кеше җанында яши. Усаллык, Явызлык ягы баса башладымы, афәт, фаҗига, югалтулар килә. Акчәчләр һәм Саралар, үз гомерләрен корбан итү хакына булса да, шуңа каршы чыгалар. Ләкин автор Ак һәм Караны тигезләнгән үлчәү тәлинкәләре кебек карамый. Яхшылык һәм Явызлыкның, Ак һәм Кара көчләрнең тигезлеге – ислам диненә каршы килүче тәгълиматтан. Автор караны юк итү, бетерү хакында уйлана. Аның үткән заман хатын-кызлары Явызлыкка җәза бирерлек, аны җир йөзеннән юк итәрлек көчкә ия түгел.

Әсәрләрдә төшләнү, саташу алымы теге һәм бу дөньяны, реальлек һәм ирреальлекне тоташтыручы көчкә әверелә. «Ак торна каргышы»нда Сараның төше – өндә раслану, өне-төш, төше өн булып чыгу, давылдан соң аның югалуы, «күккә ашуы» әсәрне төрлечә аңлау мөмкинлеге калдыра. Моннан

тыш, героиняның табигать баласы, «югары көчләр» белән бәйле зат булуы искәртелә. Ә инде «Болан»да Акчәчнең боланга әверелеп йөрүе – аңлатып булмый торган гайре табигый хәл дә, кешенең үз эчендәге каршылыгы, икегә аерылуы (раздвоение), саташуы кебек тә кабул ителә ала.

Н. Гыйматдинова иҗат иткән архетипик образ – үткән заман хатын-кызы дип атаган образ – берничә әһәмиятле сыйфатны үзенә җыйган. Башкаларга охшамаган булу, табигать һәм йөрәк-хис кушканча яшәү, үзен мәхәббәт, башкалар бәхете хакына корбан итү – шундыйлардан. Әсәрләрдә бу тип берничә вазифа башкара. Беренчедән, романтик, нечкә табигатьле, хис-кичерешкә бай, рухи саф герой Матурлык, Мәрхәмәтлелек, Сафлык үрнәгенә – идеалга әверелә. Икенчедән, үткән чор хатын-кызы заман кешеләре тирәсендә, шулар фонында сурәтләнә. Заман кешесендәге тискәре сыйфатларга, яман гадәт-чирләргә аның холкы каршы куела. Бу исә авторга ике төрле яшәү моделен, рәвешен чагыштырырга, берсен кире кагарга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә әсәрләр ике вакытка: үткәнгә һәм бүгенгегә бүленә. Кешенең табигатьтән аерылуы, нәфес колына әверелүе, тупаслануы һәм явызлануы, моның гадәти кабул ителүе бүгенге тормышның төп афәт чыганагы итеп аңлатыла. Әсәрләрдә вакыт спираль буенча бара һәм аерым бер борылышларда кирегә, артка йөгерә башлый. Вакыт белән уйнау ярдәмендә хәзерге җәмгыятьнең ялгыш юлдан кереп китүе дәлилләнә. Еш кына әсәр ахырында автор төзегән вакыт шартлый, өзелә, туктала: давыл авылны юк итә, пәри утары җир белән тигезләнә, болан-кыз юкка чыга һ. б. Автор сурәтләгән урыннан, сер-хыялдан башка гына, ансыз яшәү вакыты килә. Архетипик образ, табигатькә һәм кешегә зыян салмыйча, үз күңелен саф-чиста тотып яшәргә омтылуның киләчәк фаҗигаләрдән котылу юлы икәнлеген ассызыклый. Алай гына да түгел, кешенең дөньяга килү максатын, яшәү мәгънәсен табу-күрсәтү баскычына күтәрелә. «Кеше дөньяга иҗат итәргә, матурлык тудырырга (Сара, Камилла), башкаларга ярдәм итәр, яшәү көче бирер өчен килә (Акчәч, Хаят). Шуны онытмасак иде»,— ди сыман автор.

Н. Гыйматдинова иҗатындагы архетипик образ гуманистик, гомумкешелек идеясен белдерү мөмкинлегенә дә ия. Аның әсәрләрендә үткән заман хатын-кызлары ялгыз. Шушы ялгызлык, ал арга теләктәшләр яки аңлаучылар булмау – фаҗигагә китергән сәбәпләрнең берсе. Кешеләрнең аңлашып, берләшеп, ярдәмләшеп яшәү зарурияте укучы тарафыннан нәтиҗә кебек ясала.

Әсәрләрдә әлеге хатын-кыз белән каршылыкка кергән ир-ат төрле: Арслан яки Рөстәм, Сәйдәш яки Рыскол — характерлары, язмышлары ягыннан бер-берсенә охшамаган затлар. Автор аларның барысын да үткән заман хатын-кызы белән очраштырып сыный. Ир-егетләр дә сынауны һәрберсе үзенчә уза. Көрәшчегә әйләнгәннәре дә (Арслан), юл чатында, сайлау алдында калганнары да (Сәйдәш, Рөстәм), сынган-сыгылганнары да бар (Рыскол). Җир йөзендәге борынгы кешеләргә хас асыл сыйфатларны исә автор нәкъ менә хатын-кызда тергезә һәм аны матурлык-изгелек сакчысы, яшәү көче бирүче итеп күтәрә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1980-2000 еллар татар прозасында неомифологизм юнәлеше: нәзари нигезләре.

2. Н.Гыйматдинованың “Ак торна каргышы” повестьларында төрле катламнарның синтезы аша үткәрелгән фәлсәфә.

3. “Пәри утарында” әсәрендә мифологик һәм реалистик катлам.

## Тема 22. 1990 еллар татар прозасында психологик реализм күренеше, интеллектуаль тенденция

**Лекция**

**Аннотация.** Лекциядә 1990 еллар реалистик прозасында психологик реализм күренеше, интелектуаль тенденция, фәлсәфи-психологик юнәлеш, иҗтимагый юнәлеш, әхлакый, сатирик һәм фәлсәфи юнәлешләр өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** психологик реализм күренеше, интелектуаль тенденция, фәлсәфи-психологик юнәлеш, иҗтимагый юнәлеш, әхлакый, сатирик һәм фәлсәфи юнәлешләр.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.160.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы.**

1.Татар прозасында психологик реализм күренеше: Ф.Бәйрәмованың “Битлек”, “Болан” повестьлары.

2. 1990 еллар реалистик прозасында интелектуаль тенденция: фәлсәфи-психологик юнәлеш (Ф.Бәйрәмованың “Канатсыз акчарлаклар”, “Алыплар илендә”).

3. Интелектуаль тенденцияле реалистик прозада иҗтимагый юнәлеш (Р.Сибатның “Ялгызак”, М.Кәбировның “Сары йортлар сере”).

4. Интелектуаль тенденцияле реалистик прозада әхлакый канат (Г.Гыйльмановның “Албастылар”).

5. Сатирик һәм фәлсәфи канатлы З.Хәким прозасы.

6. Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” (“Тәүбә”, “Элмәк”, “Төнге юллар”) трилогиясе.

7. Шартлы-метафорик формалар. (М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте, Т.Миңнуллинның “Минһаҗ маҗаралары” романы).

XX гасыр әдәбиятында реализмның тагын бер агымы – **психологик реализм** формалаша. Дөнья әдәбиятында – Фолкнер, Хемингуэй («Карт һәм диңгез», «Кыңгырау нигә чыңлый»), Сент-Экзюпери («Кечкенә принц»), Бергман иҗаты, кино сәнгатендә Антониони, Феллини, Креймер исемнәре белән мәгълүм. Бу агым психологик роман жанрын алгы планга чыгарды. Галимнәр фикеренчә, нәкъ менә шушы агым XX гасыр урталарыннан кешенең эчке дөньясын, рухи үсеш-үзгәрешләрен сурәтләүдә яңа мөмкинлекләр ачты.

Психологик реализм агымының формалашуын тормыш-көнкүрештәге үзгәрешләрнең, фән-техника прогрессы, экологик, сәяси проблемаларның кеше яшәешен катлауландыруы белән аңлаталар. Ул, барыннан да элек, кешене ялгызлык хисеннән коткару максатын алга куя. Агым кешенең мәдәни-рухи байлыкны, тормыш: мәгънәсен мәхәббәттә, яратуда табуын әһәмиятле санаган әсәрләрне берләштерә. Ул түбәндәге сыйфатларга ия:

– эш-гамәлләрне түгел, бәлки уй-фикер, хис-кичереш үсешен үзәккә кую, кешенең рухи дөньясындагы үзгәрешләрне сурәтләү объектына әйләндерү;

– кешене хисләр байлыгы, уй һәм омтылышлар чисталыгына карап бәяләү, тормышка, башкаларга мөнәсәбәттә гайре табигыйлек чигенә җиткән хисле, нечкә күңелле, тормышның көрәш булуын инкарь итүче идеал тудыру;

– чынбарлыкны аң агышы, хисләр үзгәреше, мөнәсәбәтләр алышыну аша, субъектив күрсәтергә омтылу; гротеск, гипербола алымнарына мөрәҗәгать итү;
– ялгызлык һәм аннан котылуны үзәк мәсьәләитеп күтәрү, тормышта ялгыз яшәп булмавын ассызыклау;
– мәхәббәтне ялгызлыктан һәм яшәүнең мәгънәсезлегеннән качуның бер юлы итеп карау;
– яшәү кагыйдәсен, яшәү формуласын эзләүче герой тәкъдим итү;
–хакыйкатьнең төрле кеше өчен төрлечә булуын ачыклау;
–реаль чынбарлык белән идеаль яшәү моделенянәшә куеп күрсәтү һ. б.

Психологик реализм агымы кысаларында язылган әсәрләрдә мөһим урынны романтик (модернистик) геройның – гадәттән тыш шәхеснең – тирә-юнендәге «уртача» кешеләр ертлачлыгы белән каршылыгы били (Лейдерман). Бу каршылыкта җиңү – бер үк вакытта җиңелү дә һәм киресенчә. Идеалист геройның ялгызлыгы тирә-яктагыларның хыянәте белән тирә-нәйтелә. Әсәрләр кешенең хис-кичереш мөмкинлекләренә сынау уздыра, Татар әдәбиятында психологик реализм әдәби күренеш буларак, 1980 елларда, Ф. Бәйрәмованың «Болын», «Битлек» кебек әсәрләрендә көчле белдерелде.

Ф.Бәйрәмова прозасында XX йөз башындагы татар модернист авторларының традицияләрен үстереп, яшәештәге төп кануннарны аерып чыгару омтылышы сизелә. Шушы акыл әдәбиятын кеше психологиясендәге тирән катламнарга кадәр үтеп керә алу, эстетик яктан камил һәм төзек, лириклык чигенә җиткән язу өслүбе белән кушуга ирешә.

«Болын» повестендагы төп сюжет сызыгын барлыкка китерүче Алсу тарихы үзенә файда яки матурлык эзләү каршылыгына нигезләнә. Матурлык эзләүче Алсуның башкаларга файда китерүчегә әверелү кыйссасындагы каршылык героиняның күңелендә, җанында туа. Ф. Бәйрәмова әдәби текст ярдәмендә ике дөнья тудыра, иҗат итә. Аның берсе – шартлы рәвештә бүгенге көнитешкә охшаш, икенчесе исә барлык сыйфатлары ягыннан шуның капма-каршысы, еш кына хыялый-фантастик дөнья. Алсу башкаларга охшамаган: ул үзе җәмгыятьтәге көнитеш кагыйдәләрен кабул итмәгән кебек, кешеләр дә аны

«сәер», үзгә буларак бәялиләр. Алсу – замана җимеше дә. Авыл һәм шәһәр көнкүрешенә хас детальләр повестьтагы тарихны 1970 еллар ахыры – 1980 еллар башы дип аңларга юл күрсәтә. Алсу ул – шушы чордагы матурлык эзләүче, сизгер һәм нечкә күңелле, хыялый кеше. Әсәрнең башында ук автор аңа охшамаган кешеләрне аерып чыгара. Төп сюжет сызыгындагы каршылык ачыклануга, яшәешнең бер кануны укучыга мәгълүм була: кешеләр төрле — кайберәүләр үзенә файда итеп яшәр өчен, ә кемнәрдер матурлык эзләп дөньяга килә, яши. Соңгылары күп түгел, алар җәмгыятьтә ялгыз калалар. Шул рәвешле, әдәбиятта еш очрый торган ялгызлык, җәмгыять тарафыннан читкә тибәрелү, кире кагылу мәсьәләсен автор ача. Кешеләрнең аралаша-аңлаша алмавыннан, шәхеснең «экзистенциаль ялгызлыкка» дучарлыгыннан чыгу юлын башкаларга файда китереп яшәүдә таба.

Әлеге каршылыкның үсүе, көчәюе текст эчендә дә тагын бер кат ассызыклана. Алсу үз асылына тугры кала – җәмгыятьтән аерылып, «сәер» исемен алганда да үзгәрә алмый. Повестьта төп игътибар эш-гамәлләргә түгел, героиняның эчке халәтенә, дөньясына, уй-фикер-ләренә, акыл һәм рухының үсеш-үзгәрешенә юнәлтелә. Повесть Алсу белән янәшә яшәп үзгәрә алучыларны да күрсәтә. Алсуның әнисе һәм Алмаз язмышлары ярдәмче сюжет сызыкларын тәшкил итә. Шулар кысасында иҗтимагый проблемалар да күтәрелә: җәмгыять үсешенең куркыныч дәрәҗәдә тизләнүе, фән-техника прогрессы китереп чыгарган бәла-казалар, әхлакый, экологик, сәяси афәтләр яссылыгында, нәкъ менә конкрет чор контекстында тасвирлана.

Әби-әни-Алсу чылбыры аларның бер тип кешеләр, дөньяга матурлык эзләп килүчеләр икәнлегенә ишарәли. Ләкин Рәйхан үзе булып яшәү мөмкин түгеллеккә төшенгән, «оригинальный», «практичный» хатын битлеген ябып яши башлаган. Белемне үзенә хезмәткә куярга омтылу, татарлыктан качу теләге – үзгәргән Рәйханга хас сыйфатлар. Битлек астыннан вакыт-вакыт башка кеше дә күренеп китә. Ирсез, ялгызы шәһәрдә кечкенә бала белән калу Рәйханны үзгәрткән кебек, Алмазны да этисенең үлеме, әнисе һәм сеңелләре өчен җаваплылыкны үз җилкәсенә алу мәҗбүрияте сындыра, башка кеше ясый.

Әнисенең Алмазны утын пүләне белән кыйнау моменты, аңа пычрак ату мизгеле – шул үзгәрешнең башлануы. Алсуны әнисенең укырга, шөгыльләнергә, чит телләрдә сөйләшергә мәҗбүр итүе дә өлешчә шуңа аваздаш. «Хәзер акыл заманы, хис, бию заманы түгел» дип, әни кеше баласын тормышка әзерләргә омтыла. Ләкин Ф. Бәйрәмова кешеләрне үзгәртә торган авырлыкларны иҗтимагый тәртипләр белән аңлату ноктасында туктап калмый. Алмазның әнисе Хәтимә апа фаҗигасен бөтен тулылыгында ача алу авырлыкларны яшәештәге, кеше гомерендә очрый торган хәлләр буларак, фәлсәфи яссылыкта күрсәтә. Рәйханга карата әйтелгән сүзләр тулаем кешеләрнең үзгәрү сәбәбен аңлатучы гомумиләштерү кебек кабул ителә. Тормыш кешеләрне авырлыклар белән сыный, гел үзгәртергә, сындырырга, бөгәргә, явызландырырга омтыла дигән экзистенциаль фәлсәфә дә ачык күренә бирелә.

Бер үк вакытта әсәрдәге файда эзләүчеләрнең дә, матурлыкка табынучыларның да — һәркайсының үз юлы, сукмагы бар. Алсу белән Алмазның танышып китүе дә шул сукмак мәсьәләсендәге сөйләшүдән башлана. Алга таба да әсәр эчендә «сукмак» сүзе кабатланып тора, ачкыч-сүз вазифасын башкара. Аның ярдәмендә автор һәркемнең язмышын үзе язуы, еш кына үз сукмагын салырга омтылучыларны адашу көткәнлеге хакында искәртә. Әле генә карап киткән сөйләшүдә Алмазның «син бит анда куакларны сындырасың, чәчәкләрне таптагансың» диюе сукмак салучылар тарафыннан башкалар матурлыгын юкка чыгару куркынычы барлыкны да билгеләп үтә.

Үзенә файда эзләүчеләрнең типик вәкиле итеп сурәтләнгән Гомәр – «практичный» кеше, ләкин һич тә тискәре образ түгел. Алсуның «аларга бу кыңгырау чәчәкләре – печән, менә бу ак каенкаем, мескен каенкаем – утын» диюе Гомәр образын тулысынча ачып бирә. Автор төрле мәдәни дөньялар, тормышка төрлечә карый торган кешеләр Хакыйкатен күрсәтә.

Беренче повестенда ук язучы уенга мөрәҗәгать итә һәм символлар, ачкыч-сүзләр, гомумән тел материалы белән «уйнап», аңланыш мөмкинлекләрен киңәйтүгә ирешә. Әсәрнең сюжет катламында яшерелгән мәгънә ике символ ярдәмендә тагын бер кат ачыклана. Анарның беренчесе

әсәрнең исеменә үк чыгарылган. Әсәр шушы символның мәгънә төсмерләрен аңлату белән башланып та китә. Автор башта ук өч күчерелмә мәгънәне тезеп сала: 1) күңел дөньясы 2) матурлык 3) кеше гомере 4) яшьлек, мәхәббәт. Шулай итеп, сюжет кысасында, беренче вакыйгада ук болынны чабуга риза түгел, адашып булса да протест белдергән Алсу язмышы кешенең гомере һәм күңел дөньясы, шуларны мәгънәле иткән матурлык, өмет, хыял, мәхәббәт яки аларның файда хакына корбан ителүен аңларга юл ача, әсәрнең фәлсәфи катламын тәшкил итә.

Символларның икенчесе – упкын. Болын-гомернең ахырында көтеп торган упкын – гомер чиге, үлем ул. Бераз соңрак күңел дөньясының томалануы яшәүдән баш тарту мәгънәсендә килә. Символның икенче мәгънәсе – кайгы. Алмазның этисе үлү хәбәрен йомгаклаучы бу өзек болын символының өмет, хыял кебек мәгънәләренә янәшә кулланыла һәм кайгының соңгыларны җимерүен сөйли. Мәхәббәтне исә хыянәт – Алмазның болынны сөрүе – упкынга ташлый. Упкын сүзе болынның тагын бер мәгънәсен – кеше гомерен белдерүе белән дә аваздаш кулланыла һәм тормышта очрый торган авырлыкларны үз эченә ала. Димәк, яшәештә ике капма-каршы чик бар: болын һәм упкын, яшәү һәм үлем, матурлык һәм файда, мәхәббәт һәм хыянәт, өмет һәм чарасызлык, ышаныч һәм ялгызлык, хыял һәм битарафлык. Шушы чикләрнең кайсыларыдыр икенче чиккә сукмак салырга да сәләтле. Беренче урынга автор мәхәббәтне чыгара. Ул упкынны юк итә. Мәхәббәт хыял, өмет бирә, хәтта сукыр кешенең дә матурлыкка күзен ача. Һәм киресенчә, мәхәббәтне югалту упкынга, барыннан да элек, битарафлыкка илтә. Шундый көчкә ия кыйммәтләрнең икенчесе – ялгызлык. Төп сюжет сызыгының иң югары ноктасына – ялгызлык авыруына дучар булган Алсу, мәхәббәтен югалткан, өмет-хыялларын җуйган кеше яңа сукмак таба. Ул - башкаларга файдалы булу. Әсәр нечкә җанлы, сизгер һәм нәзберек кешенең башкалар өчен яшәүдә тормыш мәгънәсен табуы хакында сөйли. Алсуның мәктәпкә эшкә китүе, балалар укыта башлавы укучыны ышандырмый, эстетик яктан да аның авыруы ноктасында әсәрне өзәсе, туктыйсы килә.

Лəкин автор сайлаган үзəк – башкаларга файдалы кешегə əйлəнү фəлсəфəсе – нəкъ менə тəкъдим ителгəн чишелешне сорый.

«Битлек» əсəрендə дə автор элегрəк сайланган юнəлешне дəвам итə. Лəкин биредə сюжет барлыкка китергəн тарих бөтенлəй башка. Ул көчсез кешенең усал һəм рəхимсезгə əверелү – битлек кию тарихы. Үзəк символ повестьның исеменə үк чыгарылган һəм əсəрдəге барлык геройларны да бəялəү ноктасы, сурəтлəү яссылыгы хезмəтен башкара. Уенның вазифасы да үзгə: автор кеше тормышларын – уен, яшəешне сəхнə иткəн шартлы модель төзи, шуның ярдəмендə кешенең табигый яшəү тəртибеннəн, күнегелгəн мəдəни хəяттан баш тартуын фаҗига буларак күрсəтергə омтыла. Беренче повестьтагы упкын мəгънəсе текстта берничə тапкыр кабатлана торган «ак ишек» гыйбарəсенə салынган. Төп героиня Рəшидəнең битлек киюе, димəк, сюжет сызыгындагы төп каршылыкның да сəбəбе яшəп килүче, заман китереп чыгарган киртə-авырлыкларда. Рəшидəнең битлек кию мизгеле Зиннур эшлəгəнгə хисапланып йөргəн клубка комиссия килгəч, аның чарасызлыктан хатынына мөрəҗəгать итүеннəн соң була. Чалбар детале ярдəмендə Рəшидəнең Зиннур күтəрергə тиешле җаваплылыкны үз җилкəсенə алганлыгы тагын бер кат искəртелə. Əлеге вакыйгадан соң автор Рəшидəдəге үзгəрешлəрне Зиннурдан да таныта  Рəшидəнең үзеннəн үк битлек кию сəбəбен əйттерə. Шушы урында Ф. Бəйрəмова «битлек» сүзе белəн уйнап ала, Рəшидəнең үзенə табигый халəте, хатын-кыз бəхете белəн яшəү вакыты битлек кигəн чак сыман тоела, үзендəге үзгəрешне, киресенчə, шул битлекне салып ташлау кебек кабул итə. Тормыш кешене ничек кенə үзгəртмəсен, ул моны шулай тиеш, дөрес дип саный дигəн фəлсəфи фикер уздырыла.

Сюжет үсə барган саен, Рəшидə сайлаган битлек тə алмашына тора. Рəшидə – ай нуры табигате белəн усал яки битараф кеше түгел. Рəшидə – сизгер күңелле, матурлыкны танучы һəм тормышта идеаль кешелəр, тəртиплəр эзлəүче, яшəешне камиллəштерергə омтылучы. Алсу кебек үк –ялгыз, башкалар тарафыннан аңланылмаган. Нəкъ менə Алсу, Рəшидəлəр ярдəмендə автор үзе

күрергә теләгән идеаль яшәү моделен «төзеп» куя, шуның барлыгын укучыга даими искәртеп килә.

Кешеләрнең ялгызлыгы мәсьәләсен автор ике яссылыкта хәл итә. Иҗтимагый яктан, ул Рәшидә уе, фикере буларак китерелә. Геройлар язмышы мисалында кешеләрнең җайлашу, сату, сатылуын җәмгыятьтә урнашкан кануннар һәм гаделсезлекләр нәтиҗәсе итеп күрсәтсә дә, язучы әлеге сыйфатларның, гомумән, кешегә хас булуын да искәртеп үтә. Геройларны ике капма-каршы чиккә аерып сурәтләү бу ике төрле кешеләрнең аралаша-аңлаша алу мөмкинлеген юкка чыгара.

Ялгызлыкны фәлсәфи планда хәл итү дә сюжетта, геройлар язмышында ук башлана. Асылда, биредәге геройларның барысы да диярлек ялгыз һәм бәхетсез! Ялгызлыкның яшәештә кешене озата бара торган котылгысыз халәт икәнлеге автор тарафыннан да гел кабатланып бара. Ләкин язучы әлеге халәтнең кешене рухи баетучы, уйланырга һәм кичерергә өйрәтүче булуын да ассызыклый. Татар хатыннарында ялгызлык тудырган моңның буыннан буынга тапшырылуы хакындагы искәрмә юкка гына текстка урнаштырылмаган: «Фәлсәфәсез генә тормыш алып барып та, җир өсте тулы бала, җаннар тулы моң калдырып киткән татар хатыннары...» -дигәндә язучы кешенең җирдә яшәп китү мәгънәсен дә, нәсел калдыру белән янәшә, моңны – рухи байлыкны киләчәккә тапшыру буларак ача. Поселок хатыннары рәсемен бирү, аларның җырлаган мизгелен сурәтләү ярдәмендә язучы Рәшидә образын тирәнәйтә һәм шушы урында ялгызлык тудырган кайгы-моңны фәлсәфи югарылыкка күтәрә: милләткә бәя итеп яңгырата. Биредә яшәешнең кануны: кешенең гомере ялгыз үтү, өметләр өзелә бару, яшәүнең чикләнгәнлеге кайгы һәм моң кичерергә мәҗбүр итә дигән экзистенциаль фәлсәфә бик ачык әйтелә. Ләкин җыр хакындагы монолог моның белән тәгәлләнми. Язучы кайгыны битлек артына яшерү, һәркемнең үз кайгысын үзе кичерә алу сыйфатын милләткә хас бер үзенчәлек итеп билгеләп куя.

Ир-ат күтәрергә тиешле җаваплылыкны үз җилкәсенә алып, холыкны яшерергә — битлек кияргә мәҗбүр булган Рәшидә янәшәсендә башка төрле

язмышка ия геройлар да күрсәтелә ( Әминә яки Тәзкирә Сабировна битлекне үз кәнәфиләрен саклап тоту, кулларыннан эш килмәгәнне каплау өчен кигән булсалар, Рәшит Газизовичны битлек кияргә кәнәфи мәҗбүр итә, үзенең шәхси максатларында битлек кигән Рафис Мөбәрәков). Иң мөһиме – автор бу геройларның да еш кына үзләре дә аңлап җитми торган фаҗигасен күрсәтә, үзенә файда эшләүчеләргә карата бәхет түгел, бәлки тормыштан канәгатьлек төшенчәсен генә куллану дөреслекне исбатлый. Үз-үзеңә файда эшләп кенә яшәүнең башкаларга һәм, кайчан да булса, үзеңә үк бәхетсезлек булып әйләнеп кайтачагын искәртә. Битлек кияргә тиеш булып та, шуңа көче җитмәгән Разия гомере вакытсыз өзелә. Бу образ авторга күп кенә әхлакый проблемалар күтәрергә ярдәм иткән. Аерым алганда, олы кешеләрдә һәм яшүсмерләрдәге каты күңеллелек, ятимлекнең, эшкә чумган әни кешенең баланы балачактан мәхрүм итүе һ. б. Разия образы Рәшидә фаҗигасен тулырак ачу вазифасын гына үтәргә тиеш булса да, автор аның язмышын бербөтен әһәмиятле ярдәмче сюжет сызыгы дәрәҗәсенә күтәреп, типиклаштырып бирә алган. Әсәрдә битлексез кешеләр дә бар. (Рәшидәгә капма-каршы куеп сурәтләнгән Дания һәм аны көчәйтеп килүче Зөлфия образлары). Гомеренең ахырында Рәшидә битлек киеп яшәүнең ялгыш икәнен аңлый. Ләкин язмышны үзгәртергә вакыт калмау укучыга хатын фаҗигасен үзенеке кебек кичерү мөмкинлеге бирә. Укучыга эндәшеп, язучы хатын-кызның каты күңеллегә әйләнү сәбәбен дә, битлек киюнең кеше табигатенә каршы килүен дә, битлекнең кешеләр арасына ак ишек, упкын, ялгызлык булып сузылып ятуын да кат-кат искәртә. Әсәрдә тагын бер бик отышлы алым бар: автор укучыны әсәр идеясен кабул итәргә әзерли, аның әйтеләсен гел искәртеп тора һәм повесть ахырында автор үз героинясын да шушы хакта уйланучы-борчылучы итеп тасвирлый. «Сәхнә», «уен», «битлек» кебек ачкыч-сүзләр, символлар ярдәмендә укучыга да уен-табышмак тәкъдим итә. Хикәяләүче-автор һәм төп герой сүзләренең бер-берсен дәвам итеп, еш кына керешеп китүе әсәрдәге психологизмны тирәнәйтә. Мондый урыннарда экспрессионизм алымына мөрәҗәгать итү күзәтелә: хисләр үскәннән-үсә, каршылык иң киеренке

ноктага кадәр җитә, кабатлаулар һәм детальләрне калкытып кую аша укучыга тәэсир итү мөмкинлекләре киңәя.

1990 еллар ахырына реалистик прозада **интеллектуаль тенденция** көчле билгеләнә башлады. Интеллектуаль әдәбият, фәлсәфи-психологик (Ф. Бәйрәмова), иҗтимагый (Р. Сибат, М. Кәбиров), әхлакый (Г. Гыйльманов) төсмерләр белән баетылып, мәйданга чыкты. Яшәеш, тормыш, кешегә караган универсаль кануннарны эзләп, шуларны барлап һәм укучыга тәкъдим итеп язылган әсәрләрдә автор-хикәяләүче образы беренче планга куелды.

Г. Гыйльмановның «Албастылар» әсәрендә – әхлакый кануннар, Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар»ында – галәм, тормыш фәлсәфәсе, «Алыплар илендә»сендә – дини тәгълимат, Р. Сибатның «Ялгызак» романында «татар кешесе өчен» мәҗбүри кагыйдәләр үзәккә куела. Еш кына мифка мөрәҗәгать итү табигатьтәге һәм кешедәге үзгәрмәс кыйммәтләрне аерып чыгару юлына әйләнә. Мифологик фикерләү чынбарлык һәм уйланма кушылган тормыш моделе төзүгә китерә.

Интеллектуаль башлангычның гротеск формасына, сатирик пафоска мөрәҗәгать итүе совет җәмгыятенә көчле тәнкыйть белән караган, антиутопик дөнья тудырган әсәрләр китереп чыгарды. Зөлфәт Хәким иҗаты – моның ачык мисалы. Шулай ук Ф. Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга!», В. Имамовның «Могикан» повестьларында, Т. Галиуллинның «Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар» трилогиясендә авторларның әсәрләрдә тергезелгән тормышка иронияле мөнәсәбәте вакыйгалар катламын каплап китте. Ләкин биредә массачыл әдәбият белән әзерлекле укучыга йөз тотып язылган әдәбият арасындагы аерма кимүгә бара.

Интеллектуаль башлангыч һәм шартлы-метафорик формалар белән кызыксыну артты. М. Кәбировның «Сары йортлар сере»ндә ирония чиктән тыш арттырылып, абсурд чигенә җиткерелгән һәм социалистик тормышны гротеск формасында, антиутопия итеп сурәтләү урын тапкнн. Биредә ирония кеше тормышының мәгънәсезлеге, кешелекнең юкка чыга баруы хакындагы сызлану фәлсәфәсе белән үрелә.

«Канатсыз акчарлаклар» повестенда Ф.Бәйрәмова җир һәм галәм тормышы, яшәеш хакында үзенчәлекле миф тәкъдим итеlә, кешеләр җәмгыятендәге төрлелекне аңлата торган модель корыла. Мифологик детальләр: хатынның тәрәзә ялавы, ак кош, баланың алмашынуы яшәеш хакындагы калган мәгълүматны да милли һәм билгеле, бары тик онытылган кануннар кебек кабул итәргә әзерли. Әсәрдә дин фәлсәфәсе (Гайсә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрләр, Коръән һәм Тәүрат китаплары) кешегә ярдәм итәр, аны начарлыктан, явызлыктан саклар өчен, күктән төшерелгән иман буларак аңлатыла. Динне яңадан тергезү иманга кайту, кешелек өчен үсеш юлына чыгу кебек күрсәтелә. Күктән төшкән Ак йөзнең, кешегә әверелгәч, мәчеттә хезмәт итә башлавы да әлеге фикерне көчәйтеп килә.

Әсәрдә тагын бер шартлы символик образ — йорт бар. Яшәп килгән системаның, халык өстеннән хакимлек итүнең моделе булган җиде катлы йорт – җүләрләр йорты – җәмгыятьтәге тәртипләргә тәнкыйди бәя булып аңлашыла. Шулай итеп, әсәрдә галәм, тормыш, дин, җәмгыять хакындагы фәлсәфәләр урын ала һәм аерым канун-кодлар төсендә ваклана. Язучы психологизмның иң югары алымы – аң агышы (поток сознания), автоматик язу алымы белән эш итә. Укучыга яшәешнең барлыкка килү, төзелү моделен күрсәткән, кешелекнең вак һәм пычрак тормышка кереп батканлыгын билгеләгән автор бүгенгене кире кагу ноктасында әсәрен төгәлли.

“Алыплар илендә” повестенда төп сюжет сызыгы – Камилнең дингә килү тарихы – бер канунны югары күтәрә: дин генә җәмгыятьне һәм кешене рухи юкка чыгудан коткару, камилләштерү көченә ия. Идеяне автор Алып баласы исеменнән дә әйттерә. Төп сюжет сызыгындагы чишелеш – авылны яшен сугу – гөнаһлары өчен кешеләргә җәза, апокалипсис булып аңлашыла. Сәлим бай һәм хатыны, яшь наркоманнар, Җиһангир язмышлары да шушы идеяне көчәйтеп килә. Ярдәмче сюжет сызыклары ниндидер канун-кодны, автор язмышларга яшергән тормыш кагыйдәсен ачыклый: яраткан кешең белән бергә була алмауның тормышны җимерә (Сәлимхан һәм Рәйханә мөнәсәбәтләре); мәхәббәт – теләсә нинди авырлыкларны җиңеп чыгарлык көч

(Җиһангир-Рәйханә, Камил-Камилә) Әсәрдәге мифологик катлам Алыплар турындагы риваять хыял, саташу, төш кебек бирелгән. Тарихны белмәү һәм белергә теләмәү рухи бушлыкның, кешелек үсешендә ялгыш юлга кереп китүнең бер сәбәбе төсле билгеләнә. Әсәрдә Камилнең борынгы бабалар, Алыплар дәвамчысы икәнлеге, аның ислам дине тотучы булуы ассызыклана. Камил камиллек үрнәге төсендә, аллегорик образ итеп уйланылган. Язучы аның уйлап табылган, чынбарлыктан ераклашкан булуын үзе үк әйтә. Алыплар белән очрашу вакыйгасының да төш түгеллегенә басым ясап, аның Алыплар юлын дәвам итәргә тиешле милләтнең киләчәккә китәр кешесе икәнлеген искәртә. Язучы ике катлы уен кора: бер яктан, чынбарлыктагыча урын һәм вакыт ягыннан төгәлләштерелгән күренешләрне (авылдагы вакыйгалар) махсус рәвештә ышандырмау эффекты белән өретә, ә инде гайре табигый хәлләрнең (тау ярылу, Алыплар белән очрашу) чынлыкта булуын расларга омтыла .

Г.Гыйльмановның “Албастылар” романында язучы күрсәткән өч дөньяны үзәк каршылык – Хәлим һәм албастылар каршылыгы бәйли. Ләкин һәр катлам «албасты» сүзенә үз мәгънәсен сала. Урман албастылары – гомерләрен явызлыкка явызлык белән җавап бирүгә багышлаган карчыклар, кайчандыр үзләрен авылдан куган нәселләрдән үч алучылар. Имансызлар, дөнья пычрагына буялганнар шулай ук албастыга әверелә. «Кешенең асылы менә шушы ак — кара рухлар көрәшеннән тора. Албасты ягы җиңгән кеше тора-бара, чынлап та, бер явыз хәшәрәт кыяфәте алырга мөмкин. Фәрештә ягы җиңсә, ул Ходай Тәгаләнең җирдәге рухи илчесенә әверелә». Димәк, язучының үзәк фәлсәфәсе ачык: һәр кеше ак һәм кара көрәшенә очрый, һәркемне албасты сагалый. Аңа каршы көрәшмәсәң, аны җиңмәсәң, үзең дә албастыга әвереләсең. Әсәрнең уйланмасы тормышка һәм кешегә булган традицион карашны җимерә (деконструкция). Татар әдәбиятында моңа кадәр кеше характерындагы уңай һәм тискәре сыйфатларның бер-берсен алыштырып килгән ике концепция хөкем сөрсә (беренчесе кешеләрне уңай һәм тискәрегә, ак һәм карага бүлә; икенчесе һәр кешедә ак як та, кара як та

барлыкны таныган хәлдә, теге яки бу сыйфатлар җыелмасының өстенлек алуын, доминанта булып килүен билгели), хәзер инде аларны алыштырган өченчесе тәкъдим ителә: һәр кеше үз аңындагы кара як белән көрәшергә, чистарынырга һәм рухи камилләшергә дип җиргә килә.

М.Кәбировның “Сары йортлар сере” фәлсәфи повестенда сюжеттагы вакыйгалар күп кенә иҗтимагый проблемаларны ача. Төп сюжет сызыгындагы каршылык Мәдинә карчык белән сары йортларда яшәүчеләр арасында булса, аның кабатлануы төрле проблемаларны калкытырга ярдәм итә. Беренче тапкыр «бәрелешү» җәмгыятьтә гади кешегә куркынычсыз хезмәт шартлары тудырылмау һәм табигатьнең бозылуы мәсьәләсен күтәрә. Икенчесендә кешеләрне курку хисе биләп алу хакында искәртә. Өченчесендә башкаларны рәнҗетү аерып күрсәтелә. Шул рәвешле, бу каршылыкның төрле вариацияләре кешегә һәм җәмгыятькә шактый җентекле бәя бирә. Әлеге бәяләр арасында иң калку күрсәтелгәне — кешеләрдәге коллык психологиясе. Әсәрдә ирония чиктән тыш арттырылып, абсурд чигенә җиткерелгән һәм социалистик тормышны гротеск формасында, антиутопия итеп сурәтләү урын тапкан. Биредә ирония кеше тормышының мәгънәсезлеге, кешелекнең юкка чыга баруы хакындагы сызлану фәлсәфәсе белән үрелә.

Интеллектуаль башлангычның гротеск формасына, сатирик пафоска мөрәҗәгать итүе совет җәмгыятенә көчле тәнкыйть белән караган, антиутопик дөнья тудырган әсәрләр китереп чыгарды (Зөлфәт Хәким иҗаты) Ф. Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга!», В. Имамовның «Могикан» повестьларында, Т. Галиуллинның «Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар» трилогиясендә авторларның әсәрләрдә тергезелгән тормышка иронияле мөнәсәбәте вакыйгалар катламын каплап китте. Ләкин биредә массачыл әдәбият белән әзерлекле укучыга йөз тотып язылган әдәбият арасындагы аерма кимүгә бара. Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” исеме астында нәшер ителгән өч кисәктән торган романында ирония әсәрдә сурәтләнгән тормышта кыйммәтләрнең үзгәрүен күрсәтүгә хезмәт итә. Ул геройларның монолог-диалоглары һәм автор мөнәсәбәте-бәясенең каршылыкка керүендә күренә.

Ирония әсәрнең укучы белән «гәпләшү», укучыга ниндидер «тарихлар» сөйләү кебек язылуында да чагылыш таба. Автор-хикәяләүче һәрчак соңрак булачак хәлләрне хәбәр итеп, «хәзерге»дән нәтиҗә ясап бара. Аерым бер сүз-гыйбарәләр белән уйнау да (игелек сүзе) ирония хасил итә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1990 еллар татар реалистик прозасында фәлсәфи-психологик юнәлешле интелектуаль тенденциягә Ф.Бәйрәмованың "Канатсыз акчарлаклар" фәлсәфи повесте мисалында төшенчә бирергә.

2. Интелектуаль тенденцияле реалистик прозада иҗтимагый юнәлешне М.Кәбировның "Сары йортлар сере" фәлсәфи повесте мисалында аңлатырга. Повестьта шартлы-метафорик формалар.

3. Г.Гыйльмановның "Албастылар" романы интелектуаль тенденцияле реалистик проза үсешенә йогынты ясый?

4. З.Хәкимнең "Агымсуда ни булмас?" сатирик романында постмодернистик шартлылык.

5. З.Хәкимнең "Курку" фәлсәфи повестенда постмодернистик шартлылык.

6. Т.Миңнуллинның авангард юнәлешле "Минһаҗ маҗаралары" романында постмодернистик шартлылык.

7. Т.Галиуллинның "Сәет Сакманов" ("Тәүбә", "Элмәк", "Төнге юллар") трилогиясендә шартлы-метафорик формалар.

## Тема 23. 1985-2000 еллар татар прозасында романтизм

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә 1985-2000 еллар татар прозасында романтизм, саф романтик әсәрләр (Ф.Садриевның "Кыргый алма ачысы", М.Галиевнең "Ак абагалар" повестьлары) өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** романтизм, саф романтик әсәрләр, романтик реализм.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д. Ак абагалар көе// Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.124-140.

2. Заһидуллина Д. “Сары йортлар сере” //Заһидуллина Д. Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.169-180.

3. Заһидуллина Д. Таң җилләре кебек //Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.11-26.

4. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы:**

1. 1980-2000 еллар татар прозасында романтизм.

2. Саф романтик әсәрләр (Ф.Садриевның “Кыргый алма ачысы”, М.Галиевнең “Ак абагалар” повестьлары).

Билгеле булганча, XX гасыр татар әдәбиятында романтизм юнәлеше яшәүдән туктамый, нәкъ менә шушы юнәлештә иҗат ителгән әсәрләр татар әдәбияты өчен милли, шәркый тоелучы күп кенә алымнарны саклап кала, яңадан-яңа әдәби тәҗрибәләргә мәйдан бирә. Бигрәк тә 1980 еллардан алып, романтизм яңадан күтәрелеш кичерә, классик романтизм традицияләрен дәвам итеп язылган саф романтик (рус әдәбиятында, яңадан калкып чыкканга, неоромантизм, ягъни яңа романтизм дип атау яши) әдәбият активлаша. Ф. Садриевның «Кыргый алма ачысы», М. Вәлиев «Качу», М. Галиев «Алтын тотка», «Ак абагалар» повестьлары фәлсәфи фикер-карашлар белән баетылган саф романтик әсәрләр кебек кабул ителә.

М.Вәлиев повестьларында романтизм һәм сентиментализм билгеләре үрелеп китә. Повестьларда характер буларак тулы ачылган романтик геройларны тасвирлау, бу вакытта хис һәм фикер көчеш-үзгәрешләрен үзәккә кую психологизмны көчәйтә, зәвыклы укучыга юнәлтелгән булу әсәрләрнең үзенчәлекле уйланыш-эшләнешен тәэмин итә. Фәлсәфи гомумиләштерүләр ярдәмендә тормыш-яшәешкә бәя биреп бару, символлар, кабатлаулардан иркен файдалану, янәшәлекләр һәм каршылыклар белән уйнау, укучыга да уен тәкъдим итү дә бу иҗатка хас сыйфатлар булып тора.

«Качу» повестенда төп каршылык нәкъ романтиклардагыча: хыял һәм чынбарлык арасында. Романтик герой Билалның үз эчендәге шушы каршылыкны чишүе, көчле кеше позициясенә килү тарихы төп сюжет сызыгын хасил итә. Романтизм юнәлешенә мөрәҗәгать иткән һәр язучының хыялда «качу» урыны, идеалы була. М. Вәлиевтә ул — табигать, табигыйлек. Билал, чын мәгънәсендә, романтик герой амплуасында. Эчке дөньясы бай, башкалардан да күпне таләп итүче, тормышны интуитив, сиземләп танып белүче, хис-кичерешләргә бай шәхесне язучы бала белән чагыштыра.

Ф.Садриевның «Кыргый алма әчесе» – романтик повесть. Төп сюжет сызыгын Вилданның үз эчендәге каршылык барлыкка китерә: ул — эгоизм, үз-үзеңне ярату. Вилданның Әнвәрәне һәм үз-үзен яратуы арасында бәргәләнүе, шул сәбәпле мәхәббәтен югалту тарихы артистлар тормышы

фонында тасвирлана. Ярдәмче сюжет сызыклары өчәү: Вилдан — Әнвәрә сызыгы — мәхәббәт тарихы; Әнвәрә -Мансур сызыгы — гаилә тарихы; Әнвәрә — Нәсимә сызыгы -дуслык тарихы. Әлеге ярдәмче сюжетлар, бер яктан, Әнвәрә һәм Вилдан характерын тирәнрәк ачарга ярдәм итә, икенче яктан, ике төрле тормыш моделе төзүдә катнаша. Әнвәрәгә гашыйк булса да, Вилдан аны тамашачының яратуын кичерә алмый: йә мин, йә сәхнә дип шарт куя. Мәхәббәт хакына корбан таләп итү – беренче модель, ул мәхәббәтнең юкка чыгуына, ике кешенең бәхетсезлегенә китерә. Мансур исә, киресенчә, яраткан кешесе мәнфәгатьләрен беренче планга куя. Әнвәрә белән Нәсимә дуслыгында да шушы сыйфат доминанта ролен үти. Нәтиҗәдә икенче модель – мәхәббәттә үз-үзеңне «онытып», башка кешене ярату, аны аңларга һәм сакларга тырышып яшәү варианты пәйда була. «Кыргый алма әчесе» гасырлар чиге әдәбиятында романтик традицияләрне тергезүнең бер үрнәге булды. Язучы әсәрдә чын мәгънәсендә гүзәл ике романтик тип иҗат итә. Аларның талантлы һәм хис кешеләре (артистлар) итеп уйлануы, чыннан да талант ияләре һәм матур кешеләр кебек тәкъдим ителеше татар романтик әдәбияты өчен традицион. Әнвәрә – ялкын, ут. Намуслы, сизгер күңелле һәм хис белән яшәүче кызның холкы, әлбәттә, мәхәббәт һәм яраткан хезмәте арасында сайлау ноктасына куелганда, сәхнәдән баш тарта алмавын ышандырырлык итеп аңлата. Әнвәрә – талантын башкалар белән уртаклашып яшәү өчен яратылган кеше. Вилдан – аның капма-каршысы. Салкын, кешеләрдән читтәрәк, аларга югарыдан карап яшәүче артист һәм моңлы тавышка ия җырчы, рәсем остасы Вилдан талантын үзенең эгоистлыгын канәгатьләндерүгә файдалана, һәрчак беренче, сәхнә түрендә берүзе булырга омтыла. Вилдан – татар әдәбияты өчен традицион булмаган романтик тип, дия алабыз.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1.1980-2000 еллар татар прозасында романтизм.

2.Ф.Садриевның “Кыргый алма ачысы” повестенда романтик шартлылык.

3.М.Галиевнең “Ак абагалар” повестенда романтик алымнар.

4.М.Галиевнең “Алтын тотка” повестенда романтик алымнар, фәлсәфә сайланышы.

**Лекция 2**

**Аннотация.** Лекциядә 1985-2000 еллар татар прозасында романтик реализм (Ә. Сәлахның “Соңгы вальс”, М.Кәбировның “Мәхәббәтән җырлар кала” повестьлары) өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** романтизм, саф романтик әсәрләр, романтик реализм.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д. Ак абагалар көе// Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.124-140.

2. Заһидуллина Д. “Сары йортлар сере” //Заһидуллина Д. Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.169-180.

3. Заһидуллина Д. Таң җилләре кебек //Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.11-26.

4. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы.**

1. Романтик реализм: Ә Сәлахның "Соңгы вальс" повесте.
2. М.Кәбировның "Мәхәббәтән җырлар кала" повесте.

Гасыр ахырында иҗтимагый катлам әһәмиятле роль уйный торган, ситуацияләр иҗтимагый-тарихи да, психологик та мотивацияләнүче, романтик реализм төшенчәсенә туры килерлек әсәрләр иҗат ителә (Ә. Салахов «Соңгы вальс», М. Кәбиров «Мәхәббәттән җырлар кала»).

М. Кәбиров «Мәхәббәттән җырлар кала» повестенда реалистик катламдагы хәл-вакыйгаларны романтик алымнар ярдәмендә бәяләп бара. Әсәр Кыям абзый җыры белән башланып китә, һәм шушы җыр булачак вакыйгаларның характерын билгели. Җырга һәвәс Кыям турында сөйләгәндә, автор аны «стандарт булмаган» герой дип тамгалый. Әсәр барышында очрашкан башка геройлар: Гөлзилә яки Таһир да, комендант Нәфисә һәм Ришат белән Гүзәл дә – шулай ук үзгә, талантлы, яктыкешеләр. Ләкин талант – автор аңлатуында якты кеше булу өчен иң кирәкле сыйфат түгел. Әхмәт Сабиров, Нурияләр мисалында әхлакый якның әһәмиятле булуы күрсәтелә. Төп героинядагы мәхәббәткә тугрылык сыйфаты югары күтәрелә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. Романтик реализм агымына Ә Сәлахның "Соңгы вальс", М.Кәбировның "Мәхәббәтән җырлар кала" повестьлары мисалында аңлатма бирергә.

## Тема 24. 1985-2000 еллар татар прозасында тәнкыйди катлам

**Лекция**

**Аннотация.** Лекциядә XX гасыр ахыры прозасында шәхес культы фаҗигаләрен тасвирлаган әсәрләр (М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” (1967-84), Г.Тавлинның “Афәт”, А.Гыйләҗевның “Йәгез бер дога!” романы (1991-93), Р.Кәраминең “Каргышлы этаплар”, И. Сәлаховның “Колыма хикәяләре” (“Тайгак кичү”, 1957-81 романнары), Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” трилогиясен, замана фаҗигаләрен тасвирлау, Ф.Садриевның «Таң җиле» романы өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** роман, трилогия.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**


1.Заһидуллина Д. Замана балаларын сурәтләү // Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.158-168.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Минһаҗева Л. И.Салахов / Л.Минһаҗева. – Казан: Матбугат йорты, 1995.– 176 б.


**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли таныпбелү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы.**

1. Гасыр ахыры прозасында шәхес культы фаҗигаләрен тасвирлаган әсәрләр (М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” (1967-84), Г.Тавлинның “Афәт”, А.Гыйләҗевның “Йәгез бер дога!” романы (1991-93), Р.Кәраминең “Каргышлы этаплар”, И. Сәлаховның “Колыма хикәяләре” (“Тайгак кичү”, 1957-81 романнары).

2. Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” трилогиясендә җәмгыятькә көчле тәнкыйть белән карау, замана фаҗигаләрен тасвирлау.

3. Ф.Садриевның «Таң җиле» романы: дискурс төре.

Соңгы еллар татар прозасында неореализм («яңартылган реализм») шәхеснең кыйммәтен ассызыклаган хәлдә, традицияләргә тугры калып, иҗтимагый тормышка аерым игътибар бирә. Әсәрләрдә чор картинасын тудыру, заман, хакимият, системаның бөтенлекле образын укучы күз алдына бастыру максаты әйдәп бара. Реалистик әсәрләр ярдәмендә татар язучылары татар халкы үткәненең аерым бер дәверләре сурәтен яңадан тергезергә (1920—1930 еллар фаҗигасе – Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» романында, 1980—1990 еллардагы ялганга корылган хакимият системасы – Ф. Садриевның «Таң җиле» һәм «Бәхетсезләр бәхете» романнарында, үзгәртеп кору дәвере Ф. Сафинның «Биек тауның башларында» әсәрендә һ. б. үзәктә тора). Авторлар үзләре дә җәмгыятьнең яки җәмгыяви бөтенлекнең вәкиле булып аңлашылалар, шул бөтенлектәге әхлакый кануннарны алга куеп, үткәннәргә бәя бирәләр.

Гасыр ахыры прозасында шәхес культы фаҗигаләрен тасвирлаган әсәрләр аерым урын тота. М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” (1967-84), Г.Тавлинның “Афәт”, А.Гыйләҗевның “Йәгез бер дога!” романы (1991-93), Р.Кәраминең “Каргышлы этаплар” әсәрләре керә.

Татар прозасында бу теманы ачык текст белән яктыртуны И. Сәлахов “Колыма хикәяләре” (“Тайгак кичү”) (1957-81) әсәре белән башлап җибәрә.

И.Салахов үзе алдында торган бурычның бөтен җаваплылыгын тоеп эш итә: “... ул – синең язмышың гына түгел, ә меңләгән, йөз меңләгән хаксыз һәлак булганнарның фаҗигасе”. Әсәрнең структурасы А.Яхин тарафыннан әсәрдә сурәтләнгән фаҗига-хакыйкать өлешен өчкә бүлү  кебек тәкъдим итела. Галим фикеренчә, романда өч төрле фаҗига сурәтләнә:

“1.Хакыйгатькә ирешү *шәхес фаҗигасенә* әверелә.

2. Бер гаепсез кешеләрнең көн дә исән калу өчен тырышуы һәм меңәрләп, миллионлап үтерелүе – *халык фаҗига (социаль фаҗига).*

3. Ил фаҗигасе *(сәяси фаҗига).* Күпме генә интектермәсеннәр , асыл ирләр тоткында да асыл булып калалар”.

Җәмгыятькә көчле тәнкыйть белән карау, замана фаҗигаләрен тасвирлау Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” дип исемләнгән өч кисәктән торган романында дәвам итерелә. Романнарда җинаятьләр, үтерешләр үзәккә куела. Җәмгыятьтәге явызлык — трилогиянең үзәк мотивы. Автор соңгы еллар тарихи чынбарлыгының гариплеген абсурд логикасы ярдәмендә ачарга омтыла. Мондый җәмгыятьтә көрәшчеләр һәм геройлар – әлеге явызлыкны тудыручыларга, күбәйтүчеләргә; гөнаһсызлар, «балалар» корбанга әвереләләр. Биредә бердәнбер уңай герой – авторның шушы җәмгыятькә мөнәсәбәте, тәнкыйте, шушы-хәлләрне акыл аша уздырып, уйланырга чакыруы, гөнаһсыз корбаннар өчен сызлануы. Иң әһәмиятлесе: җәмгыятьтәге гарип кануннар, әсәрдә геройлар «ачкан», төшенгән хакыйкать төсендә, билгеләп-күрсәтеп барыла.

Реализмга карашны киңәйтеп җибәргән Ф.Садриевның «Таң җиле» романы (1993 елны дөнья күрә) әдәбиятта шәхсилек белән чикләнмәгән көчле характерлар тудыру, аларны гомумкешелек сыйфатларын калкытып типиклаштыру мөмкин булуны ассызыклады. Реалистик әсәр тәнкыйди һәм социалистик реализм, авыл прозасы традицияләрен истә тота. Нәтиҗәдә Нуриасма кебек бик тә үзенчәлекле герой мәйданга килә. Бер яктан, ул – коллектив кешесе, хезмәт кешесе, үзенә һәм якыннарына да, читләргә дә таләпчән. Шушы ягы белән замандашлары  – гомер буе эшли-эшли гарипләнеп

беткән, үзләре өчен берни дауламаган, тормыш авырлыгыннан зарланмаган Маһинур, Разыя, Гыйзденисалардан аерылып тора. Әхлакый сайлау ноктасына китерелгән, үзенең рухи көчен күрсәтергә тиеш бу герой әхлакый эзләнүләрне иҗтимагый яктан нигезли, аңлата да. Тирә-юньдәгеләргә файда китерү, кешеләргә хезмәт итү идеясен алга куеп, Нуриасма кебекләр җәмгыятьне үзгәртү юлын әхлакый камилләшүдә, үзен түгел, беренче чиратта башкаларны камилләштерүдә күрә, үзләре исә судья, кырыс хөкемдар хәлендә сурәтләнә. Язучы реалистик әдәбиятның мәгърифәтчелек, «мөгаллимлек» традицияләрен дәвам итә, эш-гамәлләрне бәяләүдә әхлакый кыйммәтләрне алга чыгара, теге яки бу геройга, вакыйгага берничә вазифа йөкли. Нәкъ менә иман-намус өлкәсендәге ялганның иң начар, иң әшәке ялган булуын ассызыклый: Нуриасма үзе үлгәндә дә кодагыена кайтырга рөхсәт бирми. Икенче гафу ителмәслек сыйфат – башкаларны рәнҗетү, аларга белә торып начарлык эшләү.

Әсәрдә тәнкыйди башлангыч тирән, язучы ялганның тамырларын, сәбәпләрен ачарга омтыла. Ретроспекция алымына мөрәҗәгать итеп, укучыны Нуриасманың яшь чагына алып китә. Ул чакта ук әхлакый кыйммәтләр алышынган, хакыйкать урынын икейөзлелек биләгән икән. Газия бала табып, аны ташлап китә — ак йөз белән яши. Аның баласын алып үстергән Нуриасма кыенлыклар күрә. Ялганның ни өчен тамыр җәюе, ни өчен тормышны тулысы белән колачлап алуы исә кешеләрдәге коллык психологиясе белән ризалашу һәм сабыр итүдә дип аңлатыла.

Вакыйга-хәлләрнең тарихи-закончалыклы бирелүе, җәмгыятьнең билгеле бер хәл-халәтенә бәйләп куелуы белән беррәттән, дөньяның – үзгәрештә, кешеләр фикер-карашының үсештә бирелүе, вакытның үткән – бүген –киләчәк кысаларында – өзеклексез тергезелүе әсәрдәге фәлсәфи башлангычны тирәнәйтә. Төп сюжет сызыгында каршылык чишелгәндә, тирә-юньдәгеләр Нуриасманың хаклы булуын, чын хакыйкатьне таный. «Таң җиле» дип исемгә чыгарылган гыйбарәнең бер мәгънәсе дә хакыйкать кебек аңлашыла: таң җиле кебек килеп, бәреп керә дә, яшәешне сафландырып,

күзләрне ачып җибәрә икән ул!. Гыйбарәнең икенче мәгънәсе – гомер. Таң җиленең төрлесе булган кебек, кеше язмышлары да төрле.

Әсәр ахырына хакыйкатьне яклау миллилекне саклау белән дә янәшә, тигезләп куела. Совет чынбарлыгы үстергән һәм тәрбияләгән булса да, Нуриасма – ышанып һәм табынып яшәүче, ул – Табигатькә, Туган җиргә, Хезмәткә, Хакыйкатькә изге дип караучылардан. Бу буын киткәч, авылда мондыйлар калмый. Язучының сагышлануы да шуның белән бәйле.

Авторның дөньяга карашы, фикер-мөнәсәбәте үзәк герой аша белдерелгәнгә, аның уйланулары еш кына публицистик төс ала. Автор һәм герой тыгыз мөнәсәбәттә, үзара аңлашу халәтендә тора кебек. Бер яктан, язучы үз героен объектив сурәтләргә омтыла, аның ялгышларын, хаталарын да читкә куймый. Икенче яктан, аңа үзенең фикерләрен бирә, аларны белдерергә мәҗбүр итә.

Әсәрдә фәлсәфи мотивларның киң бирелә. Әсәр Рәмзинең үлеме һәм аннан соң яшәү, Нуриасманың тормышы һәм үлеме арасында, экзистенциаль чикләрдә тирбәлә. Чор, дәвер проблемаларын гомумкешелек кыйммәтләре белән тоташтыру омтылышы ясала. Әсәр башында, Нуриасма таңны каршылаган вакытта, кеше һәм табигать бербөтен итеп күрсәтелә, табигать җанландырылып, әйтерсең аларның бер үк кануннарга буйсынып яшәргә тиешлеге искәртелә. Нуриасманың үлем алды минутларын һәм үлемен сурәтләгәндә, бу фәлсәфә тагын да үстерелә. Язучы кабат «таң җиле» төшенчәсенә мөрәҗәгать итә. Төшенчәнең элегрәк кеше гомере мәгънәсендә кулланылуы белән кушылып, Яшәеш хакында күзаллау бирелә: яшәү, гомер итү җир йөзенә җылы бирү өчен кирәк. Шушы җылы — тереклекнең чыганагы, тамыры. Яшәү мәгънәсе – җылы бирү, җылы калдыруда!

Тагын бер мәгънәдә – кешенең ышану, табыну ноктасы, Илаһи мәгънәсендә кабатлап, язучы әлеге фикерне тагын да тирәнәйтә. Кешенең гомере генә түгел, үлеме дә җылы калдыра, калдырырга тиеш, ди. Шул рәвешле, тормыш, яшәүнең өзлексез яңару, дәвам итү теориясе ачыклана:

җанияләренең гомере, үлеме тереләр өчен кирәк, алар калдырган җылы Яшәешне саклап килә.

Әсәр ахырында ана үрдәккә ату вакыйгасы Нуриасманың үлеме белән аваздаш бирелә. Бер яктан, ул язучының җан ияләрен тигезләп кую фикерен дәвам итә. Моннан тыш, дөнья яралуы (үрдәкнең диңгез төбеннән балчык чыгарып җир булдыруы) хакындагы мифны искә төшереп, һәр кешенең үлемен тормышның юкка чыгып яңадан барлыкка килүе дәрәҗәсендәге мөһим хәл кебек бәяли. Җирне бар иткән үрдәкне һәм Нуриасманы янәшә кую героиняны тереклек анасы баскычына күтәрә, аның бәһасе-кыйммәтен тагын да арттыра. Әсәрнең сагышлы, сентименталь пафосы, көе, шул пафосны барлыкка китерерлек итеп сайланган теле безне фәлсәфи катламны кабул итәргә әзерли. Романда укучыны «ияртеп бара» торган нәни Марат образы, аның авызыннан әйттерелгән гыйбарәләр – язучының табышы.

Шулай итеп, «Таң җиле» романы – татар әдәбиятында традицион юнәлешне дәвам итүче әсәр. Романның уңышы, әлбәттә, төп героиняны тудыру осталыгына барып тоташа. Тормышка актив мөнәсәбәттәге, көрәшче, үз хакыйкатенә тугры Нуриасма схематик образ түгел, бәлки һәр кешегә хас хисләргә ия, ялгышулардан азат булмаган шәхес, чын мәгънәсендә соклангыч характер. Психологик башлангычның калку бирелүе, язучының психологизм алымнарын киң куллануы әсәрнең хисси тирәнлеген, лиризмын арттыра.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. Гасыр ахыры прозасында шәхес культы фаҗигаләрен тасвирлаган әсәрләр: М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” (1967-84) романында көчле шәхес концепциясе.

2. А.Гыйләҗевның “Йәгез бер дога!” романы (1991-93): фаҗига темасының милләт язмышы контекстында бирелеше.

3. И. Сәлаховның “Колыма хикәяләре” (“Тайгак кичү”, 1957-81) романында хакыйкать бирелеше .

4. Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” трилогиясендә җәмгыятькә көчле тәнкыйть белән карау, замана фаҗигаләрен тасвирлау.

5. Ф.Садриевның «Таң җиле» романын анализлау барышында дискурс төрен дәлилләргә.

## Тема 25. 1985-2000 еллар татар прозасында хикәя жанры

**Лекция**

**Аннотация.** Лекциядә романтик һәм сентименталь башлангычлы хикәяләр (И. Иксанова «Телефон», М. Кәбиров «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше» һ. б.) һәм постмодернистик алымнарга бай хикәяләр (М.Кәбировның «Дүртенче үлчәм» һәм «Канатлы кеше» һ.б) өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** хикәя, сентименталь башлангыч, постмодернистик алымнар.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д. “Сары йортлар сере” / Д.Заһидуллина //Яңа дулкында. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.169-180.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Глоссарий.**

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Мотив** - әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Лекциянең планы.**

1. Романтик һәм сентименталь башлангычлы хикәяләр (И. Иксанова «Телефон», М. Кәбиров «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше» һ. б.)

2. Постмодернистик алымнарга бай хикәяләр (М.Кәбировның «Дүртенче үлчәм» һәм «Канатлы кеше» һ.б).

Гасыр ахырында хикәя жанрында, кешенең бөеклегенә дан җырлап, кеше хисенең сафлыгы һәм тирәнлеге югары күтәреп язылган әсәрләр (И. Иксанова «Телефон», М. Кәбиров «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше» һ. б.) шактый.

М.Кәбировның «Дүртенче үлчәм» һәм «Канатлы кеше» – тулысы белән шартлы, татар әдәбияты өчен модерннан соң (постмодернистик) кулланыла башлаган алымнарга бай әсәрләр.

«Дүртенче үлчәм» – мәхәббәт хакында, мәхәббәтнең олылыгына мәдхия булып яңгырый. Хикәядә вакыйгалар үстерелеше түгел, хис-кичерешләр көчеше үзәккә куелган. Әсәр лирик-эмоциональ дулкында язылган, ир белән хатынның сөйләшүе шулкадәр җылы һәм самими, нәкъ менә шул сөйләшү кеше күңеленең бай һәм тирән булуын күрсәтә. Сөйләшү һәм хис үсешен күзәтеп бару – автоматик язу алымы – хикәяләүченең алар халәтен бәяләве белән үрелеп бара. Айны, йолдызларны кабызу, яшьлеккә кире кайтырга омтылу татар халык җырлары белән ассоциациягә керә.

“Канатлы кеше” хикәясе күнегелгән күзаллауны юкка чыгара, моны хикәяләүче дә ассызыклап бара. Максат кую гарип кешене тормышка

кайтара, сөйләшергә, йөрергә өйрәтә. Хикәя кешенең мөмкинлекләре турында. Беренче хикәядәге кебек үк, «Канатлы кеше»дә дә дуслык һәм гаилә шәхес өчен терәк, иң олы кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә. Язучы бу фикерне кат-кат, төрле яссылыкларда кабатлый. Хикәяләр якты, кешенең бөеклеге, кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрнең матурлыгы хакында сөйли. Шуңа ышандыру өчен, шартлы дөнья моделе тудыра, чиктән тыш арттырып кына калмый, күнегелгән тормыш кагыйдәләренең хакыйкать булуын шик астына ала. Бу әсәрләрдә тормыш фәлсәфәсе татар укучысы өчен якын лирик-эмоциональ башлангыч белән кушылып бирелә. Моның өчен эпик сөйләм шигъри тел чаралары белән аралаша. Эстетик яктан камил, тәэсирле, романтик пафос белән сугарылган, шартлы сурәтне әдәби концепция максатларында кулланучы хикәяләр татар әдәбиятына яңа сулыш бирүче каләм остасы килгәнлекне хәбәр итәләр.

Шул рәвешле, татар әдәбиятында хикәя үзгәрешләргә иң сизгер жанр булып кала.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. Гасыр ахырында хикәя жанрында, кешенең бөеклегенә дан җырлап, кеше хисенең сафлыгы һәм тирәнлеге югары күтәреп язылган романтик һәм сентименталь башлангычлы хикәяләрне атагыз.

2. М. Кәбиров «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше» хикәяләрендә постмодернистик алымнар.

## Тема 26. 1985-2000 еллар татар поэзиясе

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә 1980-2000 нче еллар татар поэзиясенең төп үсеш тенденцияләре билгеләнә, XX гасырның 90 нчы елларында поэтик үсешне тәэмин иткән төп алшартлар ачыклана, реализм иҗат юнәлешенең чор поэзиясе кысаларында үсеш-үзгәреше өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** поэзия, дискурс, реализм, романтизм, тенденция, тематика.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Галиуллин Т. Шигърият офыклары / Т.Н.Галиуллин // Татар шигрияте: 1980-2000 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б.4-30.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.428-435

4. Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.3: В конце века (1986-1990-е годы): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 160с.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

6. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. – Б.217-263.


**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Лекциянең планы**.

1. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре.
2. 1990 нчы елларда поэзиядә борылыш, аның алшартлары.
3. Әлеге дәвер татар поэзиясендә милли тематика.
4. Реализм иҗат юнәлешенең чор поэзиясе кысаларында үсеш-үзгәреше.

XX-XXI гасыр чикләрендә Г.Морат, Сөләйман, Р.Сүлти, Р.Зәйдуллаларбуыны шигърият мәйданында “ат уйната”, традицияне яшьрәк буын шагыйрьләргә тапшыра.Сиксәненче елларның икенче яртысыннан милли мираска мөнәсәбәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә халыкның үз үткәне, мәдәни байлыгы белән кызыксынуы арту, моңа кадәр күләгәдә калып, күренми яткан әдәби катламнарның ачылуы,татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңарыш шигъриятттә яңа сыйфатларның алга чыгуына юл ача.Туксанынчы еллардагыфикер төрлелеге, азатлык, хөррият җилләре һәм төрлечә карашлар сыешуы шигъриятттә күренешләрне яңачарак бәяләргә, сурәтләргә, матурлыкны үзгә эчтәлектә, калыпта яктыртырга мөмкинлек бирә. Болар, сүз сәнгатенең башка төрләре кебек үк, поэзиянең дә бөтен яссылыкларда – эчтәлек һәм форма ягыннан - эзләнүләр юлына керүенә этәргеч була.

Яңарыш традицияләрне дәвам итеп үсү-үзгәрү, тема-проблематик яктан төрлеләнү, яңа сукмаклар эзләү, иҗади тәҗрибәләр ясап карау, фәлсәфи яктан тирәнәю, иҗтимагый тормыштагы күренешләрне дә кешелек, яшәеш кыйммәтләренә бәйләнештә ачарга омтылу белән билгеләнә. Әлеге дәвер

шагыйрьләрнең иҗат принципларын, кыйммәтләрне яңадан күздән кичерүе ягыннан үзенчәлекле. Хәзерге татар поэзиясендә бер тенденция төсендә иҗат юнәлеше, агымнарының төрлелеге күзәтелә: реализм, романтизм иҗат юнәлешләре белән янәшәдә модернистик билгеләрне үзенә сеңдергән шигъри әсәрләр иҗат ителә, постмодерн алымнары да кулланыла. Галимнәр синтезлык сыйфатының, кушма характердагы билгеләрнең әдәбиятның бер этаптан башкасына күчү чорында еш очравын билгели. Бу чор шигъриятендә дә стильләр, жанрлар, иҗат юнәлешләренең синтезы урын ала.

Идея-эстетик, сәнгати үзенчәлекләр ноктасыннан якын килгәндә, 1980-2000 нче еллар поэзиясенең үз эчендә ике үсеш баскычын үтүе ачыклана: 1990 нчы еллар һәм соңгы еллар шигърияте. 1990 нчы еллар шигъриятенә милләт язмышына, дәүләтчелегенә мөнәсәбәтле фикер әйтергә омтылу, гражданлык, сәяси лириканың активлашуы, иҗтимагый функциянең көчле булуы хас булса, соңгы елларда фәлсәфи гомумиләштерүләр, яшәү мәгънәсенә, яшәү кыйммәтенә мөнәсәбәтле уйланулар алга чыга, шуңа бәйле фәлсәфи лириканың активлашуы, стильләр төрлелеге, иҗтимагый функциянең әкренләп эстетик функция белән алышына баруы күзәтелә.

Поэтик әсәрләрнең бер бәйләмен татарның бәйсезлеге, киләчәге, язмышы, үткәне өчен сызлану берләштерә, милли эчтәлеккалку бирелә. Бу төркем шигырьләрдә символик образ, метафора, детальләргәмөрәҗәгать ителсә дә, алдагы чорлар белән чагыштырганда, милләт язмышы хакындагы фикерне турыдан-туры белдерергә омтылу алга чыга, үзгәртеп кору биргән мөмкинлектән файдаланып, фикер әйтеп калу теләге көчәя, эзоп теле икенче планга күчә. Шуңа бәйле төстә 1990 нчы елларда гражданлык, сәяси лирика үсеше күзәтелә, Г.Морат, Рәш.Әхмәтҗанов һ.б. иҗатларында публицистик поэзия үрнәкләре урын ала.

Милләт язмышы хакындагы фикерләр аеруча реалистик юнәлештәге шигырьләрдә актив. Мондый әсәрләрдә татар халкының ачы язмышы (лирик герой язмышы еш кына милләт язмышына берегеп китә), табигатьтән аерылу, аңа саксыз мөнәсәбәтнең ахыр чиктә кешегә фаҗига булып кайтуы төп

мотивлар буларак ассызыклана, милли эчтәлек калку билгеләнә, шәхес-система, лирик герой – җәмгыять каршылыгы, иҗтимагый детерминация саклана.

Р.Фәйзуллинның “Туган тел турында бер шигырь”, Ш.Галиевның “Кирәк безгә”, Зөлфәтнең “Туган тел хакында”, “Җаннарга тия шул”, “Татар теленең каргышы”, “Илем”, Р.Зәйдулланың “Халкым минем төнгә кереп бара”, “Урыс кышын озату”, Ф.Яхинның “Татарым”, Р.Аймәтнең “Тәрәзә”, Ә.Гаделнең “Теләк”,“Кияүгә чыга татар”, Илдус Гыйләҗевның “Горурлыгым”, З.Мансуровның “Төрмә эчендәге читлек” һ.б. шигырьләрендә шундый мотивлар калку. Җәмгыятьтәге, халык тормышындагы вакыйга-хәлләр нәтиҗәсендә туган хис-кичереш аша авторларның җәмгыятьтәге тәртипләргә һәм кагыйдәләргә мөнәсәбәте, ягъни гражданлык позициясе ачыла. Мәсәлән, Г.Афзалның “Без татарлар” шигырендә татарларның буйсынып яшәргә мәҗбүр ителүе, кысылып көн күрүе лирик герой күңелендә сагыш хисен уята:

*Без татарлар дөнья йөген*
*Бергә-бергә күтәргәнбез,*
*Кичә генә кызыл идек,*
*Бүген менә күгәргәнбез.*

*Без татарлар тугыз милләт*
*Арасына кысылганбыз,*
*Кичә генә динсез идек,*
*Бүген, шөкер, мөселман без.*

З.Мансуровның “Төрмә эчендәге читлек” шигырендә символик, метафорик образлар тезмәсе итеп төрмә, читлек һәм кош образлары алына. Читлек эчендә бәргәләнгән кош образында бәйсез, хөр булып яшәргә хыялланган татар халкы гомумиләштерелсә, төрмә хөкем сөргән система, коллыкны максат иткән идеологияне символлаштыра, соңгысының асылын ачып бирүгә кан эчүче черки, тәмуг, иблис авы кебек метафора, чагыштырулар да ярдәмгә килә. Шундый халәттәге тормыш-яшәеш, үз чиратында, лирик герой күңелендәге сызлануга сәбәп төсен ала:

*Ишеттереп тора өшеттергеч*
*Тимер ишекләрнең чың-шавы,*
*Утырасың хөкем ителмичә,*
*Менә нинди язмыш сынавы.*

1960-80 нче елларда укучысын романтик рухлы, фәлсәфи эчтәлекле әсәрләре белән куандырган И.Юзеевның да милли эчтәлекле әсәрләрендә реалистик алымнар, иҗтимагый эчтәлек өстенлек ала. Аның “Сагышлы мирас” шигырендә милләтнең үткәннәргә лаеклы төстә алга бармавы, ваклануы, төрле тарафларга чәчелүе лирик геройны борчуга сала. Татар халкы / Алыплар янәшәлеге милләткә хас сыйфатларны калкытып куя, Алыплар метафорасы татарның тарихи аренадагы роле, батырлыгы, баш имәве, рухи югарылыгы булып укыла. Автор милләтнең алга таба сакланышын бөек уллары белән бәйләп куя:

*Булганбыз без эре халык, тере халык.*
*Гасырларны кичә-кичә вакланганбыз.*
*Ваклансак та, без һаман да рухи Алып:*
*Тукай булып, Сәйдәш булып сакланганбыз...*
*Ак син, җырым, Әтил сыман дулкынланып,*
*Тыңла, бала, шул дулкынны уйга талып.*
*Бабаң менгән рухи үрдән төшә күрмә,*
*Төшә күрмә, Алыплардан калган халык!*

Поэзиядә милләтнең үткәне, бүгенгесенә мөнәсәбәттә туган тел язмышы мәсьәләсе калка, туган телнең киләчәге өчен борчылу мотивы Зөлфәтнең “Татар теленең каргышы”, “Туган тел хакында”, “Имансызлар”, Р.Фәйзуллинның “Туган тел турында бер шигырь” һ.б. шигырьләрдә үзәккә алына. Мәсәлән, Зөлфәтнең “Татар теленең каргышы” шигыре туган телне бозучыларга, кимсетүчеләргә карата кискен бәя булып ишетелә. “Имансызлар” шигырендә туган телнең кадере булмау, аны бозып сөйләү, милләтнең ваемсызлыгы, яшь буынның телгә саксыз мөнәсәбәте лирик герой күңелендә әрнү хисен уята:

*Туган телне ыштыр итүчеләр*

*Җир җимертеп бәйрәм иткәндә,*

*Газиз Сүзкәй, урын кала сиңа*

*Тирәннәрдә бары, үткәндә...*

*Кулларында кастет уйнаганда,*

*Уйнаганда телдә "мат" кына,*

*И Туган тел! Коткар син аларны,*

*Чоңгыллардан чыгар яктыга!*

"Телләрдә мат уйнау", чоңгыл, кастет кебек гыйбарә, образ-детальләр яшь буынның яшәү рәвешен, ямьсезлекне юлдаш итүен ачып сала һәм туган тел, милли хис туры юлга күндерүче, коткаручы сыйфатында алга чыга.

И.Юзеевның "Хакыйкатьне тулы ачалмыйча..." шигырендә идеологиягә бәя лирик герой кичерешләре аша тәгәлләшә, ул курку, цензорлык кебек сыйфатлардан җыела. Үз буынының яшәешен сурәтләп, лирик герой җәмгыятьтәге тәртипләргә, кануннарга тәнкыйди бәясен үткәрә:

*Хакыйкатьне тулы ачалмыйча,*

*Шигърияттә гомер уздырдык.*

*Канга гына түгел, җанга сеңгән*

*Курку, үз-үзеңә цензорлык.*

Шагыйрьнең "Туйдым икейөзлелектән..." шигырендә олылар дөньясы – балачак оппозициясе тудырыла, икейөзлелек, алдау-алдану, куштанлык, җаннарның, аңнарның тупаслануы аша олылар дөньясы тергезелә, балачак исә сафлык һәм ихласлык кебек сыйфатлардан җыйнала. Ике дөнья – кеше гомеренең ике чигенең - каршылыкта сурәтләнүе аша автор үзенең идеясен уздыра: кешене җәмгыятьтәге тәртипләр, мөнәсәбәтләр үзгәртә, "алыштырып куя, сүтеп кора", ул аны үзгәртә алмавы белән чарасыз. Шушы фикер шигырьгә сызлану рухын алып керә, фәлсәфи уйланулар иҗтимагый эчтәлек белән кушыла:

*Мин анда кайттым бугай дип*

*Уйларга гына кала.*

*Җаннар, аңнар тупаслана,* -

*Шәфкатьсез тормышыбыз.*

*И нәниләр, балалыктан*

*Китмәскә тырышыгыз...*

Г.Моратның “Чорлар буйлап яманатлар чаба...” шигыре дә шушы юнәлештә. Ялган – хакыйкать оппозициясенә таянып, автор хакыйкатьне кешелекне саклап калу баскычына күтәрә:

*...Ашыкмый шул Хаклык.*

*Ә шулай да*

*Кешелекне калыр ул саклап..*

Бу юнәлештәге әсәрләрнең бер төркеме тарихи тема тирәсенә берләшә. Бу тема Г.Афзалның соңгы еллар лирикасында актив. Шагыйрь милләт азатлыгы, татар телен үстерү, гадәт-традицияләрне саклап калу, милләт бәхете өчен көрәш, тарихи-мәдәни хәтерне торгызу кебек мотивларны алгы планга куя. “Болгарлар”, “Сармат җиле”, “Алтын Бөртек”, “Тарих мең дә” кебек шигырьләрендә ул ерак тарихны бүгенге көн югарылыгыннан килеп бәяли, аның серләрен ачырга омтыла. Идеология тарафыннан хаксызга рәнҗетелгән Алтын Урда, Болгар дәүләтләре чорын акларга омтыла,үткән тарихкакүзәтү аша хәзерге җәмгыятькә бәя бирә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендәге яңарышның алшартлары нидән гыйбарәт?

2. Реалистик әсәрләрдә тәнкыйди катлам нинди функция башкара?

3. Бу юнәлештәге әсәрләргә нинди үзенчәлекләр һәм алымнар хас, нинди темаларга өстенлек бирелә һәм ни өчен?

**Лекция 2**

**Аннотация.** Лекциядә 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә мифологик образларның кулланылышы һәм функциясе тикшерелә, З.Мансуровның “Ике

егълау” һәм “Хозер Ильясны эзләү” поэмаларына анализлана, 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция кулланылышы өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** поэзия, интеллектуаль тенденциямифологик образ, мотив, функция.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Галиуллин Т. Шигърият офыклары / Т.Н.Галиуллин // Татар шигрияте: 1980-2000 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б.4-30.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. ХХгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: ХХ йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.428-435

4. Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.3: В конце века (1986-1990-е годы): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 160с.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.


**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Лекциянең планы**.

1. З.Мансуровның “Ике егълау” һәм “Хозер Ильясны эзләү” поэмаларына анализ.

2. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция.

З.Мансуровның тарихи темага язылган “Ике егълау” поэмасы да милли тема-проблеманы үзенчә бәяли һәм чишә. Милләт язмышы биредә Сөембикә фаҗигасен яктырту аша чагылдырыла. Сөембикә һәм Ярославнаның егълашулары, “диалогы” нигезендә композицион җәһәттән үзенчәлекле төзелгән поэма төгәл ике – вакыйгалар һәм хис катламына аерыла. Беренче – вакыйгалар катламы – Сөембикә һәм Ярославнаның егълашу сәбәпләрен ача. Бу диалог үзе үк символик яңгырашка ия, ул ике халыкның үзара эчке кичерешләрен уртаклашуын да гәүдәләндерә, ике арадагы фаҗигале каршылык кебек тә кабул ителә. Сәяси-дини әһелләр куерткан конфликтлы ситуация рус һәм татарларның холык-фигыльләрендә, эш-гамәлләрендә чагыла.

Татар шигъриятендә еш кулланылучы, билгеле алымнардан саналган төшләр, хәтта төсләр дә әсәр тукымасына табигый төстә шул максаттан чыгып кертелә. Гадәттә булачак вакыйгаларны, киләчәк фаҗигане искәртүче мәгънәсендә йөргән төш биредә, барыннан да бигрәк, ике арадагы каршылыкны ачып бирү вазифасын үзенә беркетә. Сөембикә төшендә энҗе-мәрҗәннәр белән саташса, Ярославнаның күргән төшләре кара төсләр белән бәйләнә: кара кошлар, җиргә кара яулыгын япкан әнкәсе. Каралык аларның үз кайгысын ачып

бирү белән бергә, татар дөньясына китергән хәсрәтен дә гәүдәләндерә. Сөембикә төшендәге энҗе-мәрҗәннәрнең дә үз мәгънәви чишелеше бар. Урта гасырларда ук киң әдәби әйләнешкә кергән энҗе символик образы күз яше мәгънәсендә йөри, аның семантикасы күз яшенең дә кыйммәтле хәзинә булуын белдерүгә юнәлтелә. Әнә шулай образның күпмәгънәлелеге поэмада ике катлам эчтәлек тудырырга - татар дәүләтенең данын, зурлыгын, бөеклеген һәм шуны югалту белән бәйле милләт фаҗигасен чагылдырырга ярдәм итә.

Әсәрнең үзәгендә торган милләт фаҗигасе бик күп күренеш, деталь, элементлар аша көчәйтелә: Идел-Йорттагы көз күренеше, җиңелү кайгысыннан хәтта ташларның, бичураларның елавы, шәмдәлләргә шомландыргыч яшьләрнең тамуы, сусыз дала кылганнарының болытларның яшен койган бөркеткә сәҗдә кылуы һ.б. Соңгысы метафора хезмәтен дә үти. Ә.Еникидәгечә кылганнар “җил кая иссә шул якка авышучылар”, ягъни үзмаксатсыз, битараф кешеләр булып төгәлләшә. Аның сусыз дала белән янәшәлеге мәгънәне яңа төсмерләр белән баета. Милли тарих, дәүләтсезлекне гәүдәләндерүче сусыз дала белән кылганнар дәүләтсез калган татар халкының кыйбласызга әйләнүен, яраклашуын аңлауга китерә һәм олы милли фаҗига буларак кабул ителә.

Бәгырьләрдәге Вакыт белән Хәтер бәрелеше, бердәмлеге, ягъни хронотоп әсәргә үз мәгънәсен алып керә, ул автор әйтергә теләгән фикер-идея белән кисешә. Хәтер – ул халык күргән-кичергәннәрнең күңелдәге чагылышы, вакыт агышына да карамый канында, бәгырендә саклана торганы. Көзгеле композиция ярдәмендә аның ахырда кабатлануы мәгънәне тагын да көчәйтә.

Каршылык шул рәвешле үстерелеп, шигъри тукымага Хәзрәти Мәрьямнең иңүе белән чишелә. Дини затның “күк дөньясыннан” җиргә төшерелүе нәфрәт белән тулы аң-акылны ачарга, җиңелүне “күк каргышы” төшү дип аңлатырга мөмкинлек бирә. Хәзрәти Мәрьямнең “Сезне гирьян иткән дошман явы – Аллаһ биргән сынау вәгъдәсе” сүзләре шуны раслау кебек яңгырый. Каргыш төшүнең башы һәр халыкның үз холык-фигыленә, Хакыйкатьтән, милли асылларыннан ераклашуга барып тоташа, ягъни халыкларның җиңелүенә, башка бер халыктан бигрәк, иң беренче чиратта ул

үзе гаепле дигән гыйбарә ассызыклана (*“Искәртмиме безнең өстебезгә ябырылып торган яу үзе? Үткапчыкта гына утырадыр дошманыңның үтә явызы.”*). Бу фикер  Мәрьям авызынан әйттерелеп, Сөембикә тарафыннан кабатлаттырыла. Сабырсызлык– *“Чыдамлыгын яшькә чылатмаган сабырларны сөя Аллабыз.”*, диннән, Аллаһтан ерагаю, имансызлык– *“Алыштырмый зекер әйләүләрне, гыйбадәтне андый аһ-ваһлар.”, “Үтәмисез фарыз кануннарны – унның берсен генә булса да.”*,  масаю – *“Ил-суларын җәннәт мисалында күреп масайганнар кем иде?”* (Хәзрәти Мәрьям) кебек ике халыкка да хас тискәре сыйфатлар саналса, Сөембикә монологы вакланышу– *“Вакланыша торды алыплары киртә булып калкыр тау саен”* , таркаулык **–** *“көчен туплый алмый төрки кавем зурдан купкан дошман каршында”*, кардәшлекне сакламау **–** *“Безнең халык бер көн тора алмас туганара ызгыш, дау юкта...”, “Карымталар кырды кардәшлекне, онытылды ыру вәгъдәсе”*, уй белән гамәлнең аерылуы, масаю – *“Күккә сыймас мәгърур бөркет җаны яши кебек... хәзер тавыкта”*, үчләшү – *“Безнекеләр һаман бугазлаша кечтек кенә иске бер үчтән”*, мордарлык – *“Мордарлыкка баткан мирзаларым, нәрсә җене сезгә кагылган? Аллаһыны сөю тәһарәте кылынмыйдыр алай кан белән”*, мескенлек – *“Гарьсезләрең дала горурлыгын сатты юк-бар бүләк хакына; мескенләнеп сорау мисалында Мәскәүләргә китте хат кына”* кебек тулаем тискәре сыйфатларның татар холыгын шәрехләвен ассызыклый, үз чиратында алар “Аллаһ каргышы” – җиңелүгә -  этәрүче көч дип алына. Шушы өлештә әсәр тукымасына автор фикере кушылып, аның үз халкын кисәтүе, җәрәхәте, әле дә булса дәвам иткән начар сыйфатлардан арынырга чакыруы булып яңгырый.

Милли дәүләтчелекне югалту вакыйгалары белән бәйле халык фаҗигасе хис катламының эчтәлеген билгели: лирик герой күңелендәге әрнү, сызлануга сәбәп төсен ала. Татарларның тискәре холкы тудырган борчылу белән алмашыну аша сызлану үзенең югары ноктасына күтәрелә, киләчәкнең билгесезлеге аны тагын да көчәйтә :

*Исәннәргә нинди аһлар ишетәсе,*

*Алгы көндә тагын ниләр күрәсе?!*

*Ике бикәч көн-төн егълый ике ярда,*

*Яраларга тамып тора күз яше...*

Бер төркем шигырьләрдә милли горурлык сыйфаты калку бирелә. Мондый шигырьләрдә Өмет, азатлык, тарих, белем, халык, милләт, бәйсезлек, киләчәк, ут, көрәш, фаҗига, батырлык кебек ачкыч сүзләр татарның бөеклеген, данын, горурлыгын ачуга юнәлтелә. Р.Харисның "Татарлар" (поэма-монолог), Л.Шагыйрьҗанның "Милли, милли миллионнар…", А.Хәлимнең "Без исән!" кебек шигырьләре шул хакта:

*Җәһәннәмнән кабат күтәрелеп,*

*Әйтү ләззәт икән:*

*Без исән!* – дип яза А.Хәлим "Без исән!"шигырендә.

Бу чор шигъриятенә хас сыйфатларның берсе буларак интеллектуаль тенденциянең, шартлы-метафорик юнәлешнең үсеш алуы билгеләнә. Бу җәһәттән лиро-эпик төр матур әсәр үрнәкләрен бирә, алар арасыннан Р.Харисның "Ант суы", З.Мансуровның "Хозер Ильясны эзләү" поэмаларына тукталыйк. Кыйсса, миф традицияләренә таянган, композицион яктан катлаулы һәм үзенчәлекле әсәрләрдән саналган "Хозер Илъясны эзләү" поэмасы берничә катламның әдәби кушылмасын тәшкил итә. Гомумән, соңгы елларда мәйданга чыккан татар поэмаларының бер хасияте булып төрле катламнарның синтезына омтылыш тора. Ул синтез еш кына дини-мифологик образлар, гыйбарә-әйтелмәләр аша уздырылган фәлсәфи уйланулар: кеше һәм гомер, яшәү һәм үлем, вакыт агышы, кеше гомеренең бәясе, яшәү мәгънәсе; сәяси-иҗтимагый фикерләр: идеология һәм милләт язмышы, система алып килгән фаҗига, милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгекебек мәсьәләрнең бер әсәр чикләрендә очрашуына бәйләнә. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша – интертекстуальлек ярдәмендә ирешелә. Әлеге сыйфат-хасиятләрне "Хозер Ильясны эзләү" поэмасы да чагылдыра.

Эпиклыктан бигрәк, лирик башлангычка өстенлек биргән әсәр милли, фәлсәфи катламнарның берлегеннән гыйбарәт. Поэмада милли-сәяси катлам

иҗтимагый халәткә бәя төсен ала. ГУЛАГ, төрмә-лагерьларның бар куәтенә эшләве, меңләгән шәхесләрнең җанын кыйган шәхес культы, инкыйлаб, сансыз сугышлар, җәмгыятьтә хөкем сөргән намус һәм намуссызлык (“намус җаннан кадерле”ләр белән намуссызлар көрәше), фәхишәлек (“каруланган “кызлар” карынынннан күпме җаннар китте гарешкә”), битарафлык (“борчылуны белмәс бәндәләрнең бәгырендә бүген каты боз”), яманлык кебек күренешләр аша көчләп урнаштырылган система, идеология кире кагыла, мәгънәсез сәясәт татар милләтенә төшкән фаҗига буларак бәяләнә һәм милләтнең хәтере югалу, колга әйләндерелүе (7 баб), битараф затларга әверелүе (11 бабатагы бишек җыры идеологиягә бәя кебек аңлашыла) белән исбатлана. Милләтнең таркалуының татар авыллары юкка чыгуы белән янәшәлеге фаҗиганең икенче ягын ачып бирә. “Вөҗданның вөҗүдтән аерылуы”, буыннар арасындагы бәйләнешләрнең йомшаруы, ата-угыл мөнәсәбәтләренең катлаулануы татар фаҗигасенең өченче кыйтгасы булып аңлашыла. Поэма тукымасына кертелгән карт белән киңәш сораучы турындагы хикәят тә шушы катламга карый һәм җәмгыятьтәге халәткә бәя булып яңгырый. Яшь буынның олы буын каршындагы җавапсызлыгы тискәре сыйфат буларак бәяләнеп кенә калмый, җәмгыятьнең бәхетсезлеге әнә шуңа тоташа  дигән фикерне дә ныгыта. Җәмгыятьтәге әхлакый, иҗтимагый-сәяси торыш, милләт фаҗигасе хиснең сәбәбенә әйләнеп, лирик герой тойгысы борчылу аша әрнү, сызлануга кадәр үстерелә.

Поэмадагы ике: милли-сәяси һәм фәлсәфи катламнарны тоташтыручы, чорларга бәя бирү өчен дә, фәлсәфәне, әхлакый яңгырашны тирәнәйтү өчен дә отышлы сайланган Хозер Ильяс образы Аклык, Сафлык, Мәрхәмәтлелек үрнәге, ягъни  архетип буларак кабул ителә. “Аллаһ бүләге” шигыренә исә ул тормыш авырлыкларыннан сыгылган лирик геройны юатучы, аңа яхшылык теләүче ярдәмче карт сыйфатында килеп керә.   Аның яшәешен бәян итүче Ак әби дә - шундый типларның берсе, корбанчылык, аклык, сафлыкны гәүдәләндергән Акъәбиләр архетибының дәвамы булып тора. Хозер Ильяс белән янәшә дүрт символик образ килә: гөл-чәчәк, камчы, сал һәм учак. Гөл-чәчәк –Хозер Ильясның дәвамы - аның күңел, яшәеш матурлыгы билгесе кебек

укыла. Икенчедән, аңа йөкләнгән тагын бер вазифа шагыйранә дөньяны шартлы икегә - Хозер Ильяслы үткәнгә һәм “имансыз, денсез” бүгенгегә бүлүдән гыйбарәт. Ак чәчәккә әверелүе Хозер Ильясның Җир-анадан аерылмаган зат, табигать баласы булуын да аңлата кебек. Табигать баласы булган бүгенгеләр исә - аңардан ераклашып, сукырларча табынучылар. Бу бәйләнеш аяусыз хәл-халәт табигый башлангычтан аерылу белән дә бәйле дигән фәлсәфәгә китерә. Сал – иминлек, муллык, рухи байлык билгесе, Хозер Ильяс кабызган учак, ут – иман ныклыгы, иман нуры, намус байлыгы, алай гына да түгел, кешелеккә рухи кыйбла, маяк символы да. Сугышлар, явызлык билгесе булып йөргән камчы образы да биредә башкачарак мәгънә төсмере белән баетыла: яхшылыкка башлангыч, фатиха кебек аңлашыла:

*Хозер Ильяс камчы селтәр иде дә,*

*Карлар-бозлар китә башлый Иделдә!..*

Хозер Ильяс яшәеше – яшәү үрнәге булып тора, ягъни автор чынбарлыкны әнә шулай үзгәртергә тели, аны үз хыялы, идеалы яктылыгында бәяләргә омтыла. Дини-мифологик образ белән бәйләнгән фәлсәфи катлам автор фикерен, идеясен үткәрә: кеше бу җиргә бары бер мәртәбә җибәрелә, ә ул тормыш исә иман, намус, вөҗдан берлеге белән бизәлергә, “Хозер Ильяс биеклегенә” омтылырга тиеш. Бу фәлсәфәне аңлауга поэмага эпиграф итеп китерелгән “Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам әйтте: бу тормыш – бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан” гыйбарәсе дә ачкыч булып тора.

Әсәр тукымасында Хозер Ильяс күзләргә сеңгән изгелек булып һәр кеше күңелендә дәвамын эзли, ягъни кешеләр күңелендәге иман, изгелек чаткыларының яктысы булып та тәгалләшә. Аның юкка чыгуы – аерым кешеләр җанындагы иман нурының югалуы, имансызлык, рухи салкынлыкның өскә чыгуы да ул. Әнә шулай Хозер Ильясның югалуы хиснең икенче сәбәбе булып тора. Иман һәм имансызлык, изгелек һәм явызлык каршылыгы аша Зиннур Мансуров җәмгыятьтә генә түгел, ә һәр кешедә барган күңел тартышын ачып бирүгә ирешә. Ялгыш юлдан киткән кешелекне иманга кайтару аша савыктырырга ниятли һәм фикерен Хозер Ильяс образы, аңа салынган мәгънә

аша җиткерә. Әсәр тукымасына шома кертеп урнаштырылгын салаватлар, аерым дини гыйбарәләр, хикәятләр дә шуңа хезмәт итә.

Р. Харисның интеллектуаль тенденция чагылышы ягыннан аерым игътибарга лаек "Ант суы" поэмасында сюжет сызыгы ике вакыт катламын берләштерә.

Интеллектуаль тенденция шагыйрьнең лирикасында да чагыла. Мондый әсәрләрдә аның аеруча бер үзенчәлеге - Вакыт образына таяну, аны төрле мәгънәви калыпларда "уйнату", фәлсәфи гомумиләштерүләр ясау сыйфаты алга чыга.

Вакыт образы аша яшәешкә (җиһан) һәм җир тормышына, кешегә бәя бирү омтылышы Сөләйман поэзиясендә көчле, ул еш кына кеше фәлсәфәсенә мөнәсәбәтле гәүдәләнә. Аның әсәрләренең бер өлеше кеше гомерендәге гомер баскычларын тергезә. "Көмеш ятьмәме ул..." шигырендә гомернең ахырына якынаю көз метафорик образы аша бирелә, ул лирик герой күңелендә сагыш хисен уятуга сәбәп төсен ала һәм "кереп барам көзгә" тезмәсенең кабатлануы аша тагын да көчәйтелә.Шагыйрьнең "...Болын – яшел..." шигырендә болын һәм чиллә образлары яшьлек чорын сурәтли, сагыш хисенә сәбәп булып өметләрнең акланмавы төгәлләшә. "...Җәй. Иң рәхәте..." шигырендә Сөләйман кеше гомерен җәй, көз, кыш, яз баскычларына бүлә. "...Вакыт – тырма..." шигырендә "вакыт- тырма, мин – ат" гыйбарәсе аша кеше һәм вакыт мөнәсәбәтләрентергезә. Тырма – үткән гомер, тырма тешләре кеше тормышындагы кыенлыклар һәм аның артыннан калган эзләр кебек мәгънәләрдә төгәлләшә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция чагылышын аңлатыгыз.
2. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясенә нинди стиль тенденцияләре хас?
3. Бу чор татар поэзиясендә мифологизм нинди алымнар, мотивлар һәм образлар аша чагылыш таба?

**Лекция 3**

**Аннотация.** Лекциядә 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә романтик юнәлешнең үсеш-үзгәреш тенденияләре билгеләнә, әлеге дәвер татар шигъриятендә иҗат мотивы анализлана, 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә стиль тенденцияләре, форма эзләнүләре ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:** поэзия, романтизм, мотив, символ, функция, стиль тенденциясе.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Галиуллин Т. Шигърият офыклары / Т.Н.Галиуллин // Татар шигрияте: 1980-2000 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б.4-30.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.428-435

4. Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.3: В конце века (1986-1990-е годы): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 160с.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.


**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Лекциянең планы**.

1. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә романтик юнәлешнең үсеш-үзгәреш тенденияләре.
2. Әлеге дәвер татар шигъриятендә иҗат мотивы.
3. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә стиль тенденцияләре, форма эзләнүләре.

Поэзиядә романтик юнәлеш кешелек, яшәеш кыйммәтләрен аңлауга, анализлауга йөз тота, фәлсәфи гомумиләштерүләрне үз итә, дини кануннардан читләшүнең мәгънәсез яшәешкә илтүе, яшәү мәгънәсен югалтуның ачылыгы, шуңа бәйле битарафлыкка, ваемсызлыкка чуму мотивлары урын ала,романтик образ-деталь, алымнарга таяна, аеруча йолдыз, кояш, ай, болыт образларының актив булуы күзгә ташлана. Йолдыз – язмыш, йолдыз – гомер агышы янәшәлеге белән Зәлфәтнең “Шулай икән...” фәлсәфи шигырендә очрашабыз. Әсәр тукымасында автор мәңгелек һәм фани дөнья каршылыгын тудыра, аның аша мәхәббәтнең узуы белән гомернең үтүе турындагы фәлсәфи уйланулар үткәрә:

*...Әллә ни булмас...*
*Китәрмен*
*Галәмгә ялгыз гына,*
*Суыныр, сүнер, югалыр*

*Ялгыз бер йолдыз гына...*

Зөлфәт кеше гомеренең чиклелеге, үлемнең аеруы, югалырга мәҗбүр итүе өчен сызлана, бу фикерләр шигырьгә экзистенциаль мотивларны алып керә. Сызлану фәлсәфәсе шагыйрьнең “Язмыш” шигырендә дә урын ала. Традицион кулланылышта йолдыз – моңлы тавышлы бер кош та, бәхет, мәхәббәт, сафлык, сөйгән яр символы да. Ә Зөлфәт аны еш кына мәхәббәт, сагыну, мәңгелек, язмыш, соңгы чорда язылган шигырьләрендә ялгызлык, гомер агышы кебек мәгънә төсмерләре белән баета. Күпчелек әсәрләрдә йолдыз – мәхәббәт янәшәлеге тудырыла. Мәсәлән, “Күк тирәге йолдызланган чак...” шигырендә йолдыз символы мәхәббәтнең матурлыгын да, яктылыгын да, бөеклеген дә искәртә. Мәхәббәт кебек изге һәм мәңгелек хисне илаһи Күктәге йолдыз белән чагыштыру, гомумиләштерү аша шагыйрь мәхәббәт фәлсәфәсен үткәрә һәм Мәхәббәтне Җирне генә түгел, Галәмне гармониядә тотучы көч югарылыгына күтәрә. Сөю, сөйгән ярны сагыну мотивлары үзәккә алынган “Бар килеш...”, мәхәббәтнең көчен йолдыз нурының яктысы аша чагылдырган “Бул гына!” шигырьләрендә дә йолдыз – мәхәббәт янәшәлеге күзәтелә.

Р.Харисның “Өченче дөнья” шигырендә дә Мәхәббәт фәлсәфи югарылыкта бәяләнә. Теге дөнья / бу дөнья каршылыгына нигезләнгән шигырьдә мәхәббәт яшәү мәгънәсе югарылыгына күтәрелә:

*Теге дөнья...*

*Һәм бу дөнья...*

*Ә син - өченче дөньям...*

*Ике дөнья хасиятен мин синең белән тоям.*

*Иң хыялый төшемнән дә*

*Ниндидер көч өн ясый...*

*Җирдәге иң зур могҗиза –*

*Син, мәхәббәт дөньясы!*

М.Вәлиевның “Болын” шигырендә хис-кичерешләр үткәннәрнең якты хатирәсе буларак саклanучы болын образы аша җиткерелә, аңнардан ераклык,

кире кайта алмау, сагыну, чарасызлык барысы бергә кушылып, сагыш хисен тудыра; болын образы психологик эчтәлектә бирелә:

*Без яшьлектә бер җыр язган идек,*

*Көе калды сибелеп болынга;*

*Чишмә булып, күңелем болынында*

*Агыла шул кй, агыла тын гына.*

Р.Харисның “Син миңа үпкәләп калма...”, “Зәңгәр моң”, Р.Фәйзуллинның “Борчылма!”, Ф.Тарханованың “Йолдзы булдың гомер күгемдә”, Сөләйманның “Үкенмәм”, Г.Рәхимнең “Давылга әверелгән җил”, Р.Рахманның “Безнең бәхет”, Г.Моратның “Сагышлы йолдызлар”, Р.Гаташның “Газәл-тәрҗемә” һ.б. шигырьләрдә дә мәхәббәткә бәйле хис-тойгылар урын ала.

Романтик юнәлештәге шигырьләрдә суфичыл символик образ-сурәтләр, мотивлар, әдәби структуралар да чагылыш таба, ләкин алар укучыга, нигездә, дөньяви эчтәлеккә төреп тәкъдим ителә, мәсәлән, Зөлфәт, Р.Гаташ, З.Мансуров, Л.Шагыйрьҗан, Х.Әюпов кебек шагыйрьләр тарафыннан яшәешне дөньяви танып-белү барышында отышлы файдаланыла. Габделнур Сәлим поэзиясе исә тулысынча диярлек ике төрле укылышка урын калдырган мистик образ-символларга, мотивларга корылуы белән үзенчәлекле, суфичылык әдәбиятындагы кебек үк, аның әсәрләрендә символларның суфи юлындагы лирик герой халәтен, аның иң нечкә, яшерен кичерешләрен җиткерүе күзгә ташлана. Суфичыл әсәрләр структурасын, аларга хас мотив, символларны, төсләр символикасын яңартуы ягыннан шагыйрь бүгенге поэзиядә үз стилен булдыра, шигърияткә үзгәлек бирә, аны сурәт, мотив һәм фәлсәфә-фикер ягыннан баета-төрләндерә, традицияләрнең яшәүчәнлеген тәэмин итә.

Шагыйрьнең “Ике ук атымы”, “”Дәрвиш коңгыз”, “Мөҗәһид”, “Җан”, “Җан сурәте”, “Заһид”, “Олы юл” кебек кечкенә һәм зур күләмле поэтик әсәрләренең үзәгендә илаһи мәхәббәт (Аллага мәхәббәт), яшәү һәм үлем темалары тора, суфичылык поэзиясенә хас төстә, фикер һәм фәлсәфәгә зур урын бирелә, шуларга мөнәсәбәтле гуманистик мотивлар үткәрелә. Суфи авторлар традицияләрен яңартып, шагыйрь эзләнүләрендә “гүзәллек,

матурлык” категориясеннән бигрәк, “дөреслек һәм хакыйкать” төшенчәсе әһәмиятле санала. Әсәрләр тәкъдиргә буйсынырга, әхлакны төзәтергә чакыру, җанның Алла белән кушылырга омтылуы, бу җирнең әхлакый коллык, ялган булуын раслау идеясе белән баетыла; өлешчә иҗтимагый тәртипләргә, динсезлеккә, ширеккә мөнәсәбәт җиткерелә, рух, җан бөтенлеге, дөньяның фанилыгы, кешенең тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе кебек мәсьәләләр үзәккә куела.

Романтик әсәрләрдә фәлсәфилекнең көчәюе күзәтелә. Бу сыйфат Р.Фәйзуллинның “Тау һәм үзән”, “Метаморфозалардан”, Сөләйманның “Ә һәлакәт якыная минут саен”, “Ә тормыш – көтүче курае”, “Төнге күккә карап уйлану”, К.Сибгатуллинның “Бүген төнлә”, Ә.Баянның “Җил сурәте”, “Их, син, дөнья”, Н.Гамбәрнең “Тормыш гөлләре”, Р.Аймәтнең “Мин әле тумаган”, “Автопортрет” һ.б. шигырьләрдә күзәтелә. Мәсәлән, Р.Фәйзуллинның “Тау һәм үзән” шигырендә ике чик – тау һәм үзән образлары, кешенең үз-үзен танып-белергә, бәяләргә омтылуы аша Яшәеш фәлсәфәсе уздырыла:

*Без – Үзән.*

*Көйсезләнеп (яки үч алып) Тәңре-Җир бер ут төчкерсә,*

*Үзәннәрнең*

*Тау булуы, ә Тауларның убылуы бар.*

Бу сурәтләр укучыны бер фикергә алып килә: дөньяда абсолют төшенчәләр юк, барысы да вакытлы һәм үзгәрүчән. Шуңа мөнәсәбәттә әсәргә тормыш-яшәешнең үзгәрүчәнлеге турындагы уйланулар килеп керә, автор шуларны Хакыйкать кебек кабул итә. Мондый фикерләр Н.Гамбәрнең “Тормыш гөлләре” шигырендә дә күзәтелә:

*Яшәү – үлем аша; гөлдән тамган*

*Бу орлыклар язын гөл булыр;*

*(...Җаным сездә кала,*

*Тән үлгән көн*

*Яңа тормыш туган көн булыр.)*

Автор яшәүнең үлем аша башка баскычка күтәрелүен сурәтләп, нәтиҗә ясый: яшәү мәңгелек, үлем – бер баскычтан икенче баскычка күчү ноктасы.

*Бу дөнья – гарасат мәйданы.*

*Әллә соң яшәү дә – бер җәза?!*

*... Мин әле тумаган, ә инде*

*Күкләрдә укыйлар җеназа,* - *дип яза Р.Аймәт* “Мин әле тумаган” шигырендә һәм экзистенциаль мотивларга урын бирә. М.Галиевның “Өч мизгел” шигыре яшәешнең өч баскычын – яшьлек, гомер уртасы, картлык кебек этапларын сурәтли, шуларга бәйләп яшәеш хакында фикерләрен уздары.

К.Сибгатуллинның “Бүген төнлә” шигыренә мөрәҗәгать итик:

*Бүген төнлә минем җирем үлде,*

*Бик авырып үлде ьир шары...*

*Мин үзем дә калдым бугай шунда,*

*Томаннаргы кереп,*

*Каберсез.*

*Мин соң нәрсә!*

*Чиксез галәмендә*

*Җир булып җир хәтта кадерсез!*

*Бүген төнлә минем җирем үлде.*

*Сез кешеләр, кайда идегез?*

*Җирләмичә мәет калдырмыйлар,*

*Күмелмичә калды җиребез.*

Җир образының символик югарылыкка күтәрелеп, берничә мәгънә калыбында сурәтләнүе күренә. Бердән, ул сызлануны җиткерү өчен ярдәм итсә, икенчедән, авторның күңеле кебек шәрехләнә, өченчедән, җир кешеләренә мөнәсәбәт белдерүгә юнәлтелә, кешелекнең рухи яктан бушап калуы булып укыла. Әнә шулай төрле мәгънәви яссылыкларда автор берничә - җәмгыять торышына кагылышлы иҗтимагый, кешелеккә мөнәсәбәтле үз-үзеңне, яшәешне танып-белү һәм сызлану фәлсәфәләрен бер үремтәгә бәйләп куя.

Поэзиядә тарихи шәхесләргә багышлап әсәрләр язу үзе бер юнәлешне тәшкил итә. Сөембикә, Колшәриф, Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Тукай образларын үзәккә алган әсәрләр күпләп языла, аеруча Тукай образының сурәтләнеше катлаулы һәм катнаш төс ала.Бер әсәр цикләрендә реалистик,романтик,мифологик,модерн традицияләре берләшеп, шагыйрьгә төрле яссылыкларда бирелгән бәяне done бербөтенгә әйләндерү омтылышы ясала. Моңа интертекстуальлек, паратекстуальлек, шартлы уен кебек алымнар, дини-мифологик, символик образларга мөрәҗәгать итү, романтик пафосны реалистик детальләр белән баету аша ирешелә.

З.Мансуров,Р.Гаташ, Х.Әюпов, Х.Туфан әсәрләрендә милләтнең Тукайга мөнәсәбәте, шуның аша татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйлану, кайбер әсәрләрдә җәмгыять хәле белән бәйле сәяси тәнкыйть урын ала.Зөлфәт, Р.Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов шигъриятендә исә, гомумән, милләт язмышы, актуаль мәсьәлә кебек куелып, Тукай шәхесе, аңа мөнәсәбәт аркылы системаны, идеологияне тәнкыйтьләү, милли бәйсезлеккә чакыру мотивлары белән байый.

Тагын бер тенденция төсендә бүгенге шигърияттә стильләр төрлелеге күзгә ташлана (Ш.Анак, Р.Аймәт, Р.Зәйдулла, Сөләйман һ.б.). Мәсәлән, Р.Аймәтнең лирик әсәрләрендә импрессионистик алымнар яратып кулланыла. Шагыйрь табигать образларына еш мөрәҗәгать итә, аларны лирик герой кичерешен җиткерүгә буйсындыра (*Ялгыз айның салкын нурын кочып, Телгәләнер җаның парә – парә*, “Китү”; *Тышта яңгыр... Гонаһларны кыеп, Коя гына яңгыр шыбыр – шыбыр.Тышта яңгыр. Кагылып үтсә яшен, Ишелер күк өскә гарешкәйләр. Күк капусын ачып, миңа табаТөркем – төркем оча фәрештәләр...*), аны бер мизгелдә туган тойгы аша сурәтләргә омтыла:

*Араларда кояш бата мәллә? –*

*Сузылып ята соңгы күләгәләр...*

*Миннән алып сиңа хәтле ара –*

*Мәхәббәттән хыянәткә кадәр..,* - дип яза “Эллегия” шигырендә.Шагыйрьнең идеалы - кешеләр арасында мәхәббәткә,

миһербанлыкка корылган мөнәсәбәтләргә корылган яшәеш. Яшәеш серләрен нечкәләп аңларга-төшенергә омтылган шагыйрь айлы, йолдызлы, куе болытлы Төн образына мөрәҗәгать итеп, аны лирик герой кичерешләрен ачуга буйсындыра:

*Таңга чаклы сине төн әрләсен...*

(“Китү”)

*Төн куенына качып, шыбыр – шыбыр,*

*Йөрәгемә кемдер алма коя.*

(“Төш”)

Экспрессионистик алымнарга таяну бүгенге поэзиядә тагын бер стильне хасил итә. Мәсәлән, Р.Зәйдулла поэзиясендә экспрессионистик алымнардан лирик герой тышкы тирәлек белән каршылыкка керүе, тормышны караңгы буяуларда сурәтләү, тормышка аңлаешсыз, дошмани бәя бирү,хисләр киеренкелеге, лирик геройның күнегелгән тәртипләргә,сәясәткә, “үле” мәдәни хәл-халәткә, идеологиягә каршы чыгу сыйфатлары күзәтелә. Аның лирик героена усаллык та, барлык тәртипләрне җимерергә омтылу да хас. Мәсәлән, “Яна йөрәк, шаша җаным...” шигыренә күз салыйк. Лирик герой борчыла, ярсый, үз-үзе белән каршылыкта яши. Лирик герой җанының бикләнгән булуы, каршылыгы мәхәббәтнең юклыгына тоташа. Хисләр ташкыны уянуга төп сәбәп булып мәхәббәт яралары күтәрелә:

*Җаным бикле килеш кала,*

*Эчтән ярсыйм,*

*Эчтән янам.*

*...Тынгы бирми миңа һаман*

*Элеккедән калган ярам*.

“Битлек” шигырендә исә җәмгыятькә каршы нәфрәтләнүче, тәртипләргә каршы чыгучы лирик герой белән очрашабыз. Кешеләрнең битлеккә төренеп яшәргә мәҗбүр булуы хиснең сәбәбенә әверелә:

*Бармак төтреп көлдек без аңардан,*

*Сиздермәде, шундый горур иде.*

*...Тик бер көнне – Яңа елда бугай,*

*Ул түзмәде – битлек алып киде.*

*Һәм ул көлде мыскыл белән бездән,*

*Һәм битлеген*

*Салмады беркайчан да.*

“Литва” шигырендә “*Еллар таккан ямьсез йолаларны, Йолкып ат та юлда ела-ела!”,* - дип ачынган Зәйдулла “Хәсрәт” шигырендә бөтен дөньяны сүгә, каргый:

*Бу нинди дөнья булды соң?*

*Бу нинди...нинди...нинди...*

*Аның белән тураям дип,*

*Мин авыш булам инде.*

Жанрлар үзенчәлеге ягыннан караганда 1990 нчы елларда күңел лирикасы, гражданлык, сәяси лириканың активлыгы күзәтелсә, соңгы елларда күңел лирикасы, фәлсәфи лирикага өстенлек бирелә. Лиро-эпик төрдә поэма жанры өстенлек алса да, соңгы елларда Р.Харис шигъри роман жанрын (“Исемсезләр”) яңартып, укучыларын шатландырды. Жанрлар өлкәсендәге эзләнүләр виртуаль поэзия һәм акрошигырь жанр формаларына мөрәҗәгать итүдә дә күренә. Акрошигырь – һәр шигырь юлының беренче хәрефләре өстән аска укылганда нинди дә булса сүз, еш кына кеше исеме, яки фамилиясе аталырлык итеп язылган шигырь. Хәзерге милли поэзиядә акрошигырьгә мөрәҗәгать итү Җ.Сөләйман, Р.Аймәт һ.б. иҗатында күзәтелә. Мәсәлән, “Ал кулыңа моңлы тальян гармун...” шигырендә тезмәләрнең баш хәрефләрен бергә кушканда аның “Абзалов Ринат абый Абзал улына” багышлануы ачыклана, ә “Әбиләр чуагы бер килер таҗ булып...” шигырен шул рәвешле “чишкәндә” “Әни”гә атап язылуы аңлашыла.

Виртуаль поэзия шигырьне тышкы формасы ягыннан нинди дә булса предметка охшатып язуга нигезләнә. Мондый шигырь үрнәкләре Р.Фәйзуллин, Л.Зәлкәрнәй, Г.Сәлим һ.б. иҗатларында очрый. Мәсәлән, Г.Сәлимнең “Бәхиллек” шигыре очар кошны хәтерләтә. Аның аша шагыйрь Аллаһка

омтылучы лирик герой халәтен көчәйтүгә ирешә. Шул рәвешле, татар поэзиясе ХХ-ХХ1 гасыр чикләрендә эчтәлек һәм форма, фәлсәфи яктан тирәнәя, төрләләнә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә романтизм иҗат юнәлешенең үсеше, аның алшартлары нидән гыйбарәт?

2. Романтик әсәрләрдә нинди мотивлар урын ала, алар нинди функция башкара?

3. Бу юнәлештәге әсәрләргә нинди үзенчәлекләр һәм алымнар хас?

4. Суфичылык мотивларының һәм образларының яңарышын аңлатыгыз.

## Тема 27. Р.Харис иҗаты (1941).

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә Р.Харис иҗатына хас төп үзенчәлекләр билгеләнә, “Ат иярләү” һәм “Рәссам” поэмаларында интеллектуаль тенденция, алымнары анализлана.

**Ачкыч сүзләр:** поэзия, интеллектуаль тенденция, мотив һәм образ-деталь.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т. Замана һәм шагыйрь / Т.Галиуллин // Шәхесне гасырлар тудыра. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – Б.109-116.

2. Галиуллин Т. Фикер һәм хис бердәмлеге / Т.Галиуллин // Шигърият баскычлары. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.215-225.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Хәсәнова Ф.Ф. Ренат Харис шигърияте: Шагыйрьнең иҗат биографиясеннән / Ф.Ф. Хәсәнова // Казан утлары. – 2000. - № 5. – Б. 155-170.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ "Си-пресс", 2012. – С.118-123.

**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Лекциянең планы**.

1. Р.Харис иҗатының үсеш-үзгәреш тенденцияләре.
2. "Ат иярләү" поэмасына анализ.
3. "Рәссам" поэмасында интеллектуаль тенденция, алымнары.

Соңгы елларда әдәбиятның яңачалыкка иң сизгер катламы – шигърият тә үзгәрешләрдән читтә калмый: кыю һәм актуаль фәлсәфи фикерне киная аша

укучыга җиткерүдә алга китә, форма өлкәсендә эзләнүләр алып бара. Замана җилләре прозадагы кебек үк шигърияттә дә интеллектуаль башлангычны көчәйтә, авторның фикер калыпларын алгы планга чыгара. Татар поэзиясенең үзенчәлекле шагыйрьләренең берсе – Р. Харис та бу үзгәрешләрдән читтә калмый, яңа дәвергә кыю аяк атлый.

“Ат иярләү”поэмасы интеллектуаль әдәбият таләп иткәнчә, фикер агышына нигезләнә. Поэма структурасында ике катлам берләшә. Беренчесе реаль сугыш чорын күз алдына китерсә, икенчесе Кәрамның уй-фикер агышын сурәтли һәм беренчесенең метафорасына әверелә. Кәрамның аты белән сөйләшүе асылда үз күңеленең иң тирән төпкелләренә төшүе, үз күңелен битәрләве буларак аңлашыла. Метафорик, ирреаль катлам поэманың башыннан ахырына кадәр реаль сюжет сызыгы белән үрелеп бара һәм кешенең үз-үзенең асылына кайту процессына нигезләнә. Автор тарафыннан табышмак буларак тәкъдим ителгән сюжет бары тик барлык семантик элементларны барлаганнан соң гына чишелә ала һәм укучыдан әзерлек таләп итә.

“Рәссам” поэмасында Р. Харис чынбарлыкны икеләтә торган “проекция” алымын куллана. Реаль һәм ассоциатив күренешләрнең синтезы шагыйрьнең фикер үзгәрешенә, дөньяны күзаллавына нигезләнгән ассоциатив рәтләр барлыкка китерә. Поэмада ике ассоциатив рәт – дөньяви күренешләр һәм киндердәге сурәтләр - барлыкка килә. Беренчесен билгеләүче реаль сурәтләр сюжет сызыгын барлыкка китерми, ә бәлки икенче ассоциатив рәткә күчеш ясый. Күчеш “рәссам күңеле” аша башкарыла һәм киндергә төшерелгән сурәт рәвешендә чагылыш таба. Аның күңеле җир халәтен билгеләүче камертон ролен башкара һәм аасоциатив дөнья тудыра. Реаль дөнья күренешләрен хәтерләткән хыялый сурәтләр мәңгелек мәсьәләләрне бер чор рамкаларыннан чыгарып, тарихи дәвамчыллыкта күзәтергә ярдәм итә. “Бүре күзе” поэмасында да, интеллектуаль әдәбиятка хас булганча, вакыт рәтләренең (авторның балачагы, бүгенге көн вакыйгалары, Бөек ватан сугышы чоры, мифологик катлам) синтезы күзгә ташлана: тарихи-легендар сюжет бирелеше аркылы бүгенге көн проблемалары калкытып куела. Поэманың буеннан буена һәр вакыт

катламында күренеп килгән бүре образы  авторның нәтиҗәсен, фикер сөземтәсен ачыкларга ярдәм итә, бабаларыбыз – төркиләр заманына алып кайта һәм ассоциацияләр аша татар халкының бүгенгесен тарих белән тоташтыра. “Һарут белән Марут” поэмасы мифологик һәм реаль катламнарны берләштергән әсәр буларак характерлана. Әлеге поэманың сюжеты мифологик ышануларга барып тоташа, әмма тоташ хыялый сурәткә корылуга да карамастан, ул бүгенге тормышның реалистик күренешләренә нигезләнә. Поэмада бүгенге көн кадагына куелган актуаль мәсьәләләргә игътибар ителә, тормышка ироник күзлектән бәя бирелә, яшәешнең чын тормышчан моделе барлыкка китерелә һәм кеше бу модельне коручы төп көч итеп сурәтләнә.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. Р.Харис татар поэзиясенә нинди яңалыклар алып килә?
2. “Ат иярләү” поэмасында метафора нинди вазифа башкара?
3. “Рәссам” поэмасында шартлылык нинди функция башкара?

**Лекция 2**

**Аннотация.** Лекциядә Р.Харисның “Ант суы” поэмасына анализ ясала, шагыйрьнең лирикасында интеллектуаль тенденция алымнары, Вакыт образының мәгънәви бөтенлеге өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** поэзия, тематика, интеллектуаль тенденция, шартлылык, мифологик мотив һәм образ-деталь.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т. Замана һәм шагыйрь / Т.Галиуллин // Шәхесне гасырлар тудыра. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – Б.109-116.

2. Галиуллин Т. Фикер һәм хис бердәмлеге / Т.Галиуллин // Шигърият баскычлары. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.215-225.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Хәсәнова Ф.Ф. Ренат Харис шигърияте: Шагыйрьнең иҗат биографиясеннән / Ф.Ф. Хәсәнова // Казан утлары. – 2000. - № 5. – Б. 155-170.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Лекциянең планы**.

1. Р.Харисның “Ант суы” поэмасында вакыт рәтләре.

3. Шагыйрьнең лирикасында Вакыт образының мәгънәви бөтенлеге.

Р. Харисның интеллектуаль тенденция чагылышы ягыннан үзенчәлекле “Ант суы” поэмасында сюжет сызыгы ике вакыт катламын берләштерә. Тарихи вакыт 985 елгы Русь һәм Болгар килешүен яктырта, Сувар патшасының хыянәте, Владимирның Болгарга яу белән чыгуын, Мөхәммәт патшаның таш белән атарга теләгән кешегә аш белән җавап бирү кирәклеген истә тотып килешү төзүелүен сурәтли. Поэмада шартлы алымнардан вакытлар кушылуы күзәтелә. Поэма тарихи сюжетка нигезләнсә дә, төп фикер интеллектуаль сюжет чылбырында җиткерелә, биредә автор-хикәяләүче образы беренче планга чыга. Төп фикер “Татар башын татар ашар” дигән халык мәкале аша ачыклана. Татар халкы үз тарихына үзе аяк чала: бер яктан халыкның үз уллары аңа хыянәт итсә, икенче яктан – халык бу мәкерне сизми кала, “Болгар патшасы йоклый. Йоклый берничә халыкның язмышына бәйле тарих”, ягъни төп фикер сюжет үстерелеше ярдәмендә түгел, ә бәлки, интеллектуаль әдәбиятка хас булганча, фикер сөземтәләре ярдәмендә ачыклана. Бу авторның матур табышы булып тора. Әлеге сыйфатлар шагыйрьнең “Һарут белән Марут”, “Бүре күзе”, “Тукайның мәхәббәт төшләре” кебек поэмаларында да дәвам итә, үстерелә.

Интеллектуаль тенденция шагыйрьнең лирикасында да чагыла. Мондый әсәрләрдә аның аеруча бер үзенчәлеге - Вакыт образына таяну, аны төрле мәгънәви калыпларда “уйнату”, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясау сыйфаты алга чыга. Шагыйрь әзерлекле укучыга юнәлтеп, Вакыт образы аша фәлсәфи эчтәлекне тирәнәйтүгә ирешә. Вакыт, фәлсәфи категория буларак, бер символик мәгънәгә ия, дип саналса да, һәр шагыйрь иҗатында аның үз кырлары, мәгънә төсмерләре бар.

“Алтын төрән” шигыренә мөрәҗәгать итик.

*Җир сөрәм…*
*Гасырлар катламнарына үтеп керәм…*
*Туфракта Киек Каз Юлының тузанын күрәм…*
*Җирнең бәгърен кояш нуры белән кавыштырам,*
*Ерак тарих серен бүгенгегә таба авыштырам,*
*Ашлык тамырын космик токым белән таныштырам.*

Лирик геройның гасырлар катламнарына үтеп керүе, тарих серләренә төшенү мөмкинлеге гади Кешене Вакыт эчендә, аның агымында хәрәкәт итүче бер үзәк итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Р. Харис аның Вакыт пространствосын үзенә буйсындырырга сәләтле булуына басым ясый.

“Яшь Вакыт” шигыре аеруча үзенчәлекле. Әлеге шигырьдә Вакыт – Кеше мөнәсәбәтләренең яңа төре ачыла:

*Һәм сизәм, сыкрап сизәм —*

*Ерагая бит ара.*

*Араны яра итеп,*

*Яшь Вакыт үтеп бара!*

Биредә циклик Вакыт чагылыш таба һәм ул кеше гомерен этапларга бүләргә ярдәм итә. Инде олы яшькә җиткәч, зирәк лирик герой үзенең гомере узып баруын һәм картайганын аңлый. Ул кешенең мөмкинлекләре Вакыт белән чагыштырганда гаять чикле икәнлеге турындагы хакыйкатькә ирешә. Һәм әлеге хакыйкать лирик геройда сызлану хисен уята. Экзистенциализм фәлсәфәсенең мотивлары Р. Харис иҗатында Вакыт образы белән бәйләнештә ачыла.

Иҗатының алдагы чорында Ренат Харис дөньяны фәлсәфи тануның тагын да югарырак баскычына менә. Хакыйкатьне аңлау лирик геройдагы сызлану хисен тагын да арттыра:

*:Эзләр кала…*

*Эзләр сеңә…*

*Тик Вакыт кына өстә…* (“Истә”).

“Чиксез кодрәт” әсәрендә Вакыт чагыштырулар аша бирелә. Чагыштыру объектлары итеп шырпы (*Караңгыдан котылып була*), кояш (*Төнгә каршы котылып* була) һәм учак (*…ягып котылып була суыктан*); дару (*дару белән чигереп була үлемне…*)алына. Болар янәшәсендә Вакыт — мәңге җиңелмәслек, мәңге югалмаслык Куәт, чөнки Вакыт барлык элементларның функциясен үти ала: кояш яктылыгын, җан җылысын бирә ала һәм иң мөһиме – Вакыт дәвалый.

*Чиксез кодрәткә ия тик*

*Бер Куәт —*

*Вакыт! Бары тик Вакыт!*

Биредә дини фәлсәфә шигырьдә Вакыт – Алла янәшәлеге тудырылып, Вакытның көче яңа баскычка күтәрелә. Вакыт образының яңа сыйфаты ачып ачыла:аның өлештән бөтенгә һәм бөтеннән өлешкә күчә алу мөмкинлеге.

Шулай итеп, Р. Харис поэмаларында интеллектуаль тенденция ачык билгеләнә һәм әсәрләрдә үзенчәлекле чагылыш таба. Биредә реаль һәм ирреаль катламнарның синтезы, ассоциатив рәтләр барлыкка китерү, вакыт таләпләреннән читкә тайпылу, фольклор элементларына мөрәҗәгать итү һәм автор-хикәяләүче образын беренче планга чыгарып универсаль кануннарны эзләү омтылышы чагылыш таба.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. “Ант суы” поэмасында интеллектуаль тенденция алымнарын билгеләгез.

2. Р.Харисның лирик әсәрләренә нинди үзенчәлекләр һәм алымнар хас?

## Тема 28: 1985-2000 нче елларда татар драматургиясе

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә 1980-2000 нче еллар татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре, 1990 нчы елларда сәхнә әдәбиятында борылыш, аның алшартлары билгеләнә, әлеге дәвер татар драматургиясендә модерн алымнар ачыклана, реализм иҗат юнәлешенең чор драматургиясе кысаларында үсеш-үзгәреше анализлана.

**Ачкыч сүзләр:** драматургия, модерн алымнар, тенденция.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.95-217.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. ХХгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: ХХ йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар драматургиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.436-443.

4. Саттарова А. Яңадулкында / А.Саттарова // Татар драматургиясе: 1960-80 нчееллар. – Казан: ТаРИХ, 2003. – Б.5-16.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская драматургия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.124-133.

**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли таныпбелү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лекциянең планы**.

1. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендә төп үсеш-үзгәреш тенденцияләре.

2. Сәхнә әдәбиятында 1990 нчы еллардагы борылыш, аның алшартлары.

3. Әлеге дәвер татар драматургиясендә модерн алымнар.

4. Реализм иҗат юнәлешенең чор драматургиясе кысаларында үсеш-үзгәреше.

Сиксәненче елларның икенче яртысы-туксанынчы еллар чигендә драматургия яңа үсеш сукмакларын барлый башлый: Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, Зөлфәт Хәким, Ф.Бәйрәмова, М.Гыйләҗев һ.б. сюжет-композиция бирелеше, образлар төрлелеге, сәнгати алымнар җәһәтеннән яңа эзләнүләр, тәҗрибәләр юлына керә. Шулар аша ачылган субъектив катлам җәмгыятькә хас сыйфат-билгеләрне, система, тоталитар режим, аның шәхескә йогынтысын гына түгел, кешелекнең үзен, яшәеш кануннарын бәяли башлый, тәнкыйди бәя фәлсәфи фикер-карашлар белән кушыла яки фәлсәфә үзе бер катлам-башлангыч төсендә алга чыга. Драма төре тематик яктан байый-төрлеләнә,психологизм көчәя, проблематик яссылыкта әхлакый мәсьәләләрдән гомумкешелек кыйммәтләрен яктыртуга таба хәрәкәт итә. Өченчедән, драматургиядәге сыйфат үзгәрешләре иҗат юнәлеше, агымнарының, иҗади тенденцияләрнең төрлелегенә тоташа: сүз сәнгатенең бу төрендә романтизм, реализм юнәлешләре, агымнары белән янәшәдә модернистик, постмодернистик алымнар бергә берегеп үсә-үзгәрә, интеллектуаль тенденциянең көчәюе күзгә ташлана, дөнья әдәбиятлары үрнәгендә яңа әдәби юнәлешләр урын ала. Бу үсеш-үзгәреш, бердән, сүз сәнгатенең үз эчке закончалыклары белән бәйләнсә, икенче яктан, үзгәртеп кору сәясәтенә мөнәсәбәтле 1980-90 нчы еллар чигендә башланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни фикердәге яңарыш, милли үзаң үсеше йогынтысында формалаша.

Шушы еллар аралыгында модернистик әсәрләр, яңа, үзгә алымнарга, форма һәм элементларга таянып язылганпьесалар бер юнәлешне тәшкил итә. Д.Салиховның “Алла каргаган йорт”, Ф.Бәйрәмованың “Вакыйга җүләрләр йортында бара” кебек драмалары Аурупа һәм рус әдәбиятында үрнәгендә “явызлык театры”, Аманулланың “Әлепле артистлары”, “Кылый Кирам балдагы”, Д.Салиховның “Пуля” әсәрләре “көлке театры”, М.Гыйләҗевның “Баскетболист” комедиясе “абсурд театры” кебек әдәби юнәлешләрнең татар драматургиясенә дә үтеп керүен дәлилли.

Модернистик сәхнә әдәбиятында фәлсәфи башлангычның үзәккә алынуы, шартлылыкның, интеллектуаль тенденциянең көчәюе күзгә ташлана, мондый әсәрләр тормыш-яшәешкә бәя бирергә, актуаль проблемаларны, яшәү

кануннарының, тәртипләрнең кешегә тәэсирен гәүдәләндерергә омтыла. Үзәккә хакыйкатьне тапкан геройны күтәреп, аның аша ялгызлык фәлсәфәсен үткәрә һәм җәмгыять кешене ялгызлыкка китерә, хәтта шәхес буларакюкка чыгара дигән фикерне ассызыклап бара. Шуның ярдәмендә билгеле бер канун-кагыйдәләрне аерып чыгара, мифологик мәгълүматлар, шартлы-мифологик, символик образлар, метафора, әкияти алымнар ярдәмендә идеаль тормыш моделен төзеп, укучыга тәкъдим итә. Мондый әсәрләр чорның рәхимсезлеген, аның кеше тормышына йогынтысын ассызыклап бара, яшәеш кенә түгел, сәяси кыйммәтләрне дә кире кага. Бу үзенчәлекләр хакында М.Гыйләҗевның "Бичура", "Баскетболист", З.Хәкимнең "Җүләрләр йорты", "Кишер басуы", Д.Салиховның "Алла каргаган йорт" кебек әсәрләре хәбәр итә. Бу юнәлештәге әсәрләрнең бер өлеше милләт язмышы, аның киләчәге, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе мәсьәләсе тирәсенә җыела.

З.Хәкимнең "Кишер басуы"драмасында мифологик катлам көчле. Әсәрнеңнигезендә оча торган тәлинкәләр хакындагы миф ята һәм вакыйгалар шул нокта тирәсенә җыела. Ирония һәм гротеск алымнары ярдәмендә бүгенге авыл тормышы тәнкыйтьләнә, эчкечелек, эгоистлык, караклык һ.б. сыйфатларбилгеләнә һәм алар бөтен җәмгыятькә хас сыйфатлар булып гомумиләшә, иҗтимагый, сәяси бәянең калкулануы күзәтелә. Күк тормышын автор идеаль, үрнәк тормыш моделе кебек тәкъдим итә.

Икенче төркем модернистик әсәрләрне тормышыбызда булган трагик күренешләрдән ачы күз яше аша көлеп, укучыны тирән уйланырга мәҗбүр иткән пьесалар тәшкил итә. Хәкимнең "Җүләрләр йорты", Д.Салиховның "Алла каргаган йорт" кебек әсәрләре шул төркемгә карый. Аларда фарс элементларына, пародия алымнарына мөрәҗәгать ителә, шартлылык еш кына фантастика, абсурд дәрәҗәсенә җиткерелә, уен алымы яратып кулланыла.

Мәсәлән, З.Хәкимнең "Җүләрләр йорты" трагикомедиясендә уен ике катламда бара. Объектив катламда ул шифаханәдәге вакыйгаларны, авыруларны бәяләүгә юнәлтелә. Өч "авыру" симулянт: инженер Шәүкәт, район гәзитендә эшләүче Сәлим һәм бизнесмен Закир җаваплылыктан качып, ягъни,

эштән кыскартудан, алимент түләүдән, өченчесе төрмәгә утыртудан  куркып, җүләрләр йортына керә. Үзләрен Брежнев, Горбачев, танылмаган даһи итеп күрсәтеп, авырулар булып “уйныйлар”. Авыруларның уены, сәяси эшлеклеләргә пародияләр совет хакимиятенә, идеологиясенә бәя бирүгә юнәлтелә. Бу “уен”га икенче “уен” каршы куела һәм беренчесен төгәлләштерә. “Җүләрләр” уенын көчәйтү максатыннан автор туган көн “уенын” кертеп җибәрә. Нурыйның туган  көнен үткәрәләр.   Ашау, компот эчү, гармун уйнау, бию, җырлау барышында “авырулар” арасындагы дошманлык мөнәсәбәтләре юкка чыга. Якты теләкләр әйтелә, бүләкләр бирелә. Ләкин бу вакытлыча гына күренеш, Халит Хәбирович керүе белән элеккеге бердәмлек, дуслык югала. Әлеге күренеш тә, соңрак Сабирның Халиткә каршы бердәнбер герой буларак калуы да чын дуслыкның булмавын дәлилли, шул чор идеологиясенең тагын бер сыйфаты төсендә аның кешеләрне уен уйнап, “җүләр” булып яшәргә мәҗбүр итүен күрсәтә. Бу урында автор уен алымына хас булган импровизация ысулына  мөрәҗәгать итә.

Өченче уен баш врач ярдәмчесе Халит Хәбирович тарафыннан алып барыла. Бар кешене куркытып яшәүне максат иткән, җүләрләр йортында баш табиб, хезмәткәрләрне, “авыруларны” бер-берсенә донос яздыртып, курку астында тоткан бу диктатор герой асылда җүләр буларак ачыла. Аның тышкы портреты да шул максатка буйсындырыла: “*Кыяфәтеннән эчке вәхшилек аңкып тора. Аның әллә нинди коточкыч эшләр эшли алырлык потенциаль кара энергиясе күзләрендә чагыла. Теләсә нинди мизгелдә алдан сизеп булмас адымнар ясарлык халәт...”*.

Әлеге өч уен ярдәмендә автор торгынлык чоры сәясәтенә ironияле бәя бирә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне гротеск аша гәүдәләндереп, сатирик планда ача (Й.Нигъмәтулина). Әсәрдәге уеннар барысы баргә кушылып, шул чор җәмгыятенә хас яшәү моделен тергезергә мөмкинлек бирә, сүз уены да чынбарлыкка тәнкыйди бәя булып яңгырый.

Пьесада эчке һәм тышкы каршылыклар җәмгыятькә, идеологиягә хас проблемаларны калкытып куя. Тышкы каршылыкның герой – җәмгыять төре

алга чыга, авыруларның үзара каршылыгы, авыруларның Халит белән конфликты идеологиягә хас төп сыйфатларны ассызыкларга ярдәм итә, рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе, курку, матди байлыкка омтылыш, асыл дуслыкның булмавы, ялган, мәкер, бюрократлык, тәкәбберлек кебек проблемаларны укучыга җиткерә, курку проблемасын төп проблема дәрәҗәсенә күтәрә: “*Мин булмасам, синең бу сасы психушкаң җимереләчәк. Курку гына тота бу бинаны (Халит); Барыбыз да корбаннар бит... Күп кеше бәхетсез булса, бәхетсезлеккә ияләшәсең ул... Син кара, монда бит бер генә дә бәхетле кеше юк”.* Шәүкәт, Алсу, Вәли, Сабирларның эчке каршылыгы да шул проблемаларны тирәнрәк ачуга буйсындырыла. Әсәрдә җәмгыятьнең үз-үзе белән каршылыкта булуы күренә. Биредә үзен акыллыга санаганнар асылда җүләр, Нурый, Сабир кебек җүләр дип саналганнар иң акылы фикер әйтеп, объектив бәя бирә алучылар кебек кабул ителә.

Әсәрдә пространство җүләрләр йорты образында төгәлләшә. Гомумән, XX гасыр ахыры татар драматургиясе сары йорт образына еш мөрәҗәгать итә, бер мәгънәдә әсәрдән-әсәргә күчерә барып, лейтмотив дәрәҗәсенә күтәрә. Сүз сәнгате аны туган йорт – туган ил – дәүләт – идеология мәгънәләрендә куллана, соңгы елларда “җүләрләр йорты” образы совет системасы хакында формалашкан бәяне юкка чыгару кебек тә шәрехләнә. З.Хәкимнең “Җүләрләр йорты” трагикомедиясендә ике җүләрләр йорты сурәтләнә: аның берсе җимерелә, аның урынына икенчесе калкып чыга. Беренче очракта ул совет системасы билгесе төсендә бирелсә, икенчесе совет системасына алмашка килгән үзгәртеп кору сәясәте булып аңлашыла.

Ф.Бәйрәмованың “Вакыйга җүләрләр йортында бара” драмасында постмодерн билгеләре үзен сиздерә. Вакыйгалар катламы Тиле Түрә, Тиле Даһи, Тиле карт образларының җүләрләр йортын сатарга әзерләнүе хакында хәбәр итә. Әсәрнең буеннан-буена уздырылучы сессия хакимияткә пародия төсен ала. Моннан тыш боларны күзәтеп торучы күз һәм Маска-битлек образларына таянып, ике катлам – югары һәм түбәк власть органнары, сәяси эшлеклеләр тергезелә. Хакимияткә хас кешеләрне уен уйнап яшәргә мәҗбүр

итү, үзеңне өстен кую, эгоистлык, бюрократлык кебек сыйфатларны аерып куеп, автор сәяси кыйммәтләрне кире кага.

Соңгы елларда иҗат ителгән реалистик әсәрләрнең романтик алымнарга бай булуы, тирән психологизмга йөз тотуы, тематик яктан төрлелеге күзгә ташлана. Бу юнәлештәге бер төркем әсәрләрне милли тема берләштерә, аларда җәмгыятьтәге үзгәрешләргә җавап төсендә милләт язмышы, милли менталитет, гореф-гадәтләрнең сакланышы, катнаш никяхлар һ.б. проблемалар калкытып куела. Мәсәлән, И.Юзеевның “Ак калфагым төшердем кулдан” (1990) драмасында дөнья буйлап сибелгән татарларның фаҗигале язмышы гәүдәләнә. Реализмның төп сыйфатларыннан иҗтимагый детерминация, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы сакланса да, романтик алымнар, тирән психологизм әсәрне баета. Композицион яктан Сан-Франциско – Казан телевизион күпере рәвешендә уйланылган бу драмада төп конфликт совет идеологиясе белән шәхес арасында бара һәм милләтнең фаҗигасе, бердәмлекнең җитмәве, гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең саклануы проблемаларын калкыта.

Күпер ике төрле тормыш шартларында яшәүче, төрле караш вәкилләрен — татарларны очраштыра. Шушы фонда совет идеологиясенә, андагы курку, шикләнү, үз фикереңне әйтә алмау кебек сыйфатлар чәчәк атуга тәнкыйди бәя бирелә. Советчыл системаның төп сыйфатын кешене икейөзлеләнеп яшәргә мәҗбүр итүдә дип, драматург моны 85 яшьлек Шәмсия әби язмышы мисалында ача. Шәмсия карчык һәм улы мисалында кешеләрнең ялгыш күзаллаулар белән яшәве фаҗига буларак тасвирлана. Карчыкның улы Габделхак (Жак) сугышта әсирлеккә эләгә, котылып француз партизаннары белән сугышып йөрсә дә, илгә кайтмый. Сталин режимының элекке әсирләрне төрмә–лагерьларга җибәрүен белеп, Америкага күчә, ләкин гомере буе илен, әнисен сагынып яши, анның ак калфагын төсе итеп саклый. Үзе хакында хәбәр итми, якыннарына моның шаукымы тияр дип уйлый. Телевизион күпердә әсир язмышы турында ишеткән Шәмсия аны сатлыкҗан кебек кабул итә. Тайфур Кормаш, Жак (Габделхак), Исмай Акчурин, Шәмсия Ишмуллина кебек образларның фаҗигасе аша төп идея уздырыла: чит җирләрдә яшәргә мәҗбүр булган милләттәшләрнең фаҗигасе – ул безнең дә фаҗига. Әлеге фаҗига,

хәсрәт ак калфак образына җыйнап та тәкъдим ителә. Ак калфак турында ишеткәч, ана үзгәрә, шул рәвешле калфак — гомумкешелек кыйммәте, кешелеклелек билгесе булып аңлашыла.

Аның башка мәгънәсе дә калку. Ак калфакны кулдан төшерү — туган җирне югалту. Драматург тамашачыны гореф–гадәтләрне, милли сыйфатларны саклау – милләтне саклау дигән нәтиҗәгә алып килә.

Т.Миңнулинның "Шәҗәрә" драмасында исә милләт язмышы гасырлар дәвамында формалашкан, асылда татарларның зыялы катламын тәшкил иткән морзалар катламы тарихын, фаҗигасен сурәтләү ярдәмендә чагыла. "Илгизәр плюс Вера" драмасында милли тема катнаш никяхлар проблемасына бәйләнештә ачыла. Төп каршылык татар һәм рус халыкларының яшәү рәвешенә, гореф-гадәтләр, традицияләр аерымлыгына нигезләнә. Илгизәр һәм Вера мәхәббәтенең генә гаиләне бәхетле итә алмавы бер фикергә китерә: гаиләнең нигезенә милли һәм дини бөтенлек тә салынырга тиеш, шушы фикер аша автор катнаш никяхларны кире кага. Бу караш өч буын язмышы аша төгәлләштерелә, моннан тыш автор идеясе күп еллар буена үсеп утырып та, ике милләт вәкиле кавышканнан соң ауган карт өянке метафорасы аша көчәйтелә. Т.Миңнуллин мондый никях ике милләт арасындагы дуслыкны югалта дип раслый. Драматургның "Гөргөри кияүләре", Йөрәк маем" комедияләрендә дә милләтнең гореф-гадәтләре сурәтләнә.

Бу юнәлештәге бер төркем әсәрләр тарихи темага мөрәҗәгать итеп языла. Р.Хәмиднең "Хан кызы", Р.Зәйдулланың "Хан һәм шагыйрь", Н.Фәттахның "Сармат кызы Сиринә", Ә.Гаффарның "Соңгы сәгать", Батулланың "Сират күпере", Ф.Бәйрәмованың "Атылган йолдыз" кебек тарихи темага язылган драмаларында тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр, шул чорлардагы вазгыятьне сәнгати тергезү аша хәзерге заманга бәя бирү омтылышы алга чыга, әсәрләр фәлсәфи фикерләр белән баетыла.

Драматургиядә сугыш темасы да актуаль. Әфган, Чечен сугышларының ачы хәсрәтен Ф.Бәйрәмованың "Сандугачның балалары" Ю. Сафиуллин "Йөзек кашы һәм хәнҗәр", Р.Батулланың "Кояш баеганда", И.Мәхмүтованың "Син бит

минем бер генәм", Т.Миңнуллинның "Әзләдем, бәгърем, сине" кебек әсәрләре яктырта һәм реалистик, романтик сюжет сызыклары әфган, чечен җирләрендә барган сугышны бөтен ил фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендәге яңарышның алшартлары нидән гыйбарәт?

2. Модерн алымнарының һәм постмодерн билгеләренең чагылышын аңлатыгыз.

3. Реалистик әсәрләрдә тәнкыйди катлам нинди функция башкара?

4. Бу юнәлештәге әсәрләргә нинди үзенчәлекләр һәм алымнар хас, нинди темаларга өстенлек бирелә һәм ни өчен?

## Лекция 2

**Аннотация.** Лекциядә 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендә романтик юнәлешнең үсеш-үзгәреше өйрәнелә, әлеге дәвер сәхнә әдәбиятында яңа тип геройлар, 1980-2000 нче еллар драматургиясендә жанр һәм жанр формалары билгеләнә.

**Ачкыч сүзләр:** драматургия, модерн алымнар, тенденция.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.95-217.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар драматургиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.436-443.

4. Саттарова А. Яңадулкында / А.Саттарова // Татар драматургиясе: 1960-80 нчееллар. – Казан: ТаРИХ, 2003. – Б.5-16.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская драматургия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.124-133.

**Глоссарий.**

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лекциянең планы**.

1. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендә романтик юнәлешнең үсеш-үзгәреше.

2. Әлеге дәвер сәхнә әдәбиятында яңа тип геройлар.

3. 1980-2000 нче еллар драматургиясендә жанр һәм жанр формалары.

Соңгы елларда иҗат ителгән романтик әсәрләр кеше шәхесен, аның рухи камиллеген, яшәү мәгънәсен, бәхет, буыннар арасындагы рухи бәйләнешләрне сурәтли, әхлакый-фәлсәфи уйлануларны җиткерә. Мондый әсәрләрдә фәлсәфилекнең, психологизмның аеруча көчле булуы күзгә ташлана. Т.Миңнуллинның “Сөяркә”, “Эзләдем, бәгърем, сине”, И.Юзеевның “Гашыйклар тавы” кебек драмалары шундыйлардан. Мәсәлән,

Т.Миңнуллинның “Сөяркә” драмасында Хәбир белән Әнисәнең гөнаһ мәсьәләсендә фикер төрлелеге белән очрашабыз. Әсәрнең сюжеты да геройларның гөнаһ мәсьәләсендә эзләнү тарихын берләштерә. Шуңа мөнәсәбәттә Хәбир - Әнисә тышкы каршылыгы, Әнисә һәм өлешчә Хәбир күңелендә баручы эчке каршылык асылда бер мәсьәләне – гөнаһ, рухи бөтенлек, әхлакый кыйммәтләр проблемасын ассызыклап бара. “Гөнаһ нәрсә ул? Сөяркә булу, никяхсыз башка берәүне ярату – гөнаһмы, түгелме?” соравы үзәккә куелып, һәр герой тарафыннан җавап эзләнә: “кеше өлешенә керү – гөнаһ (Әнисә); “син ышанган кеше сине алдаса” (Рәмзия); “яратуның ни гөнаһы бар икән, яратмаган кеше белән тормышыңны бәйләү – гөнаһтыр” (Хәбирә); “йомшак кешедән бала табу – гөнаһ” (Хәбир); “...имансыз җанның үз-үзен аклап яшәве”, “Яратмау – гөнаһ, ләкин никяхсыз тормыш та - гөнаһ.. Бе хатыныбызга канәгать булмыйча, икенчеләрен алдыйбыз да “сөяркә” дип атарга теләмибез. Сөяркә ул сөяркә инде... Бу дөньяда һәрнәрсәнең үз исеме бар. Әйбер урлый икән – карак, урлашып кочаклаша икән – зина. Гөнаһ кыласың икән, гөнаһны күтәрергә дә әзер булырга кирәк. Оҗмахка арткы ишектән генә керергә телимез” (хәзрәт); “дөньяда иң зур гөнаһ - сине бик яраткан кешене алдау” (Хәбир). Шул рәвешле фикер төрлелеген ачып, үз геройларына төрле юлларда хакыйкатьне эзләү мөмкинлеген калдырып, драматург укучысын бер нәтиҗәгә китерә: гөнаһны һәркем үзенчә аңлый, ләкин гөнаһка бер кереп баттыңмы, аннан чыгу юлын табуы авыр, бәхет ул мәхәббәт белән янәшәдә җан тынычлыгы, иман ныклыгы бөтенлегендә дә.

Соңгы еллар татар драматургиясендә фәлсәфилекнең көчәюе бер тенденция төсен ала. Яшәеш турында фәлсәфи уйланулар, зур проблемаларны кыска вакыт аралыгында чишәргә омтылыш көчәя. Бу үзенчәлекләр И.Юзеевның 1992 нче елда сәхнә өчен эшләнгән “Гашыйклар тавы”драмасында да алга чыга. Әсәрдә вакыйгалар катламы Сәет белән Мөнирәнең үткәндәге мәхәббәт тарихы, аерылышу газаплары, соңыннан икесенең дә бер-берсен сагынып, юксынып яшәүләре хакында бәян итә. Сәет-Мөнирә, Өмет-Мирсәет, Мөнирә-Өмет аарсындагы тышкы, Сәет Өмет күңелендә барган эчке

каршылыклар мәхәббәткә тугрылык, туган җиргә, үткәннәргә мөнәсәбәт, гореф-гадәт, традицияләрнең сакланышы, табигатькә саксыз караш проблемаларын кискен калкытып куя. Моннан тыш романтик геройлар үзләренең хыял-омтылышлыры, хыялда тудырылган матур дөньялары белән гадәти, көндәлек тормышка каршылыкта торалар.

Драманың нигезенә салынган фәлсәфи катлам символик образлар, метафора аша ачыла. Гашыйклар тавы әсәрдә мәхәббәтнең бөеклеге, рухи югарылык символы буларак төгәлләшә, әхлакый камиллеккә юл мәхәббәт аркылы билгеләнә. Романтик әдип яшәеш фәлсәфәсен дә идеаль мәхәббәт дәрәҗәсенә бәйләп аңлата. Саф мәхәббәт хакындагы хыял югалу романтик концепциядә яшәешнең бетүе белән тәңгәлләштерелә; яшәү асылы турындагы хакыйкать мәхәббәт сафлыгы, бөеклеге белән билгеләнә, шуңа да мәхәббәт турындагы хыял тормыш, яшәү фәлсәфәсе кебек тәкъдим ителә һәм бу фикер Гашыйклар тавының фаҗигасе аша раслана.

Мәхәббәтнең көчен, бөеклеген раслау юлында әдип серле үрдәк турындагы риваятькә мөрәҗәгать итә. Ул Сәет – Мөнирә мәхәббәтенә метафора булып, серле үрдәк Мөнирәнең саф мәхәббәт турындагы хыялын гәүдәләндерә, мәхәббәт җан сафлыгын саклаучы буларак та шәрехләнә. Мөнирәнең кошка тиңләштерелүе аның мәхәббәт аша тән, җан, рух бөтенлегенә ирешкән идеаль образ дәрәҗәсенә күтәрелүен дәлилли. Бу фикерләр Вл.Соловьевның мәхәббәт фәлсәфәсенә, София хакындагы өйрәтүләренә аваздаш. Вл.Соловьев хатын-кызда Илаһи хатын-кызлык бар дип саный, ул матурлык һәм яхшылыкның берлеге кебек кабул ителә. XX йөз башы романтик, символистик әдәбиятында да илаһи кыз белән җир кызы арасында чикләр җуела (Д.Заһидуллина). И.Юзеев фәлсәфи яссылыкта шушы традицияләрне дәвам итә, Мөнирәне илаһи дәрәҗәгә җиткереп сурәли. Соңыннан Мөнирә белән янәшәдә Сәетнең дә кошка әверелүе бер фикерне асызыклый: кешене мәхәббәт яшәтә, рухи камилләштерә, тормыш ваклыкларыннан өстен куеп, әхлакый сафландыра. Бу фикер канун дәрәҗәсендә тәкъдим ителә.

Ф.Яруллинның “Бер көрешү – үзе бер гомер”, “Кызларның кызганнары”, И.Юзеевның “Эзләдем, таптым, югалттым”, Г.Каюмовның “Сагынырсың әле син дә бер” һ.б. әсәрләре дә романтизм юнәлешен сыйфат һәм сан ягыннан баета; әхлакый кыйммәтләрнең кимүе, яшәешкә эчкечелек, әхлакый тотнаксызлык, матди байлыкка омтылыш кебек проблемаларны күтәрү аларны бер бәйләмгә туплый. Ф.Яруллинның ике комедиясендә дә тормышта урын алган ямьсез күренешләрдән көлү, гротеск, сүз уйнату кебек алымнар ярдәмендә сурәтләнә.

Бу чор драматургиясендә өлкән буын геройларының да, яшь буынның да ике тибы аерылып чыга. Өлкән буын вәкилләренең бер төркеме әхлакый кыйммәтләрне, буыннар арасындагы рухи бәйләнешләрне саклрга омтылучы геройлар итеп сурәтләнсә, икенче төркем яшәү мәгънәсен әхлакый кыйммәтләрне соңлап аңлаган, җәмгыять тарафыннан онытылган персонажларны үз эченә ала. Т.Миңнуллинның “Хушыгыз”, И.Юзеевның “Гашыйклар тавы”, Р.Хәмиднең “Олы юлның тузаны”, “Актамырлар иле” кебек әсәрләрендә шундый геройлар белән очрашабыз. Мәсәлән, Т.Миңнулинның “Хушыгыз” драмасында Миләүшә ялгызлыкта калып, яшәү мәгънәсенә төшенгән герой кебек тәкъдим ителә. Аның эчке каршылыгы да яшәеше белән күңел дөньясы арасында төгәлләшә. Тышкы ялган дөнья белән эчке халәте, тормыштагы даны белән шәхси бәхетсезлеге, чын күңелдән Галимулланы яратып та, дан-дәрәҗә хакына аннан читләшүе бу каршылыкны төрле яссылыкларда ачарга ярдәм итә. Романтик сюжет сызыгындагы Миләүшә белән Галимулла “уены”, кайчандыр “дус” булып “уйнаган” Рафис, Фәһим, Нурисламнарның яшәеше укучыны бер фикергә китерә: кеше үзе булып калганда гына яшәү ямен, бәхетен таба ала. Геройлар бирелешендәге төрлелек яшь буынны сурәтләү барышында да саклана. Чор үзгәрешләрендә үзен саклап кала алмыйча, тормыш баткагына чумган, төшенкелеккә бирелеп, ялгыш юлдан киткән геройлар З.Хәкимнең “Шайтан куентыгы”, Д.Салиховның “Яшьлек хатам – йөрәк ярам”, И.Юзеевның “Эзләдем, таптым, югалттым” кебек пьесаларында тип дәрәҗәсендә сурәтләнә. Г.Каюмовның “Сагынырсың әле син

дә бер...”, Т.Миңнуллинның “Эзләдем, бәгърем, сине” кебек драмалары тормыш авырлыкларына сыгылып төшмичә, ихтыяр көче аша үз максатына омтылган, рухи ныклыкка ия геройлар тормышын яктырта.

Драматургларның жанрлар өлкәсендә иҗади эзләнүләре водевиль, мелодрама, трагедия, психологик , иҗтимагый-сәяси драма, драматик хикәя, драматик фрагмент, шигъри драматургия һ.б жанр һәм жанр формаларының активлашуына китерә. Шушы еллар аралыгында әдәби тәнкыйть татар драматургиясенең бер үзенчәлеге төсендә комедия жанрының активлашуын билгели. Аның музыкаль комедия (Д.Салихов “Хатын түгел аждаһа”, М.Гыйләҗев “Казан егетләре”, “Казан егетләре артыннан”), лирик комедия (Ф.Яруллин “Сөембикә егет сайлый”), водевиль характерындагылары (Р.Батулла «Сөйгән ярым ятка кала»), сатирик комедия (Д.Салихов “Пуля”), иҗтимагый комедия (З.Хәким “Чапты атым Казанга”), көнкүреш комедиясе (Ф.Яруллин “Бер күрешү – үзе бер гомер”) кебек жанр формалары мәйданга чыга. Драма жанры фаҗигале драма (И.Юзеев “Ак калфагым төшердем кулдан...”), иҗтимагый драма (Ф.Бәйрәмова “Безне онытмагыз”), публицистик драма (Р.Мигнгалим “Дүрт кешелек утыргыч”), психологик драма (Т.Миңнуллин “Эзләдем, бәгърем, сине”, “Хушыгыз”) жанр төрләренә байый. Тарихның үткән дәверләрен, әфган һәм чечен сугышларын әдәби материалда сурәтләргә омтылу драматургиядә трагедия жанрының активлашуына китерә. Шушы елар аралыгында Ю.Сафиуллинның “Идегәй”, “Йөзек һәм хәнҗәр”, Р.Хәмиднең “Хан кызы” кебек трагедияләре укучыга тәкъдим ителә.

Шулай итеп, кешелек, милләт, татар халкы тормышына, яшәешенә, үткәненә һәм бүгенгесенә хас проблемалар күтәрелеп, милләтнең киләчәге, фаҗигасе, яшь буынның упкын алдында торуы мотивлары хәзерге драматургиягә хас гомуми сыйфатлар төсен ала, сүз сәнгатенең бу төре әдәбиятны сүз-сурәт, образлар бирелеше, жанр һәм жанр формалары, агымнар төрлелеге җәһәтеннән дә баета.

**Контроль сораулар һәм биремнәр.**

1. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендә романтизм иҗат юнәлешенең үсеше, аның алшартлары нидән гыйбарәт?

2. Романтик әсәрләрдә нинди мотивлар, фәлсәфи фикерләр урын ала, алар нинди функция башкара?

3. Бу юнәлештәге әсәрләргә нинди үзенчәлекләр һәм алымнар хас?

4. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендә нинди жанр һәм жанр формалары урын ала?

**Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар**

**а) Төп әдәбият (основная литература):**

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Галиуллин Т. Шигърият баскычлары / Т.Галиуллин. – Казан: Мәгариф, 2002. – 229 б.

Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 192 б.

Галиуллин Т., Йосыпова Н. Басынкы елларның дәртле шигърияте / Т.Н.Галиуллин, Н.М.Йосыпова // Татар шигрияте: 1960-80 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.3-26.

Даутов А. Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм / А.Даутов. – Казан: ”ИНТЕЛПРЕСС” нәшр., 2002. – 152 б.

Закирҗанов Ә. Яңарыш юлыннан / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – 303 б.

Заһидуллина Д., Закирҗанов Ә., Йосыпова Н., Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. Теория. Тарих / Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Н.Йосыпова, Т.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 364 б.

Заһидуллина Д. Яңа дулкында / Д.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.107-123.

Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.2: Семидесятые годы (1968-1986): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 288с.

Литературная энциклопедия терминов и понятий. – М.: НПК «Интелвак», 2001. – С.159-161.

Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. - 544 б.

Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская драматургия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.124-133.

**б) ярдәмче әдәбият (дополнительная литература):**

Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 223 б.

Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә / А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. – 239б.

Галиуллин Т. Шагыйрьләр һәм шигырьләр / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. – 208 б.

Галиуллин Т. Дәвамлылык / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 168 б.

Галиуллин Т. Безнең заман— үзе җыр / Т.Галиуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.— 208б.

Галиуллин Т. Илһам чишмәләре. Монография / Т.Галиуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.— 365б.

Гамбәр Н. Ике урман арасы / Н.Гамбәр // Казан утлары. – 1997. - №1. – 48-52 б.

Гафиятуллина Н. XX гасыр татар шигъриятендә Тукай / Н.Гафиятуллина. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2002. – 152 б.

Есин А. Принципы и приемы анализа литературного произведения / А.Есин. – М.: Флинта, Наука, 1999. – 248 с.

Закирҗанов Ә. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – Б.60-63.

Зөлфәт. Чытырманда былбыл сайрый... // Ике урман арасы. – Казан, 1995. – 7-22 бб.

Ковский В. Литературный процесс 60-70-х годов / В.Ковский. – М.: Искусство, 1983. – 336 с.

Компанеец В. Русская социально-философская проза 1970-80-х годов. Нравственный и психологический аспекты изображения человека / В.Компанеец. – Саратов, 1994. – 228 с.

Латынина А. За открытым шлагбаумом: Литературная ситуация конца 80-х / А.Латынина. – М., 1991. – 160 с.

Мөхәммәдиев Р. Якутлар табыладыр вакыт белән. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Р.Миңнуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 216 б.

Нигматуллина Ю. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 1997. – 192 с.

Нигматуллина Ю. “Запоздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 2002. – 176с.

Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес. — Казан: Мәгариф, 2002. — 235 б.

Современная русская советская литература. Литературный процесс 50-60-х годов. – М.: “Просвещение”, 1987. – 218 с.

Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. – М.: ИМЛИ РАН, «Наследие», 2001. – 624с.

Урманче Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь / Ф.Урманче. — Казан: РИЦ “Школа”, 2002. – 260 б.

Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г) / Ф.И.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

Шайтанов И. Поэзия 70-90-х годов. Обзор. Новое в поэзии / И.Шайтанов // Русская литература XX века. – М., 1994. Ч.2. – С.277-303.

Шакирова Г. Драматургия Туфана Миннуллина 80-90-х годов (тематика и проблематика. Жанровая разновидность. Методика изучения в школе): Автореф.дисс.канд.филол.наук. - Казань. - 2000. - 19 с.

Шарипов М. Драматургия Туфана Миннуллина. Проблема героя и его художественное воплощение: Автореферат дисс....канд.филол.наук. - Уфа. - 1989. - 22 с

Шәрәфиев Р. Безне кемнәр аңлар? / Р.Шәрәфиев // Казан утлары.— 2000.— №7.— 139-144б.

Юзиев Н. Шигърият дөньясы / Н.Юзиев. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. – 312 б.

Юсупова Н. Тылсымлы сүз остасы / Н.Юсупова // Казан утлары. – 2007. - №1. – Б.137-142

Явчуновский Я. Драма на новейшем рубеже. Драматургия 70-80-х годов: конфликты и герои, проблемы поэтики / Я.Явчуновский. – Саратов, 1989.

**Информацион чыганаклар, интернет-ресурслар**

(Рекомендуемые информационные ресурсы в Интернете):

- www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»
- www.feb-web.ru Фундаментальная электронная библиотека «Русская литература и фольклор»
- www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КФУ
- www.slovari.ru Электронные словари

## Терминологик сүзлекчә

**Авангардизм –** 1910-50 еллар реалистик булмаган әдәбиятындагы бертөркем агымнарның җыелма атамасы.

**Автор** – әдәби иҗатның субъекты, бербөтен әдәби әсәр иҗат итүче.

**Аллегория** – образ төре, конкрет җанлы табигать сурәте аша читләтеп әйтү.

**Архетип** – теләсә нинди әдәби төзелеш нигезендә ятучы, гомумкешелек кыйммәтенә ия фундаменталь башлангыч мотивлар, образларның аталышы.

**Әдәби бәйләнеш** – бер яки бертөркем әдәби күренешнең башка бер яки бертөркем әдәби күренешкә тәэсире, әдәби әсәрләр арасында охшашлану, багланыш.

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Интертекстуальлек** – текстның чит цитаталардан һәм реминисценцияләрдән төзелүе – терминын француз филологы һәм постструктуралистик юнәлеш теоретигы Ю.Кристева кертә.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Мотив -** әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Миф** – дөньяның килеп чыгышы, кешенең барлыкка килүе, аллалар һәм патшаларның, каһарманнарның батырлыгы хакында бик борынгы сөйләүләр. Ул – борынгы кешенең тормышны һәм үз-үзен күзаллавы, гаять әһәмиятле,

ләкин аңлаешсыз, серле тоелган табигый, физиологик, иҗтимагый күренешләрне шәрехләве.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Имтихан сораулары**

1. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә яңа юнәлешләр (Зөлфәт, Сөләйман, Р.Зәйдулла, Р.Сүлти, Г.Морат һ.б.)

2. Т.Миңнуллинның “Хушыгыз” драмасында алымнар төрлелеге, идея бирелеше, җәмгыятькә бәя, төп геройлар аша уздырылган фәлсәфә.

3. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясендә “абсурд театрына” күчеш (З.Хәким, М.Гыйләҗев), шартлы образ һәм формаларга мөрәҗәгать итү (М.Гыйләҗев).

4. М.Гыйләҗевның “Бичура” драмасында мифологик образ һәм мотивлар.

5. Т.Миңнуллиның “Хушыгыз” драмасында уен алымы, вазифасы.

6. Хәзерге татар драматургиясендә уен алымы, аның төрләре.

7. З.Хәкимнең “Җүләрләр йорты” трагикомедиясендә шартлылык, постмодернистик билгеләр.

8. З.Хәкимнең “Җүләрләр йорты” трагикомедиясендә уен, вазифасы.

9. 1980-2000 нче еллар татар драматургиясе: темалар һәм күтәрелгән проблемаларның төрлелеге, актив иҗат иткән авторлар, аның үсешендәге төп юнәлешләр.

10. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә виртуаль поэзия күренеше һәм акрошигырь.

11. 1980-2000 нче еллар татар поэзиясендә яңа күренешләр.

12. 1980-2000 нче еллар татар шигърияте: иҗат юнәлешләре, агымнар, тема-проблемалар төрлелеге.

13. М.Гыйләҗев иҗатында яңа алымнар, мотивлар төрлелеге.

14. М.Гыйләҗевның “Бичура” драмасында шартлылык, ялгызлык фәлсәфәсе.

15. М.Гыйләҗевның “Бичура” драмасында символик һәм метафорик образлар.

16. Зөлфәт Хәкимнең “Җүләрләр йорты” трагикомедиясендә йорт образының мәгънәви бирелеше.

17. Р.Харис иҗатында интеллектуаль тенденция алымнары.

18. Р.Харисның “Рәссам” поэмасында шартлы образ һәм алымнар.

19. Р.Харисның “Ат иярләү” поэмасында структур катламнар.

20. Р.Харисның “Ант суы” поэмасында ассоциатив вакыт бирелеше.

21. 1980-2000 еллар татар прозасы. Яңартылган реализм: магик, психологик реализм күренешләре, интеллектуаль тенденция. Романтизм сентименталь башлангыч.

22. 1980 -2000 еллар татар прозасында магик реализм күренеше. Н.Гыйматдинованың “Сихерче”, “Ак торна каргышы”, “Болан”, “Пәри утарында” һ.б. повестьлары.

23. Татар прозасында психологик реализм күренеше. Ф.Бәйрәмованың “Битлек”, “Болан” повестьлары.

24. 1990 еллар реалистик прозасында интелектуаль тенденция.

25. Интеллектуаль башлангычлы прозаның гротеск формасына мөрәҗәгать итүе. Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” романы.

26. Интеллектуаль башлангычлы прозаның фәлсәфи-психологик канаты.Ф.Бәйрәмованың “Канатсыз акчарлаклар”, “Алыплар илендә” повестьлары.

27. Сатирик һәм фәлсәфи канатлы З.Хәким прозасы. “Курку”, “Гөнаһ”, “Агымсуда ни булмас” әсәрәре.

28. Интеллектуаль башлангычлы прозаның әхлакый канаты. Г.Гыйльмановның “Албастылар” романы.

29. 1980-2000 еллар татар прозасында романтизм. Саф романтик әсәрләр. Ф.Садриевның “Кыргый алма ачысы”, М.Галиевнең “Ак абагалар” повестьлары.

30. Романтик реализм: Ә Сәлахның “Соңгы вальс”, М.Кәбировның “Мәхәббәтән җырлар кала” повестьлары.

31. 1980-2000 еллар татар прозасында сентименталь башлангыч. Ф.Яруллин прозасы: “Яралы язмышлар”, “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра” әсәрләре.

32. 1980-2000 еллар татар прозасында постсимволизм. Р.Зәйдулла хикәяләре.

33. 1980-2000 еллар татар романында заман, хакимият, системаның бөтенлекле образын тудыру. И.Сәлахховның “Колыма хикәяләре” , А.Гыйләҗевның “Балта кем кулында?”, “Йәгез, бер дога!” романнары.

34. Ф.Садриевның “Таң җиле” романында шартлы- меиафорик образлар.

35. 1980-2000 еллар татар прозасында хикәя жанры үсеше. М.Кәбиров, И.Иксанова хикәяләре.

36. 1980-2000 еллар татар балалар прозасында юнәлешләр: Г.Гыйльманов, Н.Гыйматдинова, С.Гаффарова һәм В.Нуриев, Л.Лерон һ.б.